Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 51 (1467) 29 декабрь 2023 ел

1995 елның июленнән башлап чыга

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga madani_zhomga

8-9

«Очерки по истории Казанского ханства» исемле китабы өчен карагруһчылар Михаил Худяковны атып үтерә, ләкин татар халкын яклаган бөек тарихчының кадерен үз Казаныбызда да белмиләр шул.

14-15

1923 елда Биектау районының Өмбе авылында туып-үскән Асия Харисова 1949 елдан башлап Камал театрында дистәләгән гүзәл рольләр башкарып кына калмый, ул әле татар халкына гаять зәвыклы җырчы Равил Харисовны да бүләк итә.



16-17

1908 елда Әлки районында туган Әзәл Яһудин артист хезмәтен 1930 елда Әстерхан драма театрында башлап җибәрә, биш елдан соң Казанга кайта һәм тагын 60 елга якын милли сәхнәбезгә, газиз халкына хезмәт итә.

Яңа ел белән!



Яңа еллар мәрхәмәтле килсен, Ил-көннәргә иңсен иминлек!..

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов республикада урнашкан югары уку йортлары ректорлары һәм фәнни учреждениеләр җитәкчеләре белән очрашты.
- Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте 2024 елны «Гаилә һәм хәләл яшәү рәвеше елы» дип игълан итте.
- Россия Хөкүмәте 23 яшьтән олырак ятимнәр өчен торак сертификатлары бирү тәртибен раслады.
- Рособрнадзор белем бирүнең яңа моделендә Бердәм дәүләт имтиханының саклануын белдерде.
- «Миллиард татар» басмасы «Ел татарлары» бәйгесе җиңүчеләре исемлеген игълан итте.
- 810 км озынлыктагы М12 Мәскәү-Казан тизйөрешле трассасы ачылды.
- «Туган авылым» комплексында «Каз өмәсе ярминкәсе» узды.
- Габдулла Тукай әдәби музеенда «Тукай һәм музыка» күргәзмәсе ачылды.
- Мәктәп балалары өчен Республика Яңа ел чыршысы узды.
- Менделеевскиның 3нче химия-технология лицее базасында Татарстан Фәннәр академиясе ярдәме белән мәктәп укучыларының «Менделеев варислары» исемле Кече академия ачылды.
- Алабуга районы инвестицион җәлеп итүчәнлек буенча Татарстанның иң яхшы муниципаль берәмлеге дип танылды.
- Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының Бөтенроссия күз һәм пластик хирургия үзәгендә ике тапкыр Советлар Союзы Герое Муса Гәрәевнең музей экспозициясе ачылды.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

1 гыйнвар – композитор, беренче татар балеты «Шүрәле»нең авторы, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Фәрит Заһидулла улы Яруллинның тууына 110 ел (1914-1943);

– язучы, Татарстан АССРның атказанган мәдәният хезмәткәре Рафаил Газиз улы Төхфәтуллинның тууына 100 ел (1924-1994);

– язучы-прозаик, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Әхәт (Габделәхәт) Габдрахман улы Гаффар (Гаффаров) ның тууына 75 ел (1949-2021).

2 гыйнвар – Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре Роза Сәетнур кызы Җаббарова 75 яшь (1949);

– язучы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Фаил Миңнемөхәммәт улы Сафинга (Фаил Әмәккә) 70 яшь (1954).

СЫНАМЫШЛАР

31 декабрьдә агачларны бәс сарса, ашлык уңар ● Ел башында җил булса, ел буена җил-давыл тынмас ● Кышын кояш кызарып чыкса, суыта ● Кояш тирәсендә нурлар югары чагылса – буран, түбән чагылса – салкын була ● Колак кычытса, буран булыр.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **8 сәгать 15 минутта** чыкты, һәм ул **15 сәгать 17 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **7 сәгать 02 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **10 минутка** озынаячак һәм киләсе җомгада, ягъни **5 гыйнварда 7 сәгать 12 минут** тәшкил итәчәк.

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Гыйнварның магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 1 гыйнвар.**

* * *

Гадәттә, тулы айдан айның соңгы чирегенә кадәр **(27 декабрь – 4 гыйнвар)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

###ҺИҖРИ БУЕНЧА 1445 ЕЛ

Бүген җөмәдел ахир аеның 16 нчы көне

ҖАН АВАЗЫ

Илсур МАНСУРОВ, Уфа фән һәм технологияләр университетының Стәрлетамак филиалы татар һәм чуваш филологиясе кафедрасы мөдире, филология фәннәре кандидаты, доцент

ТЕЛЕБЕЗНЕ САКЛЫЙК!

Соңгы елларда югары уку йортларының «Өченче миссиясе» дигән проектлар актуальләште. Аңлашыла ки, университетларның беренче һәм икенче миссияләре – ул белем бирү һәм фәнне үстерү. Югары мәктәпнең өченче миссиясе дип университетларның җәмгыять белән бәйләнеше, илнең һәм иң беренче нәүбәттә төбәкнең үсешен тәэмин итүдәге социаль җаваплылыгы күзаллана. Моның иң мөһим юнәлешләре – милли-мәдәни, мәгариф һәм социаль проектларны тормышка ашыру.

Башкортстанның Стәрлетамак шәһәрендә 1940 елларда укытучылар әзерләүче институт буларак ачылган безнең уку йортында 1993 елда татар теле һәм әдәбияты буенча белгечләр әзерләнә башланды. 1997 елда әлеге уку йортында татар һәм чуваш филологиясе кафедрасы ачылды. Ул вакытта уку йорты Стәрлетамак дәүләт педагогия институты дип атала иде, бүген без – Уфа фән һәм технологияләр университетының Стәрлетамак филиалы.

Кафедра ачылган көненнән үк әлеге фукцияне үтәп килә. Башкортстанның көньяк төбәге милли-мәдәни, фәнни-методик үзәге буларак татар һәм чуваш телләрен, әдәбиятларын, фольклорын саклау, пропагандалау һәм үстерү буенча шактый эшләр башкара. Безнең Төп эшебез студентлар укыту, әмма без моның белән генә чикләнеп калмыйбыз.

Югары уку йорты фәнни эш белән дә шөгыльләнә, өстәвенә педагогик юнәлештә белгечләр әзерләү сәбәпле методик эш тә башкара. Безнең уку йорты төбәкнең үзенчәлекле ФӘННИ-МЕТОДИК ҮЗӘГЕ булып тора.

Кафедра укытучылары 25 ел дәвамында 250 дән артык уку-методик кулланма, монография, дәреслекләр һәм меңнәрчә фәнни, методик мәкаләләр бастырды. Алар арасында Башкортстан мәктәпләре өчен Татар теле буенча уку кулланмалары да бихисап. Студентлар укуда да, фәнни, иҗтимагый эшләрдә дә актив. Төрле дәрәҗәдәге олимпиадаларда, конкурс-бәйгеләрдә яхшы нәтиҗәләр күрсәтәләр, вуз, шәһәр, төбәк һәм республика милли-мәдәни чараларда катнашалар. Бүгенгә кадәр уку йорты йөзләрчә татар, чуваш теле һәм әдәбияты белгечләре әзерләп чыгарды. Аларның шактые мәгариф өлкәсендә эшли.

Кафедраның гыйльми, методик һәм оештыру потенциалына шәһәр, республика, хәтта федераль дәрәҗәдә дә ихтыяҗ бар. Без Башкортстан, Татарстан, Чуваш Республикаларының мәгариф министрлыклары, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Казан федераль университеты, аның филиаллары белән тыгыз бәйләнештәбез, Бөтендөнья татар конгрессы проектларында да актив катнашабыз. Россия фәннәр академиясенең Мәгарифне үстерү стратегиясе институты белән туган тел һәм әдәбият дәреслекләренә экспертиза, цифрлы ресурсларга верификация дә ясыйбыз.

25 елдан артык эшләү барышында милли белгечләр әзерләү төрле чорлар кичерде, зур нәтиҗәләр белән эшләү дәверләре дә булды. Хәзер дә тырышып эшләвебезне дәвам итәбез. Тик соңгы чордагы мәгариф өлкәсендәге үзгәрешләр безгә дә йогынты ясамый калмады. Милли телләр укытуның гаять дәрәҗәдә азаюы эш базарының тараюына китерде. Милли бүлекләрдә укырга теләүчеләр дә элекке еллардагы кебек түгел. Әйтик, 15 ел элек 20-25 кешелек төркемнәрдә татар һәм чуваш белгечләре әзерләнсә, хәзер 16 кешелек татар-чуваш уртак төркемә генә. Әле бу төркемне җыю да кыенлык белән бара, моның өчен укытучылардан зур тырышлык сорала. Бу юнәлештә проблемалар шактый. Әйтик, татар теле һәм әдәбияты бүлекләрен саклау, аларга студентлар җыю югары уку йорты укытучыларының шәхси эше генә булып кала бирә! Чөнки мәгариф министрлыгына да, район, шәһәр бүлекләренә дә, мәктәп директорларына да, хәтта татар теле укытучыларына да бу кирәкми. Һәрберсенең үз проблемалары, берәүләренә башка «җитдирәк» предметлар укытучылары җитми; икенчеләренә туган тел укыту мәктәп өчен өстәмә проблемалар тудыра; өченчедән, үзләренә дә сәгатьләр җитми һ.б. Иң аптыратканы: милли мәсьәләләр белән шөгыльләнүче иҗтимагый оешмаларның җирле җитәкчеләренең кайберләре турыдан-туры «бу сезнең эшегез!», дип читкә кача. Менә шундый парадокс! Татар теле укытучысы әзерләү проблемалары милли оешма эше түгел икән!

Тагын бер мәсьәлә. Төбәкләрдән Казан югары уку йортларына бик күп яшьләребез китә. Беренче карашка, яхшы гамәл. Әмма халыкның акыллы сүзе бар: таяк ике башлы! Казанга килгән яшьләребез туган якларына әйләнеп кайтмый. Ә төбәкләрдәге милли мәгарифне, мәдәниятне кем саклар, кем үстерер?

Төбәкләрдә милли белгечлек әзерләү зур кыенлыкларга дучар икәнен Тубыл, Төмән, Ульян, Оренбург, Ижевск, Бөре, Мәскәү шәһәрләрендә ачылып ябылган бүлекләр язмышы да ачык чагылдыра. Башкортстан уку йортлары бу юнәлештә әле тырышлык салып килә, тик алда әйткән абитуриентлар һәм эш урыннары мәсьәләләреннән тыш та проблемалар җитәрлек. Бакалавриат буенча уку планнары, «май указларын» тормышка ашыру белән бәйле югары уку йортларында сәгатьләр саны шактый кимеделде, галим-укытучыларның йөкләмәләре арттырылды. Нәтиҗәдә, кафедраларда укытучылар саны күпкә азайды. Әйтик, бездә 10 ел элек татар теле һәм әдәбияты буенча гына 5 укытучы иде, хәзер 2 кеше! Ә бу, үз чиратында, эш сыйфатына зыян сала.

Гомумән алганда, Башкортстан югары уку йортларының барысында да татар теле һәм әдәбияты буенча белгечләр әзерләү өчен шартлар тудырылган. Вуз, республика җитәкчелеге кафедралар эшчәнлегенә уңай мөнәсәбәттә. Аларның материаль-техник базасын яхшыртуга, студентларга уку шартларын булдыруга, фәнни-педагогик кадрларны саклап калуга, бюджет урыннар бүлүгә мөмкин булганның барысын да эшлиләр. Татар конгрессының Милли шура рәисе Васил Шәйхразиев Стәрлетамак шәһәренә килеп, безнең уку йорты һәм кафедра эшчәнлеге белән танышты. Әлеге сәфәр безнең өчен зур әһәмияткә ия иде. Кафедра эшчәнлегенә мондый игътибар уку йорты җитәкчелеге, коллектив алдында мәртәбә булды, безгә дәрт өстәде.

Кафедрабызны һәрдаим китаплар белән тәэмин итеп килгән Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына, Бөтендөнья татар конгрессына, фәнни-методик ярдәм күрсәтүче Казан федераль университеты галимнәренә, студентларның «Нәүрүз» ансамбленә татар милли киемнәре бүләк иткән Татарстан хөкүмәтенә, һәрдаим ярдәм күрсәтүче Мәгариф һәм фән министрлыгына да рәхмәтләребез яусын.

Соңгы елларда борчуга салган тагын бер тараф бар: мөнбәрләрдән, телевизордан да, матбугатта да «тырышып-тырышып» туган телне өйрәнүне гаиләгә бәйләп аңлаталар. Мөгаен, бик дөрестер. Туган тел нигезе гаиләдә салына. Тик җитди мәсьәләне кабат-кабат яңгырату сораулар да тудыра. Бик мөһим мәсьәләне артык гаиләштерү түгелме бу? Җаваплылыкны күчерү омтылышы түгелме? Моңа сагаеп карау мәгариф өлкәсендәге тормыш тәҗрибәсеннән килә.

Ата-аналар бакчага йөргән баласы белән тәүлек эчендә ничә сәгать кенә туган телендә аралаша ала? Иң яхшысы 2-3 сәгать! Бакчада бала рус телендә 10 сәгать чамасы. Өстәвенә, атна буе эштә булган ата-ана гаилә мәшәкатьләре нәтиҗәсендә үз баласын янә дә «русча сөйләшүче телевизорга», интернетка тапшыра. Аптырамаслык түгел, хәзер авылларыбызда да туган телләрен югалта баручы балаларның арта баруы бит!

Соңгы елларда татар телен укыту буенча яңа дәреслекләр, кулланмалар, күргәзмә материаллар басылды, алар зәвыклы, заманча эшләнгән. Әмма ни хикмәт: балаларыбыз русча сөйләшә! Димәк, без һаман нәрсәнедер эшләп бетермибез. Мин гаиләдән җаваплылыкны алып ташларга җыенмыйм. Гаиләдә бала әйләнә-тирәне туган телендә аңлый башларга, балалар бакчасында һәм мәктәптә ул аны камилләштерергә тиеш. Һөнәри белемне дә туган телендә алса, тагын да яхшырак. Башкача булырга мөмкин түгел!

Мәсьәлә бик катлаулы. Инде 10 елдан артык училище, колледж, вузларда балалар бакчалары, башлангыч класслар өчен тәрбиячеләр, укытучылар әзерләүче милли бүлекләр юк дәрәҗәсендә. Федераль стандартларында, уку планнарында татар телендә белем һәм тәрбия бирү шактый катлауландырылган иде. Әмма ирешелгәннәрдә тукталу ярамый, проблеманы хәл итүнең төрле юлларын эзләргә кирәк. Законнар, норматив-хокукый нормалар рөхсәт иткән барлык юнәлешләрне дә балаларга туган телебезне өйрәтүдә файдаланырга кирәк. Бу муниципаль белем бирү оешмаларында да, мәчетләребез каршында да, интернет челтәрендә дә, онлайн мәктәпләрдә дә, хәтта шәхси яисә иганәчеләр ярдәмендә дә туган телдә белем һәм тәрбия бирә торган балалар бакчаларында да, мәктәпләрдә дә оештырырга тиеш. Классигыбыз Гаяз Исхакый әйткәнчә, «Тартышуда гына табарсың үз хакыңны!»

МӨНӘСӘБӘТ

Кешене ышаныч һәм өмет яшәтә

Кешелек дөньясы яңа 2024 елны каршыларга җыена. Ул нинди булыр? Инсаниятне цивилизацион бәрелешләргә этәргән дәһшәтле XXI гасырның беренче чиреген йомгаклый торган алдагы ике елы ил-көнгә нинди үзгәрешләр алып килер? Бер караганда, халык ошбу бетмәс-төкәнмәс кыенлыклардан инде тәмам алҗыды һәм гарык та булды кебек. Икенче яктан, кеше үзенең яшәү рәвешен үзгәртмәсә, алар алга таба әле тагын да артыра мөмкин. Шуңа күрә яңа елга ул әнә шундый борчулы сораулар белән керә. Глобаль кризис шартларында кемгә ышанырга һәм нәрсәгә өметләнергә соң? Ә цивилизацияләр бәрелеше чорында ул сораулар тагын да актуальләшә төшә. Тормыш диалектикасы әлегә әнә шулай дәвам итә.

Ә декабрь ае, сәяси планда һәм халыкара мөнәсәбәтләр ягыннан, Европада иминлек һәм хезмәттәшлек буенча оешма (ОБСЕ) илләре тышкы эшләр министрларының Скопьеда (Төньяк Македония) үткән очрашуыннан башланып китте. Россия тышкы эшләр министры С.Лавров анда, ОБСЕның упкын алдында торуы, аның кысаларында иминлекнең өч юнәлеше буенча булдырылган бар нәрсәнең дә деградация кичерүе турында белдергән. Үзе үткәргән матбугат конференциясендә ул шулай ук АКШ дәүләт секретаре Энтони Блинкенны һәм Европа дипломатиясе башлыгы Жозеп Боррельне куркаклыкта да гаепләгән. Имеш, алар аның белән гадел сөйләшүдән куркып, ул килеп җиткәнче китеп барган. Тегеләре исә моны Россиянең халыкара хокук нормаларын һәм ОБСЕ принципларын бозып үткәргән агрессив сәясәтенә бердәм протест йөзеннән эшләгән. Очрашуда әле Россияне оешмадан чыгару мәсьәләсе дә күтәрелгән. Ә изоляция һәм протест чаралары аңа кадәр дә күрелде. Әйтик, Болгариянең Россия делегациясе утырган очкычны үткәрмәве сәбәпле, Скопьега алар Греция аша очарга мәҗбүр булган. Ә Эстония, Латвия, Литва, Польша һәм Украина кебек илләр, Украинадагы хәлләргә протест йөзеннән, ул очрашуда катнашудан бөтенләй дә баш тарткан.

Көнбатышның Россияне халыкара дәрәҗәдә изоляцияләү омтылышы, аны төрле халыкара оешмалардан читләштерүе дәвам итә. Әйтик, киләсе елга БМОның Халыкара диңгез оешмалары шурасын сайлаганда да (ә анда яшерен тавыш бирү юлы белән 40 ил сайланган) Россия төшеп калган. Аңа карата яңадан-яңа санкцияләр кертү декабрьдә дә дәвам итте. Мәскәү исә, үзенә карата кертелгән чикләүләрне нииндидер ясалма мин-минлек белән кабул итсә дә, халыкара изоляция фактларын бик танырга теләми. Мондый хәл С.Лавровның Федерация Советында үткән «хөкүмәт сәгате» кысаларында ясаган чыгышында да сизелде. Россия президентының Абу-Дабига һәм Әр-Риядкә сәфәрләр кылуына, ә анда аны зур хөрмәт белән, урамны дәүләт флаглары белән бизәп һәм юл кырыйларына ат вә дөяләр тезеп каршы алуларына ишарәләп булса кирәк, парламентта ул: «Курс на изоляцию России потерпел фиаско. Чего только стоят многочисленные контакты президента Путина с зарубежными коллегами», – дип сөйләде.

Әйе, очрашулар Кремльдә дә булып тора. Әмма соңгы ике елда илбашының тышкы сәфәрләре чикләнүе дә хак. Әлбәттә, «акны – кара, ә караны ак итеп» күрсәтә торган һәм ура-патриотлар колагына исәп тотып ясалган андый нотыклар Россиядә хуплап кабул ителә. Ә менә чит аудиторияләрдә инде андый чыгышларга мөнәсәбәт ни сәбәпледер башкачарак. Әйтик, Скопьеда үткән шул ук ОБСЕ очрашуының пленар утырышында ясаган чыгышына да, кемнеңдер тискәре мөнәсәбәтен күргәч, С.Лавров инде түзмәгән, инглиз теленә күчеп: «Сез мине тынычлыкта калдыра аласызмы?», – дип, хәтта бүленергә дә мәҗбүр булган. Тик, хикмәт бит ризасызлык формасында түгел, ә аны халыкара дәрәҗәдә тудырган сәбәпләрдә.

Айның һич «көтелмәгән» вакыйгасы дип, РФ президенты В.Путинның Россия геройларын бүләкләү тантанасыннан соң үткән әңгәмә вакытында, үзенең 2024 елда узачак президент сайлавында катнашырга ниятләве турындагы белдерүен санарга кирәктер. Ә бер көн алдан Федерация Советы, шуны сизгән кебек, 2024 елда Россиядә президент сайлавын 17 мартта үткәрү турында карар кабул иткән иде. Шундый ук оператив сизгерлекне Үзәк сайлау комиссиясе (ҮСК) дә күрсәтте: 8 декабрь көнне, утырыш җыеп, сайлауны өч көн дәвамында – 15-17 мартта үткәрергә карар кылды. Моны ул сайлаучыларга уңайлы шартлар тудыру нияте белән аңлатты. В.Путинга үз кандидатурасын сайлауда күрсәтү үтенече белән мөрәҗәгать иткән зат исә тантанада катнашкан кунакларның берсе – РФ һәм ДНР героеның әтисе булып чыкты.

Әлбәттә, әлеге вакыйга югары даирәләрдә бердәм хуплау тапты һәм ереле-ваклы түрәләр, берсеннән-берсе уздырып, бүгенге кыен чорда моның бердәнбер лаеклы кандидат булуын дәлилли башлады. Хәлбуки, сайлауларга яхшылап әзерләнүләре турында ҮСК рәисе Э.Памфилова да белдерде һәм бу очракта аның белән дә килешергә кирәктер.

Чөнки, чыннан да, илдә ошбу демократия институтын югары дәрәҗәдә имитацияли торган законнар, сайлау системасы һәм сайлау вертикале инде күптәннән булдырылган. Алар нигезендә, сайлауда катнашучыларның аны легитим итә торган минималь бусагасы бетерелгән, бюллетеньнәрдән «Барсына да каршы» дигән графа алынган, илдә хакимияткә реаль оппозиция бетерелгән, сайлауда кандидат булып теркәлү өчен гади кешенең буе җитмәслек киртәләр булдырылган, асылда, хакимият хупламаган затларга кандидат булып теркәлү мөмкинлеге дә бетерелгән. Ә Кремльдә сайланган затка сайлау системасы инде гарантияле сайлану мөмкинлеге дә бирә.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Туксанны тутырды, йөзне куа

Җилкәсенә җитеп торган калын, озын, көлсу чәчләренә караганда, язучы Нури Арслановка да охшаган, журналистикада берничә капчык тоз кимергән Марсель Зариповны да хәтерләтә ул. Миңа калса, галимнәр пелеше ялтырап торган Рәдиф Җамалетдинов кебек ап-ачык маңгайлы булырга тиеш сыман.

Язучы да, журналист та түгел, фольклорыбызның тирән катламнарына төшкән, Ибраһим пәйгамбәр заманында ук туган беренче шигырьнең нинди булуын ачыклаган, борынгы төрки бабаларыбызның эзләрен Якын Көнчыгышта – Газзә туфракларында, Үзәк Азиядә тапкан Казан Федераль университеты галиме Марсель Бакировны әйтүебез.

Марсель ага юбилеен – туксан яше тулуын 10 декабрь көнне якыннарын, якташларын, хезмәттәшләрен, язучыларны, журналистларны чакырып, башкалабызның «Дворянское гнездо» ресторанында бәйрәм иткән иде инде. 19 декабрь көнне хезмәттәшләре аны университетка чакырып, олуг юбилее уңаеннан, студентлары белән бергәләп котлады. Аерым алганда, КФУның филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры Рәдиф Җамалетдинов университет җитәкчелегенең юбилярга, туксан яшьлеге уңаеннан, туксан мең сум акчалата бүләк бирүен җиткерде.

Моның белән генә юбилей тантаналары бетмәде әле. Гыйнвар уртасында галимне туган ягында – Мөслимдә зурлаячаклар.

Йосыф АСЫЛХУҖА.

«Калеб»кә – 10 яшь

«Пирамида» мәдәни күңел ачу үзәгендә «Калеб» яңа буын җыенының 10 еллыгына багышланган тантаналы кичә булып узды. Яшь шагыйрь, язучыларны, җырчы, композиторларны бер-берсе белән таныштырып, уртак иҗат өчен мөмкинлекләр тудыру максатында оештырылган бу хәрәкәт яңа исемнәр ачып кына калмады, сәнгать, мәдәниятебезгә яңа сулыш өрде. Лабораторияләрнең берсендә театраль эскиз буларак иҗат ителгән «Карурман», мәсәлән, К.Тинчурин театрының репертуарына керде. Яшь композитор Миләүшә Хәйруллина Г.Кариев театры спектакльләре өчен музыка иҗат итә башлады. Г.Кутуй әсәренә нигезләнеп куелган «Тапшырылган хатлар» спектаклендәге Галия җыры, мәсәлән, күпме тыңласаң да, тыңлап туймаслык. Һәм мондый мисаллар байтак.

Тантаналы кичәдә «Калеб»не башлап йөргән Луиза Янсуар, Йолдыз Миңнуллина, Эльмир Низамов, Сөмбел Гаффарова, Гөлчәчәк Баһавиева, Рания Усманова һәм, әлбәттә инде, тыңгы белмәс җанлы проектның әнкәсе Гүзәл Сәгыйтовага олы хөрмәт белән телгә алдылар. «Калеб» үскән-ныгыган саен, алар үзләре дә үсте. Гүзәл Рәмзил кызы Сәгыйтова, мәсәлән, бүген Казан шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары булып эшли һәм талантларны барлау эшен яңа алымнар белән биегрәк дәрәҗәдә дәвам иттерә. Казан мэры Илсур Метшин үзе «Калеб» юбилеен оештырырга хәер-фатихасын биргән, матур итеп видеокотлау да юллаган. Күренекле композиторыбыз Резидә Ахиярова, язучы, депутат, Татарстан язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, Г.Камал театры директоры Фәрит Бикчәнтәев видеокотлауларында «Калеб» проектларының зур әһәмиятен билгеләп үтте, киләчәк яшьләр кулында, дип хәрәкәтнең тоткан кыйбласын хуплады.

«Калеб» проектларының саны исә ун ел эчендә җитмештән артып киткән. Бу вакыт эчендә сиксән җыр иҗат ителгән. «Безнең җыр» лабораториясе быел да уздырыла. Гала-концерты язга билгеләнгән. Композиторлар Эльмир Низамов, Миләүшә Хәйруллина иҗат иткән бериш җырларны исә кичәдә җырчылар Илүзә Хуҗина, Илгиз Мөхетдинов, Эльмира Кәлимуллина, Айгөл Хәйри, Алсу Фәйзуллина, Артур Исламов, Эльза Заяри башкарды. Киче буе сәхнәдә дирижер Ильяс Камал җитәкчелегендә «La Primavera» Казан камера оркестры уйнады.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Инкыйлаб корбаны

Революция үз корбаннарын үз сафларыннан ала, дигән гыйбарәне хәтердә яңартуга, күз алдына Сталин репрессияләре корбаны Шамил Усманов образы килеп баса. Хакта, мәшһүр татарлар арасында инкыйлабның беренче корбаны Мирсәет Солтангалиев булган. Аны 1924 елда ук кулга алалар, берничә тапкыр төрмә газаплары кичерткәч, диварга терәп аталар. Бәлки, корбаннар исемлеген 1918 елдан, Ленин тарафыннан кечкенә генә отряды белән аклар кайнап торган Казанга «тәртип урнаштырырга» җибәрелгән Мулланур Вахитовтан башлау дөресрәктер...

Шулай да, әсәрләрен мәктәп дәреслекләреннән үк укып белгәнгәме, Татарстанны радиолаштыручы, оештыручы булгангамы, Шамил Усманов образы безнең заманга якынрак сыман.

Үз язмышын кеше үзе яза. Акчуриннарның туку фабрикасында кырдыручы булып эшләгән 19 яшьлек егетнең беренче җитди гамәле – мулла кушкан Абдулла исемен тау халкының гаярь улы Шамил исеменә алыштыруы ук аның язмышындагы кискен борылышны, революция дулкыннарына ташлануын аңлата.

Каһарман язучыбызның 125 еллыгына багышлап Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында (ТӘһСИ) оештырылган «түгәрәк өстәл»дә тарих фәннәре докторы Илдус Заһидуллин: «Бу ыгы-зыгылы елларның шаукымы кая китереп чыгарачагын дөрес чамалаган әтисе Хәйрулла хаҗи васыятендә улына мөрәҗәгать итеп: «Иманым камил: син, газиз угылым, хаиннәр казыган базга егылып төшкәнче, юлыңны дәвам итмәкче булачаксың... Көчләп тагылган әҗәлең, гавамда яңгырарлык соңгы чараң нәтиҗәсендә, җәлладларга карата соңгы ләгънәтең булсын!» – дип яза. 1937 елны

кулга алгач, Мирсәет Солтангалиевне яклап чыгыш кат-кат исенә төшерәләр; революция вакыйгаларын, гражданнар сугышы бәрелешләрен тасвирлаганда татарларны калку итеп күрсәтә, дип тә гаепләләр», – дип сөйләде ул.

«Ш.Усманов – әдәбият мәйданына турыдан-туры гражданнар сугышы эченнән, совет хакимияте өчен көрәшкән кызыл гаскәриләр арасыннан күтәрелеп чыккан язучыларның берсе. Аның тәүге иҗат тәҗрибәләреннән булган «Канлы көннәрдә» һәм «Беренче адым» драмалары гражданнар сугышының иң кызган чорында – 1919 елда языла һәм кульязма рәвешендә таралып, фронт сәхнәләрендә уйнала», – дип ачыклык кертә институт әзерләгән белешмәлек.

18 декабрь көнне атаклы гаскәри, күренекле язучы, дәүләт эшлеклесе Ш.Усмановның 125 еллыгына багышланган «түгәрәк өстәл» Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтында да үткәрелде.

20 декабрь көнне Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең җыелышлар залында бу уңайдан театральләштерелгән тамаша күрсәтелде (Хәбир Ибраһим сәхнәләштермәсе, режиссеры Лилия Әхмәтова). Анда каһарман милләттәшебезнең гомер юлы сорау алу күренешләре белән аралаштырылып җиктырылды.

Рәшит МИНҺАҖ.

1 нче биттә – Табигать гүзәллеге. М.Сәгыйдуллина фотосы.

Казлар – муллык һәм байлык символы

Милли мәдәниятләр һәм традицияләр елына багышлап, Түбән Кама районының Колмакчы авылында барлык гореф-гадәтләргә туры китереп чираттагы «Каз өмәсе» үтте. Бу бәйрәм – бүгенге көнгә кадәр сакланып калган татар халкының милли гореф-гадәтләрнең берсе.

Муллык һәм байлык символы булган казлар – татарның горурлыгы да, мул табыннарның күрке дә! Сер түгел: каз үстерү күп көч һәм тырышлык сорый. Гомер буе каз, үрдәк өмәләренә йөргән Колмакчының иң уңган кызлары һәм канат сыдыручы балалар бу юлы Нургаян апа Шайхетдинованың туып үскән йортына җыелдылар. Өмәгә килүчеләрне ачык йөзле хуҗабикә, узенең сеңлесе Фирдәүсә һәм кызы Фәйрүзә белән каршы алдылар. Кызлар белән бергә, авылыбыз гармунчысы Рамис Гыймадиев, казларны суеп торучы Ибраһим абый Идиатуллин килде. Гармун моңы астында өмә гөрләде генә... Кем казның йонын йолка, кем баш-аякларын эшкәртә.

«Каз өмәсенең» тагын бер иң кирәкле өлеше – «Канат сыпыру». Балаларга авылыбызның гореф-гадәтләрен, йолаларын өйрәтеп, аларга тапшырып калдыру безнең бурыч. Апалар белән бераз каз йолкыгач, китапханәче Дания икенче бүлмәдә балаларга канат сыдыру йоласын өйрәтүгә керeштe. Аңа ярдәмгә гомер буе татар теле укыткан укытучы Гөлфинә Галимова да кушылды. Өлкән апаларыбыз кызыксынып шушы йоланы күзәтеп тордылар! Балалар бик теләп катнашты, берсеннән-берсе уздырып, тырыша-тырыша канат сыпыру серләрен үзләштерделәр. Канат сыпрып беткәч, апалары чишмәгә казларны юарга төшәргә әзерләнгәндә, балалар белән әйлән-бәйлән, түбәтәй, йөзек салыш, «Кәрия-Зәкәрия» кебек татар-халык уеннары уйналды.

Ә иң күңеллесе авылыбыз уртасындагы, узган ел яңартылган «Инеш» чишмәсенә, көянтәләргә казларны асып, бергәләп, гармун тавышына авыл көйләрен җырлап, казларны юарга бару. Балалар апалары эзләренә, су буена төшкәндә, матур кәрзиннәргә салган, сыдырган канатларны сибеп бардылар. Бу йола икенче елга да казлар күп булып үссеннәр өчен эшләнә. Чишмәдә кызлар казлар юганда, «Җидегән чишмә» җыры яңгыравы, чишмә буендагы шаярулар, кемнең генә яшьлеген искә төшермәде дә, кемнең генә йөрәген жилкендермәде икән?

Чишмәдән кайтуыбызга хуҗабикәләр һәм авылыбызның иң уңган апаларыбыз, телеңне йотарлык тәмле, мичтә пешкән каз бәлеше һәм каз мае белән майлаган беленнәр белән табын әзерләп каршы алдылар. Күңелле, мул табын артында утыруларыбыз җыр-бию, уен-көлке белән дәвам итте.

«Каз өмәсе» күпме истәлекләр калдыра... Мендәре, май канатлары, салкын тигәндә куллану өчен мае, ничәмә елларга җитә...

Шушы бәйрәмне оештыруга күп өлеш керткән, авылдаш егетебезгә, барлык авылдашлар исеменнән зур рәхмәтебезне белдерәбез!

Дания ГАЙФИЕВА.

Көллиятләрдә иҗади яшьләр укый

Казан дизайн һәм технология көллияте базасында һөнәри белем бирү уку йортларының татар телендә иҗат итүче студентлары арасында барган «Көмеш каләм» республика конкурсының йомгаклау туры узды. Татарстан халыклары телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү программасы кысаларында оештырылган һәм милләтебезнең теленә, мәдәниятенә, үзенчәлегенә карата кызыксынуны арттыруга юнәлдерелгән бәйге быел җиденче тапкыр уздырылды. Катнашучыларны Казан дизайн һәм технология көллияте директоры Ирек Даутов сәламләде һәм бәйгедә катнашучы яшьләребезнең төрле һөнәр ияләре булуына карамастан, туган телебездә иҗат итүләрен ассызыклап үтте. «Тегүчеме, эшчеме, чигүчеме, прорабмы, укытучымы, слесарьмы, автомеханикмы, аның саф татар телендә профессиясе турында матур итеп яза, сөйли белүе куандыра», – диде ул. Алдагы елларда конкурсны Казан федераль университеты белән берлектә үткәрергә телиләр.

Быел иҗади бәйгедә Казан, Буа, Чаллы, Алабуга, Мамадыш, Азнакай, Лаеш, Арча, Әтнә, Тәтеш, һ.б. шәһәр-районнарыннан политехника, авыл хуҗалыгы, педагогика, төзелеш, автотранспорт, ветеринария, кече бизнес, энергетика, гражданнар яклавы, медицина, сәүдә-икътисад, авыл хуҗалыгы, нефть химиясе, технология һәм дизайн көллиятләрендә укучы 24 егет һәм кыз катнашты. Алар үзләренең иҗатларын сәхнәдән һәм язмача формада тәкъдим итте. Сәхнәдән чыгыш ясаган студентның нигезендә иҗади материалына, аның тирәнлегенә, жанрга туры килү-килмәвенә, видео һәм фото материаллар куллануына һәм газета-журналларда басылган, социаль челтәрләрдә чыккан материалларына игътибар бирелде. Бердәм Дәүләт имтиханы, бердәм стандарт дигән проектлар уку йортларында русча укытуга китерсә дә, туган телебездә иркен сөйләшә һәм иҗат итә торган яшьләребезнең әле күп булуы аеруча сөендерде. Әйтик, Казан төзелеш, архитектура һәм шәһәр төзелеше көллиятендә белем алучы Раян Шакиров жюри әгъзаларын үзенең образларга бай шигырьләре белән җәлеп итте. Егеттән алга таба танылган татар шагыйрьләренең берсе булыр, дип фаразладык. Казан автотранспорт техникумында белем алучы Габдулла Хәйбуллиннан шәп журналист һәм алып баручы чыгачагына да шигебез булмады. Татар драматургы, язучы, балалар шагыйре, жюри әгъзасы Рафис Корбанов искәртеп үткәнчә, конкурс яшьләребез арасында әле талантлы егет-кызларыбызның булуын, аларның туган телләрендә иҗат итүен дә күрсәтте. «Бүген Язучылар берлегенә тәкъдим итәрлек егетләр бар. Алар белән бераз эшләргә кирәк», – диде ул. Катнашучылар конкурсны оештыруда башлап йөргән Казан технология һәм дизайн көллияте мөгаллиме Гөлфизә Муллануровага рәхмәт белдерде.

Сөембикә КАШАПОВА.

«Ислам – тапталган сукмак түгел»

«Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында Г.Зәбировның «Энциклопедия норм и правил ислама (в свете четырех мазхабов)» дигән китабы тәкъдим ителде.

Әлеге басма энциклопедиянең бишенче тапкыр басылуы икән инде. «Һәр юлы ниндидер мәгълүмат өстәп, әйтик, сорауларга җавап рәвешендә рубрика кертеп, тулыландырып торабыз. Чөнки ислам – тапталган сукмак кына түгел. Мин аны мөселманнар өчен көндәлек кулланма дип исәплим. Җәмгысе тугыз мең данә китап дөнья күрде», – дип сөйләде журналистлар каршында автор.

Чараны алып баручы Рәмис Латыйпов: «Бик саллы хезмәт күренә. Аны чын мәгънәсендә энциклопедия дип исәпләп буламы?», – дип үз чиратында Татар Энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты директоры Искәндәр Гыйләҗевка мөрәҗәгать итте. «Кырыс таләпләр белән якын килгәндә, билгеле, бу җыентык энциклопедия түгел. Әчтәлегенә карагандa, энциклопедик басма. Кайбер тарихи текстларны, тарихи мәгълүматларны энциклопедиябезгә кертеп җибәрә алабыз», – диде ул.

Чара барышында Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты галиме Айдар Хәйретдинов әлеге басманы татарча да күрергә теләвен җиткерде. Ул гына да түгел, ике галим арасында бәхәс чыкты. Тарихчы, «бүген татарча абзар телендә сөйләшәбез, язабыз», дип белдергәч, И.Гыйләҗев, «халыкның гади сөйләм, аралашу теле бар, әдипләребез, зыялыларыбыз куллана торган югары тел бар», дип бу фикер белән килешмәвен җиткерде.

Рәшит МИНҺАҖ.

Үзенчәлекле моң иясе иде



Татар музыка сәнгате зур югалту кичерде – озак авырудан соң 2023 елның 24 декабрендә 72 яшендә Татарстанның халык артисты **Биктаһиров Искәндәр Исмәгыйль улы** арабыздан мәңгелеккә китте.

Биктаһиров Искәндәр Исмәгыйль улы 1951 елның 12 октябрендә ТАССРның Чирмешән районы, Югары Чыгтай авылында туа. Казан дәүләт консерваториясендә профессор З.Хисмәтуллина классында белем ала.

И.Биктаһиров башкаруында халкыбызның моңлы җырлары, татар композиторлары иҗат иткән җырлар халык күңеленә кереп калды, популярлык казанды. Ул аларның һәркайсын үз күңеле аша үткәреп, үзенчәлекле тавыш белән башкара белде. Автор булараk та татар эстрадасы сәнгатен баетуга, үстерүгә зур өлеш кертте. Радио һәм телевидениедә, республикабыз шәһәрләрендә һәм районнарында, милләттәшләребез яшәгән төбәкләрдә, чит илләрдә чыгышлар ясады.

Халык күңелендә үз урынын яулаган мәшһүр җырчыбыз Искәндәр Биктаһировның җырлары яраткан тамашачылары хәтерендә мәңгелек моң булып сакланыр.

Мәрхүмнең туганнарының, якыннарының зур кайгысын уртаклашып, «Мәдәни җомга» газетасы редакциясе.

● 2024 елда Россия бюджетының кереме 35,06 триллион сум, чыгымы 36,66 триллион сум булачак, кытлык 1,6 триллион сум тәшкил итәчәк. Бюджетның 38,6 проценты (14,2 триллион сум) илне саклауга тотылачак: оборона чыгымнарына 10,8 триллион сум, дәүләт иминлегенә һәм хокук саклау эшчәнлегенә 3,4 триллион сум акча сарыф ителәчәк. Татарстан бюджеты исә кытлыксыз кабул ителгән – аның кереме дә, чыгымы да 399,6 шар миллиард сум булачак.

● 2011 елдан 2013 елга кадәр генә дә Кытайда АКШта бөтен XX гасырда кулланылган кадәр цемент җитештерелгән һәм файдаланылган.

● Бик куе һәм баллы кайнар сөтле чәй алкоголь, наркотиклар, дарулар белән агуланганда иң яхшы дәва чараларыннан берсе санала.

● Финляндиядә мәктәпкә укырга керүче балага нибары бер портфель (рюкзак) кына сатып алырга кирәк, калган бөтен нәрсә бушлай бирелә, ашау да түләүсез.

● Кеше тәнендә 6 сантиметрлы кадак ясарлык тимер бар.

Бөтендөнья Татар конгрессы Милли Шурасы 2024 елны «Шәхесләребез елы» дип игълан итте. Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты галимнәре яңа ел башланганын да көтмәде: «XX гасыр татар иҗтимагый галәмендә шәхесләр һәм язмышлар» дигән ике көнлек халыкара конференция уздырды.

Татарны таныткан шәхесләр

Әлеге гыйльми җыелыш күренекле педагог һәм журналист Әхмәтһади Максудиның туууына – 155 ел, Садри Максуди, Гаяз Исхакый, Закир Кадыйриларның тууларына – 145 ел, мәшһүр журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Габдулла Баттал Таймасның туына – 140 ел, Госманлы дәүләтенең танылган икътисадчы галиме Муса Акъегетзадәнең вафатына 100 ел тулуга багышланды. Билгеле, юбилей булу-булмауга карамастан, аларның татар иҗтимагый фикер тарихына керткән өлешләре кимеми.

Бу асыл затларның Әхмәтһади Максудидан калганнары төрек иҗтимагый хәятендә дә саллы урын били, шул сәбәпле алар турында «татар-төрек иҗтимагый фикер тарихына нигез салучылар» дип атау да бик урынлы. Әйтик, төрек милли дәүләтчелек идеологиясен мәйданга китерүгә зур өлеш керткән, Мостафа Ататөрекнең киңәшчесе булып эшләгән Садри Максуди һәйкәл булып Казанына кайтты. Муса Акъегетзадә белән Габделбари Баттал Таймас исемнәре дә зыялы татарларга берникадәр таныш. Конференция барышында үзем өчен кызыклы ачыш та булды: мәшһүребез Гаяз Исхакый хакында Болгар Ислам академиясенең Ислам мирасы үзәге башлыгы Сөләйман Рәхимовтан да мәгълүматлырак белгеч юктыр сыман. Ул Гаяз Исхакый эшчәнлеген архив чыганакларына таянып бәян итте...

Моңарчы Тарих институты хезмәткәре, тарих фәннәре кандидаты Айдар Хәйретдиновны Муса Бигиевнең тормыш юлын һәм хезмәтләрен төпченеп өйрәнүче галим буларак кына белә идек, әмма тынгысыз галим башка фикерияләребезне дә игътибарсыз калдырмый икән. Бу юлы ул татар язучысы, Госманлы дәүләтенең танылган икътисадчы галиме Муса Акъегетзадә мирасын ачып салды. Татар реалистик әдәбиятының атасы (Хатип Миңнегулов билгеләмәсе) дип саналган бу асыл затыбыз яңа заман төрек икътисади фәненә нигез салучы, мәшһүр Сөләймания мәдрәсәсе китапханәсенең (1918 елдан башлап вафат булганчы, 1923 елга чаклы) беренче директоры да икән. А.Хәйретдинов аңлатуынча, аны икътисадчы галим буларак та кабул итәргә кирәк. Ул чиновник, педагог та булып эшли, икътисад фәненнән укыта. Төрек галимнәренең тануынча, Төркиядә икътисад фәне Муса әфәндегә кадәр торгынлык кичерә, Акъегетзадә аңа яңа сулыш бирә.

– Төрек галиме Хәмди Гәнч аның хезмәтләрен югары бәяләп: «Ирекле тиҗарәт нигезләренә корылган заманчыл икътисадның эчтәлеген, методологиясен һәм халыкара тиҗарәтне аңлауга багышланган беренче житди тикшеренү Муса Акъегетзадә тарафыннан башкарылган», – дип яза. Әлеге бәя мәшһүр милләттәшебезнең Төркия яңа заман башы икътисад фәненең чишмә башында торуын күрсәтә, – дип сөйләде А.Хәйретдинов.

Ул заманда, байтак җәдитчеләребез евроцентризм шаукымына бирелеп, түбәтәйләрен җиргә органда, Муса әфәнде ислам динебезне алга сөрә. 1895 елда Истанбулда нәшер ителгән «Аурупа мәдәнияте әсасенә бер караш» дигән хезмәтендә галим бөтенләй икенче яктан ачылган (йөз елдан соң, тәгаен әйткәндә, 1996 елда бу әсәр Әнкарада кабат бастырыла). «Муса әфәнде анда: «Хәтта французлар да Мөхәммәд пәйгамбәрнең әхлагын аңлау дәрәҗәсенә үсеп җитә алмады әле. Әгәр үсеп җитсәләр, эшләре тагын да яхшырак барыр иде. Фән үрләрен яулау, гыйлем алу Европа бездән үзләштергән гыйлемнәрне кире үзебезгә кайтару өчен кирәк», – дип яза. Муса әфәнденең икътисад нигезләрен ачып салган хезмәтләрен өйрәнү бүгенге татар галимнәрендә дә комачауламый, – дип тәкъдим итте ахырда А.Хәйретдинов...

XX гасыр башында татар-төрек галәмендә журналист, язучы, җәмәгать эшлеклесе булып танылган Габделбари Баттал-Таймас турында да конференция барышында байтак мәгълүмат бирелде. Аеруча күңеллесе: гыйльми җыелышта катнашучыларга күптән түгел генә «Җыен» фонды тарафыннан «Шәхесләребез» сериясендә нәшер ителгән «Габделбари Баттал» җыентыгы бүләк ителде.

Шушындый китап дөнья күргән икән, аны һич тә аз билгеле шәхесләр исемлегенә кертә алмыйбыз. Өч телдә – гарәп, татар, төрек телләрендә иркен язган әлеге журналист вә әдип – безнең өчен өлге ул.

– Габдулла Баттал-Таймас шактый озак яшәгән (87 яшь) һәм гомере буе диярлек нәрсәнедер өйрәнгән. 21 яшендә ул – беренче, 86 яшендә соңгы китабын бастыра, ягъни 65 еллык иҗат гомерендә күп мәгълүмат язып калдыра. Аның хезмәтләрен тасвирлау өчен Мисырда, Казанда һәм Төркиядә озак һәм катлаулы тикшеренүләр үткәрү таләп ителә, – дип яза милләттәшебез турында төрек галим Али Биринҗи.

Татар галимнәре, әйтик, Лирон Хәмидуллин Габделбари Батталны 87 түгел, 89 ел яшәгән дип исәпли. «Төркиядә чыккан биографияләрендә 1883 ел саны куелган икән, анысын Россия зинданнарыннан качып киткәндә мәҗбүри рәвештә теркәлгән бер сан дип карарга кирәктер», – ди Лирон ага.

Шунысы кызык: вакытлы матбугаттагы эшчәнлеген Г.Баттал 1905-1908 елларда Каһирә шәһәрендә, гарәп телендә башлый. «Әл-Җаридә» «Әл-Манар», «Әл-Мукаттәм» журналларында язышa. 1908 елны ул Каһирәгә килеп «Әл-Нәһза» газетасы чыгаруга керешкән Исмәгыйль Гаспралының тәрҗемәчесенә әйләнә. Аның мәкаләләрен гарәп теленә тәрҗемә итеп тора. Россиягә кайткач һәм һиҗрәткә киткәнче (1908-1921 еллар аралыгында) «Вакыт», «Йолдыз», «Алтай», «Маяк», «Корылтай» газеталарында, «Шура», «Мәктәп», «Сөембикә» журналларында бик күп мәкаләләрен бастыра. Хәтта каләмдәшебез әлеге «Йолдыз», «Корылтай», «Алтай», «Маяк» газеталарының редакторы да булып тора. 1925 елны Төркиягә килеп урнашуыннан башлап 1968 елга кадәр, 43 ел дәвамында әдип бик күп төрек газеталарында һәм журналларында мәкаләләрен бастыра. 1903 елда Казанда басылган «Акмулла» китабыннан башлап 1968 елда дөнья күргән «Kazanli Dilci Cemal-ud-din Velidi ve Eseri» мәкаләсенә (Turk Kulturu, sayi (Mart 1968) кадәр үткән әлеге 65 бәрәкәтле елда төрки дөньяда аның кебек актив иҗат иткән башка журналист-язучыны табып булмый, ди белгечләр.

Рәшит МИНҺАҖ.

«Сез иң гүзәл кеше икәнсез!»

2023 ел – Россиядә Укытучылар һәм остазлар елы уңаеннан «Казан утлары» журналы редакциясе Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән каләм ияләре һәм мәктәп укучылары арасында «Сез иң гүзәл кеше икәнсез!» әдәби бәйгесен игълан иткән иде. 20 декабрь көнне «Татмедиа» АҖнең җыелышлар залында бәйгегә йомгак ясалды, җиңүчеләргә бүләкләр тапшырылды.

Чара башланыр алдыннан «Татмедиа» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Шамил Садыйков җыелган халыкны «Татмедиа»ның яңа проектлары белән таныштырды, аерым алганда, ул анда «тора-бара татар теленең киләчәге ясалма интеллекта, безнең шушы мөмкинлекне ничек файдалана алуыбызга бәйле булачак» дип белдерде.

Конкурста урыннар түбәндәгечә бүленгән. «Хикәя» номинациясендә: I урын – Ркаил Зәйдулла, «Кани калды нишапур»; II урын – Гөлүсә Батталова, «Чыра»; III урын – Әнисә Зәйнуллина, «Очрашу». Кызыксындыру премияләре: Алия Мөбарәкшина («Таң сызылганда»), Айзилә Сабирова («Минем яраткан, усал укытучым»), Наил Шәфигуллин («Шагалиев шәүләсе»).

Повесть номинациясендә: I урын – Әлфирә Галиева, «Сары атым алтын нукталы»; II урын – Асия Юнысова, «Сылукай»; III урын – Гөлинә Гыймадова, «Усал»; Кызыксындыру премияләре: Нурания Гыйльметдинова («Мөнбәрле мөгаллим»), Гөлназ Нуриева («Бәзәкә тавы»), Сания Әхмәтҗанова («Сабыр сөю сагышы»).

Шигырь номинациясендә: (мәктәп укучылары арасында): I урын – Назлыгөл Гайнетдинова, «Укытучыма мәдхия»), II урын – Рәдиф Миңнеханов, «Сез иң гүзәл кеше икәнсез!», III урын – Әмир Фәрхуллин, «Бөек син». Кызыксындыру премияләре: Аяз Батталов («Телимме мин укытучы булырга?»), Камилә Демидова («Укытучыма»), Раил Мәрданов («Укытучыма» Такташка тәкълид).

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәисе урынбасары, әлеге Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов конкурсны югары бәяләде; һәм тантана ахырында, әлеге хикәя, повестьларның каһарманнары исән булса, тамашачылар, укучылар бу әсәрләрнең реаль җирлеген, кемнәргә багышлануын күрсен, ишетсен иде, дигән теләген җиткерде. Монысы инде радио-телевидение җитәкчеләре колагына.

Талантлылар төбәгеннән

(Факил Сафинга 70 яшь тулу уңаеннан)

Мөслим төбәге талантларга бай. Әдәбият өлкәсендә кабатланмас иҗатлары белән танылган Х.Әюп, Зөлфәт, Ф.Садриев, Д.Заһидуллина, Ф.Латыйфи, Н.Гамбәр, Л.Лерон, Э.Шәрифуллина, Ш.Җиһангирова, һ.б. кебек милләтебезгә хезмәт итүче шәхесләр җәмәгатьчелеккә яхшы таныш. Алар арасында мәртәбәле урынны әдәбиятның проза, шигърият, балалар әдәбияты, публицистика өлкәсендә бердәй уңышлы иҗат итүче, актив җәмәгать эшлеклесе Факил Сафин алып тора.

Факил Сафин – зыялы инсан буларак әдәби һәм иҗтимагый эшчәнлеген төрле юнәлештә гаять киң җәелдергән шәхес. Нинди генә хезмәт башкарырга туры килмәсен (ул укытучы, мәктәп директоры да, заводта слесарь-җыючы, мастер да була, журналистлык эшчәнлеге белән дә киң танылa), тормыш аны татар әдәбияты белән тыгыз бәйләнештә яшәтә.

Мөслим төбәгенең Әмәкәй авылы тумасы Ф.Сафин, чордашлары кебек үк, яшьтән тормыш арбасына җигелә. Мәктәп елларында колхозда күптөрле эшләр башкарган малай, урта мәктәпне тәмамлагач, шоферлыкка укый һәм хезмәт юлын башлап җибәрә. Армия сафларында Ерак Көнчыгыштагы чик буе гаскәрләрендә хезмәт итә. Аннан кайткач, туган ягында комсомол секретаре, мәдәният йорты директоры кебек эшләрдә чыныгу ала. Югары белем алу теләге аны Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә китерә. В.Хаков, М.Мәһдиев, С.Ибраһимов, Р.Ганиева, Ф.Сафиуллина, М.Бакиров һ.б. остазлардан белем алган яшь белгеч киләчәген мәктәп белән бәйләргә уйлый. Мөслим районындагы Октябрь, Әмәкәй, Татар Бүләре мәктәпләрендә укытучы, мәктәп директоры булып эшли, Чаллы шәһәренең 24, 18 мәктәпләрендә тарих фәннәре укыта. Әмма илдәге иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр дулкынында Ф.Сафин милли-мәдәни тормышка чума. Гадел сүзгә, объектив бәягә сусаган халык ихтыяҗына нисбәтле бер-бер артлы газета-журналлар пәйда булган 1990 елларда ул Чаллыда чыга башлаган «Таң йолдызы» газетасында баш мөхәррир урынбасары, «Аргамак» журналында җаваплы сәркатип, соңрак «Фән һәм мәктәп», «Мәйдан. Чаллы» журналларын оештыручы һәм аларның баш мөхәррире кебек вазыйфалар башкара. Берара Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары буларак хезмәт итә. Гаилә хәлләре буенча янә Чаллыга кайтып, «Рухи мирасны өйрәнү» төбәк фәнни-методик үзәген оештырып, җитәкчесе булып эшли башлый. Язмыш кабат аны журналистикага китерә – озак еллар «Көмеш кыңгырау» газетасында баш мөхәррир, аннан «Мәйдан» журналында баш мөхәррир урынбасары хезмәтен башкара. Бүгенге көндә ул Язучыларның Яр Чаллы бүлеге җитәкчесе, өстәвенә Бөтендөнья татар конгрессының Яр Чаллы җирле оешмасының дилбегәсен дә аңа тапшыралар.

Мәктәп елларында ук шигырьләр, эпиграммалар язу белән мавыккан малай, тәҗрибә туплауга, әдәби иҗат серләренә ныграк төшенә бара. Тормышка, илдәге үзгәрешләргә, яшәеш сорауларына бәйле уй-фикерләре чәчмә яисә шигъри тезмә булып кәгазьгә төшә. Иҗат җимешләре белән газета һәм журналлар аша укучысын таныштырып килгән яшь авторның «Соңгы көз» (1992) һәм «Тузганак чәчәге» (1994) җыентыклары басылып чыгу шатлыклы күренеш була. Каләмдәшләре К.Сибгатуллин, Зөлфәт, М.Әгъләмов, М.Вәлиев, Ф.Мөслимова, И.Сафуанов, Р.Сибат билгеләп үткәнчә, әлеге китаплар татар әдәбиятына үз стиле чарланып килгән талантлы әдип килүен хәбәр итә. Алдагы елларда Ф.Сафинны әдәби процессның алгы сафына чыгарган, кыю рәвештә әдәби-эстетик эзләнүләр алып баручы язучы итеп таныткан әсәрләре дөнья күрә: «Гөлҗиһан» (1998), «Биек тауның башларында» (1998), «Сәфәр» (2002), «Саташып аткан таң» (2003), «Тулганай» (2007), «Шәүлә» (2008), «Галәм күзе» (2011), «Шигырьләрнең кирәк чагы...» (2011), «Былбыл оясы» (2013), «Сер» (2021), «Күкләр җиргә тоташкан» (2022), «Иман шарты» (2023). Боларга монографияләрне өстәп күп санлы хикәяләрне, балалар өчен язган дистәгә якын китапларны, газета-журналларда басылган фәнни-гамәли мәкаләләрне дә өстәсәк, шактый бай әдәби багаж барлыкка килә. Тагын аның иңсәсендә никадәрле оештыру мәшәкатьләре, җәмәгать эшләре...

Факил Сафин – беренче чиратта, проза остасы. Сүзгә талымлыгы, яшәеш сорауларын уңышлы тотып алуы һәм вакыйга-күренешләр аша бөтен каршылыгында күз алдына бастыруы, герой характерын ачканда сәбәп-нәтиҗә бәйләнешенең ныклы булуы, милли, тарихи, сәяси, иҗтимагый катламнарны уңышлы үреп баруы кебек үзенчәлекләр әсәрләренең яратып укылуына китерә. Әдипнең барлык әсәрләре үз укучысын табып, аның юлдашына, фикердәшенә әверелде. Шулай да язучының иҗат биеклеген күрсәтүчеләре булып «Гөлҗиһан» повесте һәм «Саташып аткан таң» трилогиясе тора. Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булган әлеге әсәрләр, гомумән, татар әдәбияты казанышы буларак бәяләнә. Язучы халык язмышын үзенчәлекле типлар аша чагылдыруга килә. Ф.Сафин бу әсәрләрендә сюжет кору остасы булып танылa. Серле һәм каршылыклы, мавыктыргыч һәм катлаулы, шул ук вакытта гаять тормышчан сюжеттагы хәл-күренешләр укучы күңелендә урын ала, уйландыра, тормыш куйган сорауларга җавап эзләргә этәрә. Еш кына үз әсәрләрендә тарихи үткәнебезгә мөрәҗәгать итә. Шунысына игътибар итәргә кирәк, Ф.Сафин үткәнне язган кебек, әмма гамьле укучы тиз төшенә – ул бүгенге көн язучысы, аның әсәрләрендә бүгенге көн вакыйга-күренешләренә параллельләр үткәрелә, әсәрләренә күпкатламлылык хас, бары тик андагы сурәтләнгән һәр нәрсәне күңел аша үткәреп, аңлый алу мөһим.

Әдипнең «Саташып аткан таң» роман-трилогиясе вакыйгалар катламы, кабатланмас геройлары, аларның тормышта прототиплары булу, фәлсәфи нәтиҗәләре белән җәлеп итә, соклану уята. Автор XX гасырның беренче яртысында ил-халык тормышында булган вакыйгаларны Әхмәтсафа Дәүләтьяров һәм Рабига Сарымсакова эш-гамәлләре аша сурәтли. Эзлекле рәвештә чор һәм шәхес концепциясе калкып чыга, шуның аша 1930 еллардагы катлаулы дәвернең әдәби сурәте тудырыла. Роман тарихи нигезе белән көчле: шул чорның безгә билгеле кешеләре, күпсанлы документлар үзгә мохит тудыра, шунда укучыны яшәтә, хакыйкать эзләүгә китерә.

Ә.Дәүләтьяровның бөтен тормышы укучы күз алдыннан үткәрелә. Автор аны һич тә идеаллаштырмый, бәлки ялгышулар аша халкына хезмәт итү теләге белән янып яшәүче олы шәхес итеп сурәтли. Ул – үзенең бөтен акылын, белемен, сәләтен татар халкының матур киләчәге өчен көрәшкә багышлаган олпат зат. Кызганыч ки, бик күпләр кебек, үзе дә төзергә булышкан системаның корбаны була. Әлеге тарихи шәхес фаҗигасе татар милләте фаҗигасе булып калка. Шунысы игътибарга лаек, язучы ул дәвернең танылган кешеләре образларына мөрәҗәгать итә, кайберләре чын кеше булып бу дөньядан үтсә, икенчеләре хурлык, түбәнлек баскычына атлый. Әмма автор аларга кара тамга сугу юлыннан китми, бәлки шул хәлләрдән, афәттән сабак алырга чакыра. Романда каршылыклы иҗтимагый тормыш калка, милләт язмышы белән бәйләнештә аерым шәхесләрнең эш-гамәле бәяләнә. Автор шул вакыйгалар аша уйланулары белән уртаклаша, укучыны әхлакый һәм фәлсәфи гомумиләштерүләргә алып килә. Әсәрнең исеме дә күпмәгънәле метафора буларак, табигать күренешенә нисбәтле шул чор җәмгыятенә, системага бәя булып яңгырый.

Ф.Сафин коеп куйган шагыйрь дә бит әле. Тәнкыйтьчеләр тарафыннан бирелгән бәяләмәдә, әдипнең татар поэзиясендәге традицион романтизм юнәлешен дәвам иттерүче булуы, шулай ук үзенчәлекле романтик фикерләве белән хәятне әдәби сурәттә яңадан торгызуда яңачалыкка ирешүе ассызыклана. Шигъриятендә дә күпкатламлылык өскә чыга, суфичыл образларга мөрәҗәгать итүе, тормыш күренешләре һәм яшәү циклларын фәлсәфи күзлектән бәяләве, ниһаять, татар шигъриятенең жанр мөмкинлекләрен киңәйтүгә өлеш кертүе – дүртьюллыклар, бишьюллыклар, поэмалар, поэма-эскизлар, шигъри цикллар, балладалар, сонетлар – аерым игътибарга лаек. Аталган кайбер жанрлар, мәсәлән, сонет татар әдәбиятында аз эшкәртелгән, сонет жанрында көчләрен сынап караучылар да еш кына, тәнкыйтьтә әйтелгәнчә, сонет шәкелендәге шигырь иҗат итәләр. Ф.Сафин бу яктан да уңышка ирешә: шушы жанр таләпләрен тулысынча үзләштергән әсәрләре белән безне сөендерә.

Ф.Сафин иҗатының әһәмиятле өлешен балалар әдәбияты тәшкил итә. Алар нигездә кече яшьтәге балаларга адресланып язылган. Повесть, хикәяләрнең, әкиятләрнең, шигырьләрнең эчтәлеге дә, формасы да шушы яшьтәге балаларга туры килә. Шигырьләрендәге лирик герой – әти-әнисенең, әби-бабасының мәхәббәтен белеп, тоеп үсүче, хезмәт кадерен белүче, туган ягын һәм телен яратучы бәхетле бала. Аның күңеле китап укыганда җылына, ул олылар белән бергә өмәдә катнашуы белән горурлана, хезмәтнең тәмен һәм әһәмиятен белеп үсә, табигатьнең сихри манзараларына соклана, әтисе уйнаган дәртле гармун көенә матур итеп бии, кояш гөлгә үрелгәндәй туган теленә тартыла. Мондый лирик герой җәмгыятебезне ялган кыйммәтләрдән арынып, ата-бабаларыбыз кушканча яшәп алгарышка бару юлын күрсәтә.

Гомумән, Ф.Сафин иҗаты татар әдәбиятында яңа сүз, җитди казаныш булып яңгырый: бердән, автор якындагы тарих сәхифәләре аша заманча яңгырашлы әсәрләр иҗат итә; икенчедән, гаҗәеп бай интригалы вакыйгаларда шул чорның үзенчәлекле типларын мәйданга чыгара; аннары шәхесләр язмышы аша халык язмышын чагылдыра, аның үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында уйланырга этәрә; катлаулы чор күренешләрен сурәтләп, әхлакый һәм фәлсәфи гомумиләштерүләргә, җитди уйлануларга, нәтиҗәләр ясауга китерә. Ф.Сафин татар шигъриятен романтик фикерләүдә яңача алымнарга, формаларга мөрәҗәгать итү мөмкинлекләрен ача, татар балалар шигъриятен әхлакый кыйммәтләр, милли үзаң тәрбияләүдә зур куәткә ия булган әсәрләр белән баета.

Татар милләтенең бүгенгесен, киләчәген кайгыртып яшәүче тынгысыз җанлы галим, шагыйрь, прозаик, Тукай бүләге иясе, Г.Исхакый, А.Алиш исемендәге әдәби премияләр лауреаты, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты, милләтнең асыл заты булган Факил Сафин безне яңа иҗади казанышлар белән дә сөендерер әле.

Фәридә ГАБИДУЛЛИНА,
филология фәннәре
кандидаты.

ЯҢА ЕЛНЫҢ ТӘҮГЕ КАРЫ

И сибелә, и сибелә! – ап-ак дөнья – кар ява.
Яңа елның тәүге кары, һәр бөртеге өр-яңа!
Шул аклыкны җанга алып, сөеп кочасы килә.
Карлар сыман бөтерелеп, уйнап очасы килә.
Алгысына ак күңелем, җилләренә уралам.
Яңа елның ак карына оеп ята урамнар.
Яңа елның ак сулышын урманнар, кырлар тоя.
Бу аклыкка киң дөньяның бөтен рәхәте сыя.
Ак кар сыман ак теләкләр бөтерелә күңелдә.
Яңа ел ул – ак өметләр, җан аклыкка күмелә.
Ак кар булып яусын бәхет, чит итмәсен беркемне.
Көтелмәгән куанычлар каксын ишек беркөнне.
Көтелмәгән буламыни?! – көтә-көтә арыган,
Бетмәс кодрәт, дәрт алабыз Яңа елның карыннан.
Борчылулар, пошынулар калсыннар иске елда.
Чир-вируслар чәнчелсен, тәмам туйдырдылар ла!
И сибелә, и сибелә, кар өелә көшелгә.
Миһербанлы булсын бу ел илгә-көнгә, кешегә!

Факил САФИН

Җыры аның күптән җырлангандыр, Ташлап китте язмыш корабы...

УЙ

Бәйләт әйдә,
Бәйләт күңелем күзен,
Киләчәкне күрмәсен дисәң...
Х. Туфан

Әрни-әрни җан сызлана, тынар иде бәйләсәң.
Бәгырь, куллар катылана. Җирне йөз кат әйләнсин син –
Җылы куллар юк шул янда, табылса – буе җитмәс.
Ипсез илдә бәгырь яна, ярасы киртләч-киртләч.

Җирне йөз кат әйләнерсең, тирәнәер яралар,
Ил өстендә һаман да төн, кара җәймә тарала.
Татар җанын ыргыталар кисәкләп телем-телем...
Әрнүләрем чигенерләр, урмандай басса илем.

Канун дисәң – кануны юк, закун дисәң – закуны...
Кемгә бакма – шома пүлән, кавем – каен утыны...
Эчтән кеөп, эчтән янып, күпме чыдарсың, халкым,
Түбәләрне каерып атып, бәреп чыгармы ялкын?..

«Тел димәгез, көн димәгез!» – янаучы тамак кыра.
Калай таккан наместниклар бармагын янап тора.
«Без китәбез, сез каласыз...» Үзгәрде ул, карасак:
Телне тешләп кан суыра – татар җаны гарасат...

«Бәйләт әйдә, бәйләт әйдә, бәйләт күңелем күзен».
Тавышым барып җитмәсә, җитәчәк шигъри сүзем!
Чалкан яткан айга карап, их, бер улыйсы килде...
Ходай биргән дөньясында Бүре буласы идек...

Бүре буласы идек тә: нәселебез – Ак Бүре...
Безгә булырга язмаганмы ошбу җиһанның түре.
Тел биргәнгә – ил бирмиләр, тоттыралар шымытыр.
Кабатлыйлар: «бар да әйбәт, күзләреңне йомып тор!»

Бәйләтмик әле, бәйләтмик, бәйләтмик күңел күзен...
Болыт мәңге каплап тормас, ачылыр ул күк йөзе!

ТУГАН ТЕЛЕМ

Кубарылды дәвер, яңа гасыр! –
Тар базлардан чыктык шикелле.
Коллык чиген үтеп барган чакта
Тагын өскә ташкын ишелде.

Туган телне, җаннан суырып алып,
Фәрман белән илдән сөрәләр.
Каһкаһәләп сөенәдер җаһил,
Бармак төртеп бездән көләдер.

«Туган телем, димсез? Беркем тыймый! –
Сөйләшегез өйдә туйганчы!»
Җегәр бетеп, димәк, егылганчы,
Телдән калып, аңны җуйганчы...

Без еш кына горур тотып башны,
Меңьеллык, дип, сөрән салабыз.
Иман төсе – Туган телебездән
Тел яшереп коры калабыз.

Аллаһ безгә Ана теле биргән!
Туган тел ул – бөек хәзинә.
Кавемдәшләр теләп ваз кичәләр,
Намус, оят юкмы әз генә?..

Җирне, күкне бар иткәндә Аллаһ
Һәр кавемгә изге тел биргән.
Үз телеңнең газиз иясе бул!
Вәхий әйтеп безгә җан өргән.

Туган тел – ул Аллаһыдан иңгән!
Туган тел – ул Иман орлыгы!
Туган тел – ул Әнкәемнең рухы!
Туган тел – ул минем барлыгым!

ВАКЫТ

Килер бер көн – вакыт чаңы сугар.
Н. Гамбәр

Вакыт кирәк алсуланып таң атсынга,
Чыгар юлга, җан яшәтер җылыга да.
Вакыт көтеп үтеп бара ничә гасыр,
Вакыт җитми телгә, сүзгә, җырыма да.

Вакыт кирәк изге сүзне ишетергә,
Вакыт кирәк эш итәргә, иш итәргә.
Вакыт кирәк килергә дә, китәргә дә,
Хыялый бер морадыңа җитәргә дә.

Вакыт кирәк үзең белән килешергә,
Вакыт кирәк хакыйкатькә төшенергә.
Вакыт кирәк сәгадәткә ирешергә,
Вакыт кирәк тау-кыялар ишелергә.

Вакыт кирәк чаңнар булып сугылырга,
Моңга тулып, сазлар булып сызылырга.
Вакыт кирәк көмеш чыкта коенырга,
Вакыт кирәк орлык булып коелырга.

Эш яме юк, кыйммәте юк чын хезмәтнең,
Сүз тәме юк, кадере юк бар өммәтнең.
Җил искәндә бер урында чаба кылган,
Чигенгәндә кем дә чапмый әләм болгап...

Сазлар булып сызылыр чак үтә-китә,
Вакыт чаңы сугар чакны кемнәр көтә?
Офык буйлап күк түренә очкын сибеп
Бер вакытсыз киткән җаннар... меңнәр үтә.

Вакыт кирәк яңа туган сабыйга да –
Гамь керсенгә аның керсез күңеленә.
Вакыт кирәк һәммәсенә, һәрнәрсәгә,
Вакыт эзли бар кешелек бүген мөнә.

Галәмендә тирбәлә Җир – бәллү-бишек,
Кәрәм дисәң, чыгам дисәң, ачык ишек.
Вакыт җитми... Зарланадыр карты, яше...
Вакыт җитми! Гомер сүтә җирдә кеше.

СОҢГЫ ТАТАР

«Мин калырмын җирдә соңгы
татар булып...»
Р.Юныс

Кораб китә. Палубада халык...
Ярдагылар кала ут йотып.
Киткәннәрнең ярда эшләре юк,
Кораб алды сүрән кычкыртып.

Кораб кысан, китеп баручылар
Урнашканнар урын бүлешеп.
Палубадан куллар изи алар,
Калганнарга карый көлешеп.

Татар ярда калды. Тагын шулай...
Урын җитми уртак табында.
Дәүләте дә китте, чик ишелде, –
Озатулар сеңгән канына.

Теле китеп бара, томаналык
Бу кавемнең миен ашаган.
Татар бит ул үзен-үзе яккан,
Киләчәген суга ташлаган.

Үз куллары белән тотып биргән,
Патшасын да, денен, иманын.
Җиңелгәндә гаеп. Хакыйкатьне
Бүгенгәчә татар тоймады.

Кораб китә. Киләчәккә ишә.
Ак дулкыннар сагыш кузгатты.
Соңгы татар ярда. Ул бирәсен бирде,
Озатасын күптән озатты.

Ә башында уйлар өермәсе,
Уйлар йоткан бөтен булмышын.
Дәүләт тоткан кавем...
Әләм, гимн –
Юанычы калган тормышның.

Ул төзүче иде. Җир йөзенә
Мәңгелеккә килгән яралып.
Шәһәрләрен килеп җимерделәр,
Авыллары бетте таралып.

Болай үзе җебегән дә түгел,
Әвәләнмәгән дә камырдан.
Яраклашты илдә һәммәсенә,
Яраклашкан саен
Ераклаша барды тамырдан.

Яшәлдеме җирдә? Тарихында
Ни генә юк әгәр карасаң?..
Ул давылны үзе чәчеп урды,
Тыныч көнен итте гарасат.

Зәгыйфьләнде, тәссезләнде иле,
Җиргә калды имән идәне.
Күршеләре аны таладылар
Йолыккандай печән кибәнен.

Татар кушып санын арттырдылар,
Җире бетте, җырын урлыйлар.
Бармак төртеп аны гаеплиләр,
Аяк тибеп аны хурлыйлар.

Килмешәк ул, имеш, дөньясында,
Тикшерделәр кат-кат канын да.
Тау кадәрле язган тарихы бар,
Җилләр уйный татар аңында...

Ярда калган татар. Күкрәгендә
Йөрәк тибә – чутсыз яралы.
Җыры аның күптән җырлангандыр,
Ташлап китте язмыш корабы.

Болай үзе тере сыман иде,
Йокыга да исе китмәде.
Үзе һәрчак алгы сафта булды,
Күкрәп үсте кырда икмәге.

Яуга дисәң – ул беренче инде,
Ярып узды утын-ташкынын.
Үз өнендә тотып дөмектерде
Илгә кергән каһәр баскынны.

Таш атканга ашын бирә килде,
Таптаганның сөртте аягын.
Киләчәккә кораб озата ул,
Җиргә төртеп ипсез таягын.

Ярда читендә бүген... Озатты ул
Бөтенесен, инде барсын да.
Чал дулкыннар ярга бәреләләр,
Соңгы татар... язмыш каршында...

РЕДАКЦИЯДӘН. Танылган язучы һәм шагыйрь, Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе, филология фәннәре кандидаты Факил Сафинга шушы көннәрдә 70 яшь тула. Без каләмдәшебезне күркәм гомер бәйрәме белән ихластан тәбрик итәбез, аңа исәнлек-саулык һәм яңадан-яңа иҗат куанычлары теләп калабыз.

Михаил Худяковның

Быел Михаил Худяковның «Очерки по истории Казанского ханства» китабы басылып чыгуына 100 ел тулды. Бу китап, чын мәгънәсендә, Михаил Худяковның гомер китабына, визит карточкасына әйләнде. Ә бит ул татарлар турында 60 тан артык фәнни хезмәт язган һәм шуның өчен атып үтерелгән кеше! «Очерки по истории Казанского ханства» китабын язганда Худяковка әле 30 яшь тә булмый, һәм бу китабын язарга ул, мөгаен, гомер буе әзерләнгәндер... Малмыжда татарлар арасында яшәү, балачактан Казанда, гимназиядә һәм университетта уку, татар галимнәре белән дус булу, телебезне, халык авыз иҗатын, динебезне, гарәп язуын белүе аны милләтебезгә тагын да якынайткандыр...

М.Худяков әле студент вакытта ук, 1914-1915 елларда Шәһре Болгарда һәм Биләрдә археологик экспедицияләрдә катнаша, болар турында матбугатта фәнни мәкаләләр яза. Әмма 3 нче курста укыган чакта, 1916 елны, ул хәрби хезмәткә алына һәм университетта укуын 1918 елда гына тәмамлый. Ә 1918-1923 елларда үзенең гомер китабы булачак Казан ханлыгы турында фундаменталь хезмәтен яза. Бу елларда ул әле каторжан кебек эшли дә – мәктәптә, Археология һәм этнография институтында укыта, энесе Иван белән Малмыж музеена нигез сала, шулай ук Үзәк музейда тарих бүлеге мөдире булып эшли. Ул шулай ук халыктан тарихи мирасны җыю, туплау белән дә шөгыльләнә, күргәзмәләр оештыра, 1923 елда «Общество Татароведения» оешмасына нигез салучыларның берсе була, аның секретаре булып эшли. Шушы вакыт эчендә ул ТАССРның археологик картасын төзи, Болгар буенча юлкүрсәткеч яза, халык алдында татар тарихы буенча вакыйга булырлык докладлар укый. Шуңа күрә, ислам дине кабул ителүнең 1000 еллыгы буенча төп хезмәтләрне һәм Казан ханлыгы тарихын М.Худяков язуы очраклы хәл түгел, чөнки бу теманың төп белгече ул була.

Идел буенда рәсми рәвештә ислам дине кабул ителүнең 1000 еллыгы уңаеннан, матбугатта М.Худяковның ике зур фәнни хезмәте басылып чыга. Ул аларны язганда үзе үк туплаган бай материалдан файдалана. Худяковның 1922 елда дөнья күргән хезмәтләре – «1000-летие мусульманской культуры в Поволжье» (Вестник просвещения, 1922, №1-2) һәм аерым китапчык булып чыккан «Мусульманская культура в Среднем Поволжье» (Казань, 1922) язмалары үзләре аерым өйрәнүгә лаек, чөнки аларда, рус тарихында беренче тапкыр, ислам диненә, Идел буенда яшәүче болгар-татар халкына зур бәя бирелә. Идел буенда яшәүче болгар-татарларның ислам мәдәнияте турында язган мәкаләләрен Михаил Худяков «Очерки по истории Казанского ханства» китабына кертми, чөнки аның бу хезмәте татар ханлыгының сәяси һәм дәүләти тарихына багышланган була. Бу китапның язылу чоры бик авыр чорга туры килә – ике революция, хакимият һәм идеология алмашыну, гражданнар сугышы, ачлык... Ә яшь галим шул вакытта Казан, Питер һәм Мәскәү архивларында утырырга, тамак туйдырырлык эшләргә һәм яшәргә дә тиеш була. Шуңадыр, ул гаиләм корырга да ашыкмый, бөтен вакытын, акылын һәм көчен фәнгә бирә. Бу китабын язганда матди яктан зур кыенлыклар кичерүен ул хезмәтенең кереш өлешендә үзе дә әйтеп үтә. Шуны күздә тотып булса кирәк, 1922 елның 19 октябрендә Татнаркомпрос Худяковка «Очерки по истории Казанского ханства» китабын язу өчен 20000 сум күләмдә премия бирә. Шул ук вакытта Академ Үзәктән М.Худяковның бу хезмәтенә фәнни бәя бирүне сорыйлар, бу эш татар галимнәре Г.М.Максудовка һәм А.С.Сәйфигә тапшырыла.

М.Худяковның «Очерки по истории Казанского ханства» китабы 1923 елның көзендә басылып чыга, бу китапка ихтыяҗ бик зур була, бигрәк тә татар зыялылары аны сөенеп каршы ала, чөнки ул күптән көтелгән тарихи дәреслек була. Шушы ук елның 25 июнендә Худяков Казан халкы, интеллигенция алдында «Борьба Казани с Москвой» дип аталган темага фәнни доклад ясый, бу исә аның тарафдарларын тагын да арттыра. Китап дәүләт нәшриятында нибары 1000 данә басылып чыга һәм бик тиз таралып бетә. Казан ханлыгы турындагы бу тарихи китап 302 биттән тора, ул алты зур бүлеккә, 62 кечкенә бүлекчәгә бүленгән, бу исә катлаулы тарихи материалны кабул итүне шактый җиңеләйтә. Бу китапны язганда М.Худяков 169 фәнни хезмәт файдаланган, алар арасында татар авторлары да шактый, чөнки ул татар телен дә, гарәп имлясын да яхшы белгән.

Худяковның бу китабы нәкъ үз вакытында дөнья күрә – иртәрәк язылган булса, аны патша хөкүмәте чыгармас иде, утызынчы елларда исә совет цензурасы рөхсәт бирмәс иде. Казан ханлыгы турында бу уникаль китап чорлар кучешенә, идеологияләр алышынган вакытка туры килә. Яшь галим бу мөмкинлектән тулысынча файдалана һәм моның өчен соңыннан гомере белән түли... Китап басылып чыгу белән, аның тирәсендә шау-шу кузгала, бигрәк тә рус интеллигенциясе Худяковның бу китабын тәнкыйтьләп каршы ала. Танылган галимнәр Н.Н.Фирсов, С.И.Порфирьев яшь галимне тарихи фактлар белән артык иркен, үзенчә эш иткән, Казан ханлыгында урыс хәрби тотыкларының кол хәлендә яшәүләрен язмаган, бу темага моңа кадәр язганнарның фикеренә колак салмаган өчен тәнкыйтьли.

Әмма һәр галимнең тарихи фактларга үз бәясен бирергә дә тулы хакы бар! Чыганаклар мәсьәләсендә дә Худяковны тәнкыйтьләүчеләр арттырып җибәргән, чөнки бу китапта урыс елъязмалары һәм «писцовая книгалар» да, «Казан елъязмасы», «патша китаплары», тарихи актлар, Курбский хатирәләре, Лызлов, Карамзин, Соловьев, Паллас, Рычков, Смирнов, Спасский, Вильяминов-Зернов, Можаровский, замандашлары Фирсов, Фукс, Катанов, Малов язмалары да, башка кешеләрнең дә хезмәтләре киң файдаланылган. Әмма безнең өчен тагын да кадерлесе – Худяков үзенең «Очерки по истории...» китабында күп татар тарихчыларының хезмәтләрен файдаланган! Менә алар: Атласов (Һади Атласи) – «Казан ханлыгы» һәм «Сөембикә»; Әхмәров (Гайнетдин) – «Казан тарихы»; Баһаветдинов Шиһабетдин (Мәрҗани) – «Казан вә Болгар тарихы»; Баттал (Габделбари) – «Сөембикә манарасы хакында»; Биккулов К.Д. – «Татар ханлары»; Вәлидов (Әхмәтзәки) – «Төрек вә татар тарихы»; Гәбәши (Хәсәнгата) – «Мөфассал тарих кауме төрки»; Газиз (Гобәйдуллин) – «Татар тарихы», «Шаһ-Гали»; Гобәйдуллин Газиз һәм Гали Рәхим – «Татар әдәбияты тарихы»; Мәрҗанинең 100 еллыгына чыккан җыентык (1915 ел); Мөхәммәт Риза – «Әссәб-әссәййар» («Җиде Йолдыз»); Насыров (Каюм) – 1873-1881 елгы календарьлары; Хисаметдин (Шәрәфетдин улы) – «Тәварихе Болгария»;

Моның өстенә, бу исемлеккә кермәгән күпме татар халык авыз иҗаты, борынгы кабер ташлары, нәсел шәҗәрәләре, борынгы мирас һәм ядкәрләр, хәтирәләр... Худяков аларның барысын да туплый, йөрәге аша үздыра, хезмәтләрендә куллана. Шуңа күрә аның язганнары коры тарихи фактлардан гына тормый, аларда милләтнең язмышы, бөеклеге һәм фаҗигасе чагыла...

Тарихчы-археограф, педагог һәм дин әһеле Сәет Вахидиның исеме файдаланылган хезмәтләр арасында булмаса да, Худяков китабының сүз башында аңа аерым рәхмәтен әйтә. Заманында Казан ханы Сәхибгәрәйнең ярлыгын тапкан һәм аның башка тарихчылар белән дә уртаклашкан татар галиме турында ул болай ди: «Особенному признательность автор выражает С.Г.Вахидову, любезно предоставившему возможность использовать при составлении настоящей работы подлинный текст открытого им ярлыка Сагиб-Гирея». Ул шулай ук коллегалары Гаяз Максудов һәм Газиз Гобәйдуллиннарга да зур рәхмәтләрен әйтә.

Казанның ул чактагы рус интеллигенциясе, элеккеге профессура Худяков китабын салкын каршы ала. Хәтта, бүгенге татар күзлегеннән караганда да аның хезмәтенә карата каршылыклы фикерләр булырга мөмкин. Әйтик, Худяковның тарихи хезмәтләрендә болгарчылык идеясе белән артык мавыгуы сизелә, ә ул объективлыкка зыян китерә. Шулай ук ул Хисаметдин бине Шәрәфетдин Мөслими әл-Болгариның бүгенге тарихчылар тарафыннан тәнкыйди кабул ителгән «Тәварихе Болгария» хезмәтенә артык таяна. Казан каласының яшен ике тапкыр киметеп күрсәтүе һәм Сөембикә манарасының Казан алынгач, руслар тарафыннан салыну фикере белән дә килешеп булмый. Әмма болар барысы да «Очерки...» китабының бәясен төшерми, авторның әйтергә теләгән төп фикеренә комачаулык китерми. Худяковның бу хезмәте татар тарихына өр-яңа карашы белән аерылып тора.

«Очерки...» китабында, тарихта беренче тапкыр, рус галиме тарафыннан, татар халкының дәүләтчелегенә һәм мәдәниятенә югары бәя бирелә. Худяков татарларның бәйсез дәүләтле һәм югары цивилизацияле халык булуын тарихи фактлар белән раслый. Моңа кадәр рус тарихчылары тарафыннан татарлар, яулап алынган халык буларак, шактый түбән дәрәҗәдә һәм кимчелекле яктыртыла. Мәскәү кенәзлегенең Казанга туктаусыз һөҗүмнәрен, нәтиҗәдә, аны юк итүләрен, имеш, киләчәктә үзләрен татар яуларыннан саклау өчен, дип аклыйлар. Рус язмаларында татарлар явыз һәм кыргый итеп тасвирланды, мөселман буларак, дин дошманы, дип игълан ителде. «Очерки по истории...» китабында, тарихта беренче тапкыр буларак, Казан ханлыгының вәхшиләрчә басып алынуында, татар халкының явызларча юк ителүендә, югары мәдәниятле шәһәр цивилизациясенең харап булуында Худяков урыс басып алучыларын, Мәскәү дәүләтен гаепли. Моны тарихи фактлар белән дәлилли!

Ул болгар-татарларда мең еллык ислам мәдәнияте һәм мәгърифәте булуын, халыкның укымышлы, гаять тырыш икәнлеген, ярты дөнья белән сәүдә итүен, яуда батыр, тыныч тормышта матур булуын тасвирлый. Урыс хәрбиләре аяк астында бөек цивилизациянең һәлак булуын әрнеп яза. Худяков татар халкының гасырлар буе кичергән кайгы-хәсрәтләрен, дәүләтсезлек фаҗигасен, тирән яраларын бөтен дөньяга ачып күрсәтә һәм, әлбәттә, күпләр өчен бу шок, коточкыч хәл була! Шуңа күрә, элеккеге рус профессурасы бу китапны дошманый кабул итә, чөнки Худяков татарларны шушы фаҗигале хәлгә калдырган патша хакимиятен генә түгел, ә татарлар арасында урыслаштыру һәм миссионерлык сәясәтен уздырган империя галимнәрен дә гаепли...

Китап басылып чыккан 1923 ел Татарстан һәм татар дөньясы өчен сөенечле дә, көенечле дә була. Сөенечле – яшь республикада татар теле дәүләт теле буларак киң таралыш ала, милли белгечләр әзерләнә, татар тарихы өйрәнелә һәм менә шундый дөрес фәнни китаплар басылып чыга. Көенечле – шушы миллилекнең башында торган Совнарком рәисе Кашаф Мохтаров өстендә кара

гомер китабына100 ел

болытлар куера башлый, аның тарафдары Мирсәет Солтангалиев кулга алына, хакимиятендәге иң якын фикердәшләре эштән куыла, 1924 елның язында аның үзенә дә чират җитә.

Шушы яңа татар хакимиятенең төп тарихчысы булган Худяков өчен дә катлаулы көннәр башлана, бер яктан, иске урыс профессурасы аны гафу итә алмый, икенче яктан, милләтсез социализм төзәргә җыенган яңа хакимият өчен ул инде Татарстанда кирәк булмый. 1925 елның башында Худяков Казанны ташлап, Ленинградка күчәргә мәҗбүр була, анда аспирантура тәмамлый, укыта, фән белән шөгыльләнә. Әмма ул анда да, мөгаен, күзәтү астында һәм ышанычсызлар исемлегендә булгандыр, чөнки күпме сораса да, аңа чит илләргә чыгарга рөхсәт бирмиләр. Һәм вакыты җитү белән, тарих фәннәре докторы, профессор Михаил Георгиевич Худяковны, 1936 елның көзендә кулга алып, 19 декабрьдә «террорист, контрреволюционер, троцкист», дип атып үтерәләр. Мөгаен, татар халкының бөек һәм фаҗигале тарихы турында иң дөрес китап язуын да кичерә алмаганнардыр.

М.Худяков 1957 елда тулысынча аклана, әмма бу әле аның намуслы исеме һәм хезмәтләре халыкка кайтты, дигән сүз булмый, моның өчен әле тагын утыз елдан артык вакыт кирәк була. Һәм Худяковны урыс фән даирәсе түгел, ә татарлар күтәреп чыга! Үзен атып үтергәч, Худяковның фәнни хезмәтләрен, китапларын да юк итәләр, әмма андый вакытта да барыбер, кайдадыр ни дә булса яшеренеп кала. Казанның Ленин исемендәге китапханәсендә дә Худяковның бер данә китабы табылды һәм аның яшерен күчермәсе татар язучылары кулына да килеп керде, бер төндә аны мин дә укып чыктым. Бу 1983 ел иде...

Менә инде 40 ел буе Казан, Ленинград, Киров, Малмыж һ.б. архивлардан мин Худяков хезмәтләрен барлыйм, аларны өйрәнәм, халыкка кайтарам. Иң мөһим эшләремнең берсе – 1989 елны Ленинградның Археология институты архивыннан Худяковның моңа кадәр басылып чыкмаган кулъязмаларын өйрәнеп, аларның исемлеген төзү булды, соңыннан аны күп фәнни хезмәтләрдә файдаландылар. 1989 елда аның мирасы буенча диплом эше яkладым, фәнни җитәкчем тарихчы Миркасыйм Госманов булды, бу СССРда Худяков иҗаты буенча якланган беренче диплом эше иде. 2006 елда Тарих институтында шушы тема буенча кандидатлык диссертациясе якладым, җитәкчем тарихчы Равил Әмирханов булды, бу инде Россиядә Худяков буенча беренче фәнни эш иде. 2003 елда Казанда «Михаил Худяков и история татарского народа», ә 2007 елда «Михаил Худяков и историко-культурное наследие народов Среднего Поволжья» дип аталган фәнни-документаль китапларым дөнья күрде.

Татарлар Худяковны күтәреп алды. Аның «Очерки по истории Казанского ханства» китабы 1990, 2004 елда Казанда, 1991 елны берничә басмада Мәскәүдә, 1996 елда Мәскәүдә «На стыке континентов и цивилизации» китабында дөнья күрде. Моннан тыш «Шәхесләребез» сериясендә Казанда 2011 елда 700 битле «Михаил Худяков» китабы басылып чыкты, ә 2019 елда исә «Очерки по истории Казанского ханства» китабы өч телдә – татар, рус, инглиз телләрендә дөнья күрде. Бу китап шулай ук Төркиядә дә берничә тапкыр басылды, аны төрек теленә башта Гаяз Исхакый, аннан соң Роза һәм Иклил Корбаннар тәрҗемә итә. Худяковның бу китабы – татар тарихының визит карточкасы.

Ә туган якларына М.Худяков исеме шактый озак әйләнеп кайта. 1989-2002 елларда Малмыжда булганда, аның исеме белән бәйле урыннар ташландык хәлдә, архивы таралып, юкка чыгып ята иде. Әле музейга да 1920 елны энесе Иван белән Худяков үзе нигез салган бит! Беренче эш итеп, миңа Казанда һәм Мәскәүдә Худяков турында басылган китапларны җибәрергә туры килде. Аннары менә инде ун ел буе Малмыжда уздырыла торган «Худяков укулары»нда төп докладларны ясый башладым. Ниһаять, 2016 елда Малмыжда Худяков туган һәм яшәгән йортка истәлек тактасы куйдык, урамга исемен дә бирдек. Быел исә «Худяков укулары»нда бу музейга М.Худяков исеме бирү тәкъдиме белән чыктым, хәзер хакимияттә генә хәл итәсе калды. Киләсе елга Михаил Худяковның тууына 130 ел була, бу аның юбилеена зур бүләк булыр иде. Музейда үткән бу чарада быел беренче тапкыр Худяковның нәсел дәвамчылары да катнашты, алар Екатеринбургтан килгән иде. Мин музейга М.Худяковның этисе Георгий Павлович һәм энесе Иванның уникаль фотоларын бүләк иттем...

Ни кызганыч, бу тарихи китапның 100 еллык юбилее Казанда билгеләнеп үтмәде. Бүгенгә кадәр Казанда Худяковның музее түгел, ул нигез салып калдырган музейларда хәтта бер почмагы да юк! Дөрес, Казанның 1000 еллыгына үзәктәге кечкенә генә бер култыкка М.Худяков исеме бирелде, шундый ук урам Әлмәт каласында да бар. Казанда Худяковка багышлап махсус фәнни конференцияләр дә уздырылганы юк. Аны безнең буын гына күтәрде, чөнки без Худяков китабы аша татарның чын тарихын белдек, бөеклеге белән горурландык, фаҗигаләре өчен хәсрәтләндек. Татарлар турында алтмыштан артык фәнни хезмәт язган галимнең татарлар өчен атып үтерелүен белеп кайгырдык. Татар тарихының үзе кебек мондый утлы-ялкынлы китапның Худяковка кадәр дә, аннан соң да әле язылганы юк. Менә 100 ел буе ул бердәнбер булып кала...

Фәүзия БӘЙРӘМОВА,
язучы, тарих фәннәре кандидаты.









Мәдәни җомга
29 декабрь
№51, 2023

АЛИШ

Рафис КОРБАН

(Ахыры. Башы 46, 47, 48, 49, 50 нче саннарда).

– Фронтка җибәрер алдыннан бер ай танк училищесы полигонында хәрби әзерлек үткәрергә алып калдылар,– диде Алиш.

– Бездә дә үзгәрешләр булырга тора әле, - дип бүлдерде редактор. – Ирләрне фронтка озатабыз бит. Бездән генә түгел, башка гәзит-журналлардан да китәләр. «Кызыл Татарстан»га күчерәләр безне. Башка редакцияләрне дә берләштерергә җыеналар. «Кызыл яшьләр»дән баш редактор урынбасары Рәхим Саттар да китеп барган кичә фронтка.

– Фронтка ук түгелдер, әзерлек курсларына гынадыр.

– Юк шул. Ул бит фин сугышында катнашкан кеше. Мылтык тота белә, әзерлисе юк. Аны десантчылар әзерли торган курсларга Куйбышевка җибәргәннәр, ди. Ә безгә менә бүлмәләрне бушатырга куштылар, – дип уфтанып куйды Хәбибуллин. – Мәскәүдән язучыларны, журналистларны Казанга эвакуациялиләр, ди. Шуларга урын кирәк.

– Ничек инде?.. Безне – фронтка, аларны – тылга? Нәрсә була инде бу?

– Шулай инде менә. СССРның иң күренекле язучыларын кайтаралар. Киләчәк өчен саклап калырга телиләр булып чыга. Леонов, Фадеевлар, Исаковский, Тренёв, Фединнар.

– Без бетсәк тә ярый икән...

– Йә, ярар, анда беләләрдер. Безгә менә көн саен яңа повестка китереп торалар. Бүген әнә Арсланга килгән.

Арслан дигәне Нури Арсланов була инде.

– Арслан да китәмени?

– Китә шул. Бүген барыбыз да җыйналып өенә, озатырга барырга җыена идек әле. Әйдә, син дә безнең белән, – диде редактор.

7.

Сугышның илленче көнендә дуслары, туганнары, гаиләсе, Казан белән хушлашып киткән Алишка әлләни озак булырга туры килмәде фронтта. Аларның Казанда формалашкан 1001 нче укчы полкын Брянск фронтына озаттылар. Биш көн дигәндә, 16 августта, аларның эшелоны Брянск шәһәренә җиткәч, барысын да вагоннардан төшереп, частьларга бүлгәләп, фронт урнашкан көнбатышка, Смоленск юнәлешенә таба җәяүләп атлаттылар. Көн саен 60-70 чакрымнар тәпиләп, Жиздра, Карачев шәһәрләрен уздылар да, Орёл тирәсендәге урманнарда туктап калдылар. Алар көнбатышка карап атласа, дошман алардан да тизрәк адымнар белән каршыларына килә, аралары көннән-көн якыная, кыскара бара иде. Аралар белән бергә көннәр дә кыскара, фронт сызыгы якынлашкан тизлек белән бер үк вакытта көз якынлаша. Юлларында кырда урак уручы хатыннар, көлтә төягән атлы олаулар, ындыр табакларында ашлык җилгәрүче малайлар, кызлар очрап кала. Ашлыгын суктырырлар, тик кая куярлар, амбарларга салып өлгерерләрме? Безнең гаскәрләр әлегә фронтка барабыз дип атласа да, алда бомба шартлаган тавышлар көннән-көн ачыграк ишетелә. Дошман илнең йөрәгенә, Мәскәүгә таба ашкына. Күп тә үтмәс, бу басу-кырлар, бу авыллар фашист итеге астында калачак. Алиш кына түгел, башка солдатлар да шулар турында уйлап атлый иде бугай. Берсенең дә сөйләшәсе, аралашасы килми, барысы да үзенә бикләнеп, тавыш-тынсыз гына алга баралар...

Сентябрьнең бишендә Алиш кинәт кенә авырып китте. Температурасы күтәрелде. Хәлсезлек аяктан екты. Үзе болай нык, таза кеше дә бит, кизү тазалыгыңа карап тормый икән. Салкын тидереп авырып ятканы да юк иде югыйсә. Ә монда, үч иткәндәй, чир элəктерде. Грипп дигән диагноз куйды полк врачы. Алдагы көндә коеп яуган салкын яңгыр астында калды алар. Беркая качып, ышыкланып торыр урын да юк иде. Япан кыр уртасында иртәдән ява башлаган яңгыр көне буе койды да койды. Манма су булып чыланган гимнастёрка җылыту түгел, киресенчә туңдыра, күшеккән тәнен калтыратып, өшетә башлады. Алиш кебек салкын тидергән тагын биш-алты солдатны Карачев шәһәре янындагы яралы сугышчыларны дәвалый торган бәләкәйрәк кенә кыр госпиталендә калдырып киттеләр.

● Абдулла Алишның хатыны һәм улы Алмаз.

Госпитальдән чыгып күп тә үтмәде, аларны Брянск урманнары тирәсендә фашист солдаты кыяфәтендәге, иңенә кәкре чалгысын салган үлем шәүләсе куып тотты. Октябрь башында фашистларның 43 нче армия корпусы Брянск шәһәрен төньяктан урап узып, икенче яктан һөҗүм итүче Гудирианның икенче танк группасына караган 47 нче мотоцикл корпусы белән кушылып, Брянск фронты гаскәрләре тулысынча чолганышта калды. Алишларның шушы фронтта сугышучы 1001 нче укчы полкы да тулысынча әсирлеккә төште. Туган илне немец фашистларыннан азат итү өчен дигән изге максат белән сугышка чыгып китүенә нәкъ ике ай булды дигәндә, Алиш Ватан сакчысыннан «халык дошманы»на әйләнде дә куйды. Дошманны алга җибәрмәс өчен бер адым да артка чикмәскә, соңгы тамчы каның тамганчы көрәшергә дигән установка куелган иде бит. Ә алар бу боерыкны үти алмады. Чолганышта калып, үзләренә тугыз граммлы ядрә белән гомерләрен өзәр өчен дип автоматын төбәгән фашист солдаты алдында кулларын күтәреп, әсир төшәргә мәҗбүр булдылар. Бу 1941 елның 12 октябре көн иде. Шушы көннән Алиш өчен хурлыклы да, михнәтле дә, әмма Ватан азатлыгы өчен аяусыз, кыю яшерен көрәшкә әверелгән, данлыклы үлем белән чикләнгән әсирлек тормышы башланды.

«Бигрәк тиз булды бит әле бу. Юньләп торып сугышка да кермәгән, ичмасам бер генә фашистны булса да теге дөньяга олактырмаган да килеш, коллык михнәтен чигәргә туры килер микәнни?» дигән уй миен бораулады.

Көек авылында Абдулла Алиш музее һәм аңа куелган һәйкәл

(Ахыры. Башы 47-50 нче саннарда).

Йолдызсыз калган 25 татар каһарманы

МУСИН СӨЛӘЙМАН МУСА УЛЫ

Мусин Сөләйман Муса улы – 1926 елгы, Теләче район комиссариаты аша чакырылган. 1 нче Белоруссия фронтында 5 нче удар армиянең 94 нче гвардия укчы дивизиянең 288 нче полкында укчы, гвардия рядовое. 1945 елның 30 апрелендә Герой исеменә тәкъдим ителә, Кызыл Байрак ордены белән генә йомылып кала.

С.Мусинның бүләкләнү кәгазе.



Все графы заполнять полностью

Наградной лист

1. Фамилия, имя и отчество Мусин Сулейман Муса
2. Звание Гвардии красноармеец 3. Должность, часть стрелок 8 стрелковой роты 288 Гвардейского стрелкового полка 94 Гвардейской стрелковой дивизии

Представляется к присвоению звания Герой Советского Союза

4. Год, место рождения 1926 Национальность татарин
6. Партийность Член ВЛКСМ 1944 7. Участие в гражданской войне, последующих боевых действиях по защите СССР в Отечественной войне (где, когда) 1 Белорусский фронт 1.11.44
8. Имеет ли ранения или контузии в Отечественной войне (число, месяц, год ранения местонахождение в настоящее время) ранений не имеет
9. С какого времени в Красной Армии (месяц, год) 11.1943
10. Каким РВК призван Тюлячинским РВК 11. Чем ранее награжден (№ приказа, дата, чей приказ) Медаль За отвагу приказ № 03/н. от 23.01.45 287 сп.

1. Краткое, конкретное изложение личного боевого подвига или заслуг

В бою в г. Берлине 28.04.45 года на Александер плац штурме полицейского управления города, первым ворвался в [illegible] и ручной гранатой уничтожил яростно сопротивлявшихся 3 гитлеровцев "фаустников", чем дал возможность оцепить дом.

Когда на втором этаже дома в одной из комнат были нем[illegible] в количестве 6 человек, он завязал с ними бой, ворвавшись [illegible] дом и броском гранаты уничтожил 6 сопротивлявшихся.

Кроме того при штурме полицейского управления, в подва[illegible] уничтожил 5 полицейских, которые обстреливали из подвала н[illegible]ши передовые подразделения.

В бою за Александрийский вокзал, в доме на углу Кайзер-штрассе засевшая группа немцев мешала продвижению, т.Мусин скрытным путем подполз к дому и гранатой уничто[illegible] до 12 немецких солдат.

За [illegible] мужество и отвагу достоин присвое[illegible] звания [illegible] Советского Союза.

Командир 288 Гвардейского Стрелкового Кишиневского [illegible] полка Гвардии подполковник КОНДРАТ[illegible]

"30" Апреля 1945 года

ХӘЛИУЛЛИН ХӘЙРУЛЛА ХӘЛИУЛЛА УЛЫ

Хәлиуллин Хәйрулла Хәлиулла улы – 1925 елда Лаеш районының Атабай авылында туган, шул район комиссариаты аша чакырылган. 1 нче Белоруссия фронтында 33 нче укчы дивизиянең 44 нче артиллерия полкында орудия төбәүчесе булып хезмәт итә, ефрейтор. 1945 елның 26 апрелендә Герой исеменә тәкъдим ителә, Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә. Вафатыннан соң, туган авылы зиратында җирләнә.

ХӘСӘНОВ НИКОЛАЙ ГРИГОРЬЕВИЧ

Хәсәнов Николай Григорьевич – 1918 елда Шөгер бистәсендә туган, шул ук район комиссариаты аша сугышка озатылган. 3 нче Украин фронтында 73 нче укчы дивизиянең Басаргин исемендәге 211 нче полкында укчылар взводы командиры ярдәмчесе була, гвардия сержанты. 1944 елның 3 декабрендә Герой исеменә тәкъдим ителә, Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә.

ШӘРИФУЛЛИН СӘЛИМ ГОБӘЙ УЛЫ

Шәрифуллин Сәлим Гобәй улы – 1925 елда туган, Азнакай район комиссариаты аша сугышка озатылган. 1 нче Белоруссия фронтында 11 нче танк корпусының Волноваха исемендәге 65 нче танк бригадасында моторлаштырылган батальонда автоматчы була, рядовой. 1944 елның 22 июнендә Герой исеменә тәкъдим ителә, Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә.

ШӘРИФУЛЛИН НУРГАЛИ

Шәрифуллин Нургали – 1924 елда туган, Әтнә хәрби комиссариаты аша сугышка озатылган. 92 нче укчы дивизиянең 317 нче укчы полкында укчы булып яу йөри. 1944 елның 9 июлендә Герой исеменә тәкъдим ителә, Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә.

Михаил ЧЕРЕПАНОВ.
«Миллиард татар» челтәреннән.
Вахит ИМАМОВ тәрҗемәсе.



Сынауларга инде күнеккәнбез,

Без илаһи кануннар идарә иткән гаҗәеп дөньяда яшибез. Сәламәтлек, мәхәббәт, уңыш – болар барысы да әлеге кануннарга бәйле. Әмма күп нәрсә үзебездән дә тора! Шунлыктан Яңа елны ничек каршы алсаң, ел шулай үтәр, дигән сынамышка да күбебез ышана. Киләсе ел нинди булыр икән, аны ничек каршыларга кирәк – шул хакта сөйләшик.

Яшел Агач Аждаһа елы

Кытай астрологиясе буенча, һәр елның хуҗасы бар. 2024 ел Яшел Агач Аждаһа – кешегә күп сөенеч китерергә сәләтле зирәк әкияти зат билгесе астында үтәчәк, ул 10 февральдә башланып, 2025 елның 28 гыйнварында тәмамланачак. Татар халык әкиятләрендәге Аждаһа бик явыз һәм кешегә үчле булса да, Кытайда ул – абруйлы җанвар, аның химаясендәге ел һәрвакыт диярлек уңышлы була. Шунлыктан киләсе ел да куанычлы үзгәрешләргә, сөенечле очрашуларга бай булачак, күп проблемалар хәл ителәчәк. Моннан тыш, бу Аждаһа яшел төстә бит әле, ул исә тынычлык, янарыш һәм иминлек символы санала.

Яңа елны ничек каршыларга?

Аждаһа елларының барысы да – кәбисә. Йортка уңыш җәлеп итү өчен, йә чүлмәккә чын агач (кечкенә чыршы яки бонсай) утыртырга, яисә диварга агач сурәтләнгән картина булса да элеп куярга кирәк. Аждаһа сурәте дә бәхет китерә, ул йомшак уенчык та, фарфор һәм агач уенчык сыйфатында да, савыт-сабадагы рәсем рәвешендә дә булырга мөмкин. Өйне бизәгәндә, төрле төстәге гирляндалар эләргә онытмагыз. Шәм, чыршы уенчыклары, эскәтер-тастымалларның күпчелеге кызыл һәм алтын төсендә булсын. Кызыл төстәге кытай фонарьлары һәм чуар кәгазь аждаһалар да ел хуҗасы күңеленә хуш килер. Аждаһа игътибар үзәгендә булырга, башкалардан аерылып торырга ярата. Шунлыктан Яңа елны каршылау бәйрәмен гадәттәгедән тантаналырак итү мәслихәт. Яңа ел төнен ресторан яки кафеда үткәрү иң яхшысы, әмма өйдә дә бик күңелле каршылау мөмкин бит: иң мөһиме, матур киенеп, тәмле ризыклар белән сыйлану, күп итеп кунак чакыру – соңыннан елмаеп, сөенеп искә алырлык кичә булсын ул. Кием-салым кыйммәтле тукымадан – бәрхет, ефәк, парча, атластан, кызыл, алтын йә яшел төстә булырга тиеш. Ак яки кызыл эскәтер җәелгән өстәлне бант-чәчәкләр, зиннәтле-нәфис тастымал, савыт-саба белән бизәү яхшы. Сый-хөрмәтнең табигый булуы шарт: табынга кимендә 12 төрле ризык куелып, сыер-сарык-тавык-күркә ите, балык, пилмән, татлы дөге бәлеше, төрле казылык, яшелчә-җимеш, баллы тәм-томнан өстәл сыгылсын – ярымфабрикатлар һәм консервалар гына булмасын. Җитен эскәтер, агач тәлинкәләр, бәллүр савытлар, хуш исле шәмнәр, нарат-чыршы күркәсе һәм «алтын» төсендәге әфлисун, мандарин, хөрмәдән ясалган композицияләр бәйрәм табынын тагын да күркәмләтә төшәр.

СӘЛАМӘТЛЕК ЙОЛДЫЗНАМӘСЕ-2024

КҮСЕ

(1936, 1948, 1960, 1972, 1984, 1996, 2008, 2020)

КҮСЕ елында туучыларның сәламәтлеге зарланырлык түгел. Дөрес, быел бераз чирләп китү һәм имгәнү ихтималы да бар, шунлыктан аеруча сак булу сорала. Иммунитетны ныгыту мөһим. Күселәр хәвефләнергә ярата, шуңа стресслардан саклану һәм психик сәламәтлек турында кайгырту зарур. Медитация, йога белән шөгыльләнү, йокы һәм туклануның сыйфатын яхшырту мәслихәт. Аждаһа елы Күселәргә үз яшәү рәвешен үзгәртү һәм физик активлыкларын арттыру мөмкинлеген бирә. Сәламәтлекне саклау һәм ныгыту өчен, даими рәвештә физик күнегүләр ясау, урамда йөгерү яки җәяү йөрү, дөрес туклану һәм җитәрлек күләмдә су эчү киңәш ителә.

КУЯН

(1939, 1951, 1963, 1975, 1987, 1999, 2011)

КУЯН (Мәче) елында туучыларның физик сәламәтлегенә беренче куркыныч та янамый, әмма шулай да аңа даими игътибар бирергә кирәк. Бу ел көтелмәгән хәлләргә бай булачак, шунлыктан физик һәм психик сәламәтлекне кайгырту бик мөһим. Куяннар гадәттә стресска бик бирешүчән, хафаланырга яратучан, шуңа күрә хис-тойгыларны йөгәнләргә өйрәнү мәслихәт. Медитация, йога, догалар уку, саф һавада күбрәк йөрү һәм спорт белән шөгыльләнү стрессны җиңәргә булышачак. Дөрес туклану, даими рәвештә медицина тикшеренүләре үтү дә зарур.

ҮГЕЗ

(1937, 1949, 1961, 1973, 1985, 1997, 2009)

ҮГЕЗ елында туучыларга 2024 ел физик халәтләрен яхшырту мөмкинлеген бирә. Киеренке вазгыятькә, стресслар һәм нервлану артуга бәйле рәвештә, психик сәламәтлекне кайгырту бик мөһим. Көндәлек режимны саклау, дөрес туклану зарур. Ашый торган ризыкларның күләме һәм сыйфатына игътибар бирү, физик активлыкны арттыру, тарту һәм эчү кебек зарарлы гадәтләрдән арыну киңәш ителә. Авыруларны кисәтү өчен, даими тикшеренеп тору хәерле.



АЖДАҺА

(1940, 1952, 1964, 1976, 1988, 2000, 2012)

АЖДАҺА елында туучыларга үзләренең физик һәм психик сәламәтлегенә игътибарлы булу мөһим, чөнки 2024 ел алар өчен бик энергияле һәм ашкынулы булачак. Сездәге бетмәс-төкәнмәс энергияне дөрес файдалану сорала. Көндәлек режимны үтәү, вакытында ял итү яхшы. Дөрес туклану һәм физик активлык та мөһим, спорт белән даими шөгыльләнү сезгә баланс һәм гармонияне сакларга булышачак. Үз хисләрегез һәм стресс белән идарә итү, фикер ачыклыгын саклау һәм җан тынычлыгы табу өчен, медитация, йога, спорт белән шөгыльләнү, догалар уку, саф һавада күбрәк йөрү киңәш ителә. Шулай ук якын кешеләрегез белән ешрак аралашу һәм ял итү-күңел ачу өчен вакыт табу да бик мөһим.

ЮЛБАРЫС

(1938, 1950, 1962, 1974, 1986, 1998, 2010)

ЮЛБАРЫС елында туучыларга 2024 елда йокы һәм туклануның сыйфатын яхшырту мәслихәт. Алкоголь һәм никотиннан бөтенләй баш тартырга тырышыгыз. Аждаһа көчле рухлыларны үз итә, шунлыктан зарарлы гадәтләрдән арыну һәм үзеңне камилләштерүгә омтылу хуплана. Спорт белән актив шөгыльләнү, чаманы белеп кенә туклану һәм сәламәт яшәү рәвешенә омтылу сезнең өчен файдага булачак. Даими рәвештә медицина тикшеренүләре үтәргә дә онытмагыз.

ЕЛАН

(1941, 1953, 1965, 1977, 1989, 2001, 2013)

ЕЛАН елында туучыларның сәламәтлеге зарланырлык түгел, әмма бик актив һәм энергияле Аждаһа елында стресслы хәлләр һәм нерв киеренкелеге арту эмоциональ төшенкелеккә китерергә мөмкин. Тик зирәклеге белән танылган Еланнар теләсә нинди үзгәрешләргә яраклашырга һәм тынычланырга тырышачак. Үзләрен даими кайгырту кирәклеген онытмаган Еланнарга Агач Аждаһа елы сәламәтлекләрен яхшырту өчен яңа мөмкинлекләр бирәчәк. Медитация, йога, спорт белән шөгыльләнү, догалар уку, саф һавада күбрәк йөрү киңәш ителә.

Аждаһа елында кемнәр туган?

Жанна д'Арк, Иммануил Кант, Жан Жак Руссо, Фридрих Ницше, Сара Бернар, Николай Римский-Корсаков, Бернард Шоу, Зигмунд Фрейд, Николай II, Марлен Дитрих, Сальвадор Дали, Марчелло Мастрояни, Че Гевара, Пеле, Джон Леннон, Брюс Ли, Владимир Путин, Рамзан Кадыйров, Патрик Суэйзи, Моника Беллуччи, Адель, Киану Ривз, Шакира, Рианна һ.б.

хәерхаһ бул безгә, Яңа ел!..

АТ

(1942, 1954, 1966, 1978, 1990, 2002, 2014)

АТ елында туучыларга сәламәтлекләрен бераз кайгырту зарур. Чирләп китү һәм имгәнү ихтималы бар, шунлыктан сәламәтлеккә һәм иминлеккә игътибарны арттыру сорала. Спорт белән шөгыльләнгәндә аеруча сак булу хәерле. 2024 ел Атларның яшәү рәвешенә үзгәрешләр кертергә мөмкин: туклану сыйфатын яхшырту һәм физик активлыкны арттыру, зарарлы гадәтләрнең аеруча зыянлыларыннан котылу бу елда җиңел бирелачәк. Вакыт-вакыт стресслар һәм нерв киеренкелеге җәфалаячак, шунлыктан аларны җиңәргә өйрәнү мөһим. Медитация, йога белән шөгыльләнү, якын кешеләр белән ешрак аралашу, күбрәк ял итү мәслихәт.

ӘТӘЧ

(1945, 1957, 1969, 1981, 1993, 2005, 2017)

ӘТӘЧ елында туучыларга сәламәтлекләрен кайгырту зарур. Аларга үз бәдәннәренең көч-куәтенә генә өметләнү җитәрлек булмаячак. Ә инде организмга бераз ярдәм итеп, тикшеренеп һәм вакытында дәваланып торганда, ел шактый тыныч үтәр. Нерв системасын саклау мәслихәт – бер сәбәпсез кәеф төшсә, нык ардырса, артык каты тәэсирләндерсә, шундук тынычланырга тырышу хәерле. Психик сәламәтлекне саклау өчен, медитация, йога, спорт белән шөгыльләнү, догалар уку, саф һавада күбрәк йөрү киңәш ителә. Сәламәтлекне начарайтачак хәвеф-хәтәрле карарлар кабул итүдән саклану мәслихәт.



САРЫК (КӘҖӘ)

(1943, 1955, 1967, 1979, 1991, 2003, 2015)

КӘҖӘ (Сарык) елында туучыларга быел үзләренең физик һәм психик сәламәтлегенә бик игътибарлы булу мөһим. Иммун система һәм ашкайнатуда проблемалар килеп чыгу ихтималы бар, шунлыктан дөрес туклану зарур. Аждаһа елында стресслы хәлләр һәм нерв киеренкелеге арту күзәтелә, шуңа күрә вакытында ял итү мәслихәт. Хис-тойгыларны контрольдә тотарга һәм күңел төшенкелегенә бирешмәскә кирәк. Аждаһа елын тыныч үткәрү өчен, әллә ни тырышлык та кирәкми үзе – физик хезмәттә дә, ашау-эчүдә дә чама хисен югалтмау, сәламәтлекне даими кайгырту гына сорала.



ЭТ

(1946, 1958, 1970, 1982, 1994, 2006, 2018)

ЭТ елында туучыларның сәламәтлеге зарланырлык түгел, әмма профилактика турында онытмау яхшы. Сәламәтлекне саклау һәм төрле проблемалар килеп чыгуны кисәтү өчен, яшәү рәвешен үзгәртү сорала. Туклануны контрольдә тотарга һәм витаминнар белән микроэлементларның җитәрлек булуын тәэмин итәргә кирәк. Физик активлыкны арттыру мөһим. Быел шактый күп булачак стресслардан саклану өчен, аларны җиңәргә өйрәнү зарур. Медитация, йога, спорт белән шөгыльләнү, догалар уку, саф һавада күбрәк йөрү киңәш ителә.

МАЙМЫЛ

(1944, 1956, 1968, 1980, 1992, 2004, 2016)

МАЙМЫЛ елында туучылар үзләренең сәламәтлеге турында ел башыннан ук кайгыртырга, кирәкле тикшеренүләрне вакытында үтәргә тиеш. Ваемсызланып йөрмәү хәерле. Сәламәт яшәү рәвеше алып бару зарур – вакытында йокларга, дөрес тукланырга, саф һавада күбрәк булырга, стресслардан сакланырга кирәк. Иммунитетны һәм физик халәтне яхшырту өчен, көндәлек режимны үтәү, спорт белән шөгыльләнү таләп ителә. Маймыллар арып-талганчы, чама хисен югалтып эшләргә ярата, бу исә бөтенләй көчсезләндерергә мөмкин, шунлыктан вакытында ял итү мөһим. Күңел төшенкелегеннән саклану өчен, якыннар белән күбрәк аралашу файдалы.

ДУҢГЫЗ (КАБАН)

(1947, 1959, 1971, 1983, 1995, 2007, 2019)

ДУҢГЫЗ елында туучыларның сәламәтлеге зарланырлык түгел, ара-тирә вак-төяк һәм тиз үтеп китә торган чирләр генә борчып алгаларга, ә менә психологик халәтләре бераз борчу тудырырга мөмкин. Моңа гаҗәпләнергә дә, әллә ни хафаланырга да кирәкми. Ел буена артык дулкынланмый-ярсымый яшәргә тырышу мәслихәт, нинди дә булса гайре табигый чаралар куллану катгый тыела. Әмма бу елда гына түгел, киләчәктә дә саулык куандырырлык булсын өчен, сәламәт яшәү рәвеше алып бару һәм зыянлы гадәтләрдән арыну хуплана. Ел башыннан ук дөрес туклангнада, саулык сөенерлек булачак.

Уңыш кемгә елмаячак?

Аждаһа елы Күсе, Маймыл һәм Әтәч елында туучыларга уңыш һәм муллык китерәчәк. Үгез, Елан һәм Эт елында туучыларның шәхси тормышында һәм һөнәри эшчәнлегендә кытыршылыклар килеп чыгу ихтималы бар. Аждаһа елында туучыларга да игътибарлы булу зарур, бу алар өчен уңышсызлыклар һәм яңарыш елы булачак, шунлыктан һәркайсының кыюлык, бәйсезлек кебек сыйфатларын көчәйтәчәк.

Аждаһаны ачуландырма!

Яңа ел төнендә менә нәрсә Аждаһаның ачуын чыгарырга мөмкин: төшенке кәеф, түләнмәгән бурыч һәм кредитлар, җыештырылмаган пычрак йорт, бәйрәмгә чит кеше киемен кию, якыннар белән ызгышу, шәм һәм уткабызгыч кебек утка бәйле бүләкләр бирү – ут ургылдыру ел хуҗасының үзенә генә рөхсәт ителә. Иң мөһиме – Яшел Агач Аждаһа елын каршылаганда, үзегезне бәхетле тоярга тырышыгыз, чөнки ул күңелсезләнүне, бигрәк тә бәйрәмдә, бер дә яратмый.

2024 – таулар күчерерлек куәткә ия ел, һәркемгә тормышын яхшы якка үзгәртеп калу хәерле. Исегездән чыгармагыз: Аждаһа – энергия, үз-үзеңә ышаныч һәм уңыш символы ул!

Бүләк сайлыйбыз

Кытайда иң шәп бүләк – акча салынган хунбао (кызыл конверт). Быел файдалы гына түгел, гаҗәпләндерерлек тә бүләк сайлау зарур: затлы кием-салым йә бизәнү әйберләре; интерьер өчен таң калдырырлык берәр җиһаз; массаж яки SPA-процедурага сертификат; рәсем ясау, мозаика төзү яки флористика буенча осталык дәресенә чакыру; һава шарында очу яки парашют белән сикерүгә сертификат; фитнес-клубка абонемент һ.б. Якын туганнарга күп итеп әфлисун һәм мандарин, чәчәк, баллы тәм-том бүләк итәргә дә була.

Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

● Асия Харисова.

● Шакир Харисов.

АЛАР ИСТӘ

Татар театры белән кызыксынган, артистларыбызны туганнарыдай яраткан өлкән буын тамашачыларыбыз хәтерлидер – Асия исемле актрисалар бар иде театрда, өч Асия: Галиева, Хәйруллина һәм Харисова. Алар Мәскәүнең Луначарский исемендәге театр сәнгате институтында (ГИТИС) татар студиясендә белем алып, 1949 елда Казанга кайткан төркемнән. Бер ел ТЮЗда (рус яшь тамашачылар театры) эшлиләр. Бер көн ТЮЗ спектакле, икенче көнне безнең шушы яшь артистларыбызның татар телендәге спектакльләре күрсәтелә. Ә 1950 елдан алар Татар Академия театрында эшли башлый.

Бу төркемдә булган артистларыбыз да искә алуга лаек: Шәхсәнәм Әсфәндиярова, Гәүһәр Камалова, Празат Исәнбәт, Рәфкать Бикчәнтәев, Дэлюс Ильясов, Гали Хөсәенов, Шакир Харисов һәм соңыннан язучы булып танылачак Мәхмүт Хәсәнов һ.б. Әле санап киткән исемнәр һәркайсы озак еллар буе татар театрының йолдызлары, йөзек кашлары булып балкыды. Һәр уйнаган рольләре, куйган спектакльләре театр тарихын бизәүче җәүһәр булды.

Шуларның берсе, Татарстанның атказанган артисткасы Асия Харисованың тууына шушы көннәрдә 100 ел тулды. Түгәрәк, олы дата.

Асия апа – гади авыл кызы. Ул Биектау районы Өмбе авылында, Әхмәтша Разаутдинов гаиләсендә дөньяга килгән. Гади гаиләдән, ә тумыштан искиткеч табигый талант бирелгән. Аның балачагы – 30 нчы еллар уртасында «сәнгать халыкныкы» дигән шигарь белән авылларда да үзешчән сәнгать түгәрәкләре оеша, театр тамашалары, концертлар белән кызыксыну башланган чорга туры килә. Һәвәскәрләр белән сәхнәдә җырлап-биеп йөргән Асияда да артист булу хыялы уяна. Әмма нәкъ һөнәр сайлау вакыты җиткәндә, тормышның астын-өскә китереп, Бөек Ватан сугышы башлана. Ялкынлы йөрәкле, чая, зирәк, кыю Асия фронтка китү теләге белән яна. Ә аларны урман кисәргә, окоп казырга җибәрәләр. Сугыш чоры газапларын ул кеше сөйләгәннән яки китаплардан укып түгел, үзе татып белә. Ә менә 1944 елда, әле кызу сугыш барса да, Татарстан хөкүмәте карары белән Мәскәүдәге Луначарский исемендәге театр сәнгате институтына татар театры өчен талантлы яшьләр кабул итү турында игълан чыккач, аның күңелендәге яшьлек хыялы тагын дөрләп кабына һәм ул укырга ниятли. Аны укырга кабул итәләр һәм чиксез бәхетле кыз Мәскәүгә юл ала.

Курс җитәкчесе – Станиславский шәкерте, режиссёр, педагог, профессор – Ольга Пыжова үзенең милли студияләр турында язган китабында Асия турында менә ничек искә ала: «Асия студиядә укыган вакытта ук сөйкемле сөяге белән аерылып торды, гадилеге, табигыйлеге белән үзенә җәлеп итте; сәхнәдә озак еллар эшләгән тәҗрибәле кешеләр өчен дә үрнәк булырлык самимилек күрдем мин аңарда», – ди ул.

СССРның халык артисты Михаил Тарханов исә студентка Асия Харисова белән бәйле бер вакыйга турында болай дип яза: «Карло Гоцциның «Болан патша» әкияте буенча диплом спектаклендә әзерләнгән вакытта, Смеральдинаны уйнаучы Асия Король каршында баш игәндә шулкадәр нәфис хәрәкәт белән бөгелде ки, үзе дә аз гына егылмый калды. Бу хәрәкәт миңа бик тә ошады, утырган җиремнән «Яхшы, искиткеч. Бу табышыңны оныта күрмә, ныгыт. Гел шулай итеп эшләрсең», дип кычкырып җибәрдем. Әмма бу мизгелдә мин кызның ачлыктан хәлсезләнеп, егыла язуын башыма да китерә алмадым. Ә Асия исә, тиз генә аңына килгәч, ике кулын канат кебек җәеп әкрен генә күтәрелде дә, йөгереп китеп

● 1971. К.Тинчурин. «Сүнгән йолдызлар». Г.Нигъмәтуллина. А. Харисова.

барды. Ул шул хәлендә дә һәр хәрәкәтнең сәхнәдә акланырга тиешлеген аңлап уйнавын күрсәтте; сәхнә законнарын үз йөрәге аша үткәрү, халык алдында югалып калмау – бу инде чын талант чаткылары, профессионализм, артистлык осталыгы. Шул вакыйгадан соң мин Асияның театрга булган көчле мәхәббәтен, сайлаган хезмәтенә бик җитди каравын чынлап торып аңладым», – ди. Мәскәүнең олпат карт актерыннан мондый бәһа алу – ул инде кызыл дипломга тиң...

Яшь артистлар белән бергә Асия дә Казанга кайта. Бу чорда труппа иң көчле артистлар ансамбле белән дан тота. Монда Гөлсем Болгарская, Гөлсем Камская, Фатыйма Ильская, Мәрьям Сульва, Галимә Ибраһимова, Галия Булатова; ир-атлардан Хәлил Әбҗәлилов, Камал III, Зәйни Солтанов, Хөсәен Уразиков. Алар янында бу яшьләргә, әлбәттә, җиңел булмый... Беренче елларда Асия Харисовага да күбрәк күмәк күренешләрдә катнашырга туры килә, әмма табигате белән тынгысыз, эш сөючән Асия вакытын бушка уздырмый, ул репетиция вакытларында һәрвакыт сәхнәне күзәтә, өлкән артистларның уеннарын өйрәнә. Мәсәлән, үзенең беренче роле, «Галиябану» спектаклендәге Галимәбану ролен ул әнә шулай залда утырып, үзлегеннән өйрәнә һәм режиссёрга күрсәткәч, аның уенын оста дип табалар һәм спектакльгә кертәләр. Берничә еллардан соң «Галиябану» кабат сәхнәгә куелгач та, Асия Харисова шул ролендә кала. Авылда туып-үскән кызга бу образ бик якын, таныш була, әлбәттә. Ул аның тышкы кыяфәтенә зур әһәмият бирә, үзенә генә хас бизәкләр таба. Мәсәлән, аның бик табигый итеп җеп эрләве, кулындагы орчыгының биеп торуы рольне баетып җибәрә. Уңганлык, тазалык сибелә аның Галимәбануыннан, сәхнәгә ул ап-ак оекбаштан чыга, идәнгә нык итеп, каты басып йөри. Аның уенына ул чакта матбугат битләрендә мондый бәя бирелә: «Баласы өчен җанын да фида кылырга риза Ана коеп куелгандай күз алдына килеп баса, шул ук вакытта артистка, Галимәбануның ир күзенә генә карап торырга мәҗбүр икәнлеген дә

1967. А.Гыйләҗев, А.Яхин. «Шамил Усманов». А.Харисова, Х.Җәләлов.

абайлап уйный, теләсә-теләмәсә дә фаҗигага сәбәпчеләрнең берсенә әверелүнең авырлыгын артистка оста күрсәтә алды».

Г.Ибраһимов әсәре буенча куелган «Татар хатыны ниләр күрми» дигән спектакльдә Асия Харисова ике роль башкара. Берсендә ул бик мәхәббәтле, киң күңелле, ягымлы-якты йөзле Фәүзия киленне гаять тормышчан гәүдәләндерсә, икенчесендә аңа чагыштыргысыз Гөлсем Камскаядан соң әрем-тел Сабира образын, усал кайнананы уйнарга туры килә. Менә шунда инде артистканың чын табигый таланты ачыла. Асия апа нинди генә рольдә булмасын – бик уңаймы яки тискәре, усал рольләрдәме – шундый табигый иде, аңа тәмам ышанасың. Әгәр ана ролендә икән – нәкъ үз әниең кебек якын булуын тоясың, әгәр инде менә шушы Сабиралар кебек усал икән, ул хәтта бер аждаһа төслегә әйләнә.

Асия Харисованың татар драматургиясе классиклары әсәрләрендә уйнаган рольләре байтак: К.Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар»ында шундый ук бер тискәре карчык Фәрхи, «Казан сөлгесе»ндә Гөлбану, Ф.Бурнашның «Яшь йөрәкләр»ендә Галимә, Н.Исәнбәтнең «Миркәй белән Айсылу»ында Сәрия, Ш.Хөсәеновның «Әни килде»сендә Расыйха, М.Әмирнең «Тормыш җыры»нда Мәргубә карчык.

Хәзерге заман әсәрләрендә дә ул бик кызыклы рольләр башкарды. Бигрәк тә Рәфкать Бикчәнтәев

● 1967. Х.Вахит. «Күк капусы ачылса». Г.Хәйретдинова, А.Харисова.

● 1972. М.Фәйзи. «Галиябану». А.Харисова, Н.Ибраһимова, Б.Әшрәпов.

ҺАМАН...

куйган спектакльләрдә. Шәкерттәше, Асия Харисованы режиссёр, артист Рәфкать абый Бикчәнтәев бик хөрмәт итеп, үзенең спектакльләренә алган. Үкенечкә, Асия апа уйнаган күп спектакльләрнең язмалары, кино тасмалары юк диярлек. Бары тик Х.Вахитның «Күк капусы ачылса» дигән водевиленнән Р.Бикчәнтәев белән партнёр булып уйнаган бер күренештән өзек кенә бар. Шушы кыска уенда да А.Харисованың бик нечкә тоемлаучы, җиңел, матур, йомшак юморга бай һәм табигый, ихлас артистка икәнен күзалларга мөмкин.

Мәскәүгә укырга кергәндә, А.Харисованың фамилиясе Разаутдинова була, ә менә шул ук студиядә укучы Шакир исемле егет белән гаилә коргач, ул инде театр тарихына Асия Харисова булып керә. Шакир Харисов та шушы артистлар белән бергә Академия театрында эшли башлый, күп кенә эпизод рольләр башкара, матур җырлый һәм ул үзенең озын гомеренең күп өлешен театрда режиссёр ярдәмчесе булып эшләп уздырды. Шуны да әйтеп китәргә кирәк, Асия Харисова белән Шакир Харисовның гаиләсендә әле студент елларында бик талантлы бер бала туа һәм ул соңыннан безнең халкыбыз алдында татар эстрадасының йолдызы Равил Харисов булып танылa. Шундый ук талантлы, мәһабәт озын буйлы, ягымлы, белемле, зәвыклы Татарстанның халык артисты Равил Харисов, ни кызганыч, әти-әнисе яшенә җитә алмады. Әле иҗатта янып яшәгәндә арабыздан китеп барды.

Ни булса да, без бүген үзләренең иҗатларын, талантларын татар сәнгатенә, татар сәхнәсенә багышлаган Харисовлар гаиләсен зур хөрмәт һәм рәхмәт белән искә алабыз. Аларның театр һәм эстрада дөньясында үзләре салган тирән, якты эзләре бар.

Луара ШАКИРҖАН,
Татарстанның халык артисты.

● 1966. Н.Исәнбәт. «Миркәй белән Айсылу». А.Хәйруллина, А.Харисова.

● ГИТИС, татар студиясе. Уртада Ширияздан Сарымсаков.

● ГИТИС тәмамлаган артистлар: 1 рәттә – Р.Әхмәрова, Г.Камалова, А.Хәйруллина, З.Колбарисова, А.Харисова. 2 рәттә – Х.Кумысников, Ш.Әсфәндиярова, Ш.Харисов.

Онытылмас

Күренекле нәфис сүз остасы, конферансье, ТАССРның атказанган артисты Әзәл Яһудиннең туына быел 21 декабрьдә 115 ел тулды

Әзәл Бәдретдин улы Яһудин 1908 елның 21 декабрендә ТАССРның Әлки районы Яңа Чаллы авылында күп балалы гаиләдә дөньяга килә. Әти-әнисе Бибимахифәттәй һәм Бәдретдин хәлфә укытучылар була. Ул яшьтән үк белемгә омтыла, абыйлары белән башта мәдрәсәдә, аннары җидееллык мәктәптә укый. Шигырьләр иҗат итүче, гармунда уйнаучы абыйсы Әхәт Әзәлне дә үз артыннан калдырмый, гармунда уйнарга өйрәтә, алар мәктәптә үзешчән сәнгатьтә актив катнаша.

«Сәхнәгә мин драма артисты булып түгел, нәфис сүз сүз белән кердем дисәм, ялгыш булмас. Нәрсәдән, кайсы шагыйрьдән башларга? Бәлки Габдулла Тукайдандыр? Чөнки мин бөек шагыйрьнең шигырен телем ачылгач та, сөйли башлаганмын. Соңрак граммофон тәлинкәсеннән Габдулла Кариев язмасында «Ысул кадимче»дән ике юллыкны отып алганмын да, шуны теләсә кайда такмалап йөргәнмен», – дип искә ала Әзәл ага үз истәлекләрендә.

1927-1930 елларда ул Казан театр техникумында белем ала. Сабантуйда куелган «12 ел сөргендә» исемле спектакльдә катнаша. Беренче тапкыр зур сәхнәгә аяк басуы шуннан башлана.

1930 елда инде Әстерхан Татар дәүләт драма театрында профессиональ артист буларак иҗади эшчәнлеген башлый. «1930-1933 елларда Әстерхан Татар дәүләт театрында артист булып эшләдем. Театрга татар театр техникумының 4 нче курсында укыганда театр директоры чакыруы белән киттем», – дип яза Әзәл ага «Юллар истәлеге» кульязмасында.

Әзәл Яһудин Казанга кайтып, 1935-1938 елларда Татар дәүләт академия театрының колхоз филиалында; 1938-1949 елларда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында эшли. Ул танылган классик язучылар В.Шекспир, Н.Гоголь, К.Тинчурин, Җ.Фәйзи һ.б. әсәрләре буенча куелган спектакльләрдә төп рольләрдә уйный. М.Әмирнең «Тормыш җыры»нда Басыйр, Т.Гыйззәтнең «Чаткылар»ында Шәриф, В.Шекспирның «Король лир»ында Шут, Н.Гогольнең «Ревизор» әсәрендә Бобчинский һ.б. дистәләгән театраль рольләре була.

Бу елларда ул булачак тормыш иптәше, җырчы һәм актриса Мәстүрә Абканаева белән театрда таныша. Мәстүрә ханым бик матур җырлый торган була, ул 1938-1945 елларда Татар дәүләт филармониясе эстрада бүлегендә һәм Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә дә эшләп ала. 1935 елда алар гаилә кора, 1940 елда уллары Ринат туа. Бөек Ватан сугышы елларында Әзәл Яһудин тормыш иптәше белән бергә госпитальләрдә шефлык концертларында чыгыш ясый.

1950 елның 1 гыйнварыннан Ә.Яһудин иҗат эшчәнлеген Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә нәфис сүз остасы буларак дәвам итә. Ул бирегә әзер репертуар белән килә һәм анда Г.Тукай, М.Җәлил, Ф.Кәрим, Һ.Такташ шигърияте, Г.Әпсәләмов, Г.Кутуй әсәрләре төп урынны алып тора. Заманында Татар дәүләт филармониясе Салих Сәйдәшевнең Урта Азия буйлап иҗат концертларын оештыра. Анда Рәшит Ваһапов, Әсма Шәйморатова, Фәйзи Биккинин, Илдар Мәҗитовлар катнаша. Шул уңайдан Нәкый Исәнбәт «Татарстан сәламе» исемле әсәрен иҗат итә. Әзәл Яһудин әлеге әсәрне җыр-музыка белән баетып, концертларны шуның белән башлап, зур уңыш казана торган була.

Ә.Яһудин филармониядә эшләгәндә Усман Әлмиев, Илһам Шакиров, Җәвәһирә Сәләхова, Зифа Басыйрова, Динә Сираҗетдинова, Флюра Сөләйманова, Гани Вәлиев, Вафирә Гыйззәтуллина, Татар дәүләт опера һәм балет театры артистлары Фәхри Насретдинов, Шәфика Котдусова, Венера Шәрипова, Мөнир Якупов, Зилә Сөнгатуллина һ.б.ның концертларын алып бара. Аның иҗатының күп өлеше Татарстанның халык артисты Рәшит Ваһаповның концерт бригадалары белән үтә. Ул аның концерт бригадасында нәфис сүз остасы һәм конферансье буларак элеккеге Советлар Союзының татарлар яши торган бик күп төбәкләрендә була, алар бергә меңләгән концертлар бирә.

Ә.Яһудиннең репертуарында Г.Тукайның лирик һәм сатира әсәрләре, аның «Шүрәле»се, Һ.Такташның «Мокамае» һәм «Мәхәббәт тәүбәсе», М.Җәлилнең «Моабит дәфтәре»ннән шигырьләре, Ә.Фәйзинең «Гармун»ы, Н.Исәнбәтнең «Татарстан сәламе» һәм «Әптери абзый әкияте», Ш.Маннур, Ә.Давыдов, Р.Фәйзуллин, Г.Рәхим, Ш.Маннапов, Р.Гаташ, Ф.Яруллин әсәрләре дә киң урын ала. Шулай ук Г.Афзалның «Күрде безнең башлар» дигән юмор әсәре, Х.Туфанның «Соңгы мамонт» поэмасыннан «Башлана башлады» өзеге, Г.Әпсәләмовның «Алтын йолдыз» романыннан «Шаһиевнын өйләнүе» дигән өзеге һ.б. бар. Ә инде Ф.Кәримнең «Кыңгыраулы яшел гармун»ы сүз остасының бик оста итеп озак еллар буе яратып башкарган әсәрләреннән була. Ул аны кыңгыраулы гармунында уйнап сөйләгән.

1976 елда хатыны Мәстүрә вафат булгач, моңсуланып йөргән көннәрендә ул җырчы Зәйтүнә Әхтәмова белән таныша һәм алар гаилә кора. ТАССРның атказанган артисткасы Зәйтүнә Әхтәмова гомере буе Г.Тукай исемендәге Татар филармониясендә эшләгән, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле хоры җырчысы булган. Алар егерме елдан артык бергә гомер кичерә, әле лаеклы ялга киткәч тә иҗади эшчәнлекләрен туктатмый, төрле концерт-кичәләрдә чыгыш ясый. Әзәл ага гомеренең соңгы елларына кадәр Татар дәүләт фольклор үзәгендә һәм Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының сирәк кульязмалар бүлегендә эшли, татар сәнгатенә, татар әдәбиятына галим, фольклорчы буларак та зур өлеш кертә. Әле шактый өлкән яшьтә булуына карамастан, 1993 елда Түмән өлкәсенә кадәр барып, онытыла башлаган бәет-мөнәҗәтләрне туплап кайта. 1997 елның көзендә туксан яшенә таба барганда, Әзәл ага бакыйлыкка күчә, Казанда Татар зиратында җирләнә.

Зәйтүнә апа Әзәл ага дөньядан киткәч тә, аны бик сагынып яшәде, аның турында сөйләгәндә күзләрендә һәрчак яшьләнә иде. Ул филармониягә бик еш килеп йөрде, Әзәл аганы искә алу кичәләрендә дә чыгыш ясады. 2010 елның көзендә Зәйтүнә апа да арабыздан китте. Әзәл аганың улы Ринат әфәнде бүгенге көндә Новосибирск шәһәрендә яши, Россиянең атказанган метеорологы, география фәннәре кандидаты. Милли җанлы шәхес буларак, ул җирле төбәктә төрле татар кичәләре, очрашулар оештыра. Әти-әнисе турында язылган истәлекләрен безгә дә җибәрде.

Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе музеенның тәкъдимнәр дәфтәрендә нәфис сүз остасы, Татарстанның атказанган артисты Әзәл ага Яһудиннең дә язып калдырган мондый юллары бар:

«Хөрмәтле, якын, газиз сәхнәдәш дуслар! Ниһаять, бөек шагыйребез Г.Тукай исемен йөрткән дәүләт филармониясендә дә музей ачу эшләре башланган. Бу эшкә алынган иптәшләргә мең рәхмәт. Хәерле юлга, чордашлар, яшьтәшләр, сәхнәдәшләр! Яктыртыйк филармониянең үткән авыр, данлыклы, героик юлын!»

Инде бу еллар эчендә архивта филармония тарихын яктырткан шактый гына бай мәгълүмат, кызыклы гына экспонатлар тупланды. Алар арасында Әзәл ага Яһудиннең сәхнә эшчәнлегенең иң якты мизгелләрен язып барган сәхнәдәшләре, замандашлары турындагы юмор белән өретелгән «Артист язмалары» да бар. Бүген инде саргайган бу кульязмалар музей архивында кадерләп саклана. Чөнки аларда сәхнә остасының күпкырлы иҗади эшчәнлеге һәм башка сәнгать әһелләренең үзенчәлекле, гыйбрәтле язмышлары сүрәтләнә. Бу истәлекле сәхифәләр 2002 елда Әзәл ага Яһудин турындагы истәлекләр китабында да (мөхәррире: Шамил Маннапов, төзүчеләре: Рафаэль Сальмушев, Алсу Хәлилова) урын алган иде. Аларның кайберләренә күз салыйк.

«Артист язмалары»

Шәмәрдәннән Казанга ничә көнлек юл. Сугыштан соңгы елларда тимер юлларда йөрү бик авыр иде. Без – танылган җырчыбыз Гөлсем апа Сөләйманова һәм берничә артист Саба районында концертлар уздыргач, Шәмәрдәндә поездга утырып, Казанга кайтырга ниятләдек. Ләкин Шәмәрдәнгә килгәч аптырап калдык, кая ул поездга утыру? Вокзал халык белән шыгрым тулы, кассага якын барырлык түгел. Ә көн кичкә авыша, вакыт үтә, нишләргә?..

Менә бүрәнәләр төягән вагоннар белән йөк поезды килеп туктады. Без бүрәнәләргә ябышып мендек тә, шулар арасына сырыштык. Гөлсем апа егылмас өчен бүрәнәне кочаклап бара. Шулай Арчага килеп, Арча-Казан поездына утырып, Казанга кайту нияте иде. Арчага җиткәч, поездга чаптык, ләкин без килеп җиткәнче соңгы поезд да китеп барды. Нишлисең? Арча вокзалында төнне уздырып, икенче көнне көндез генә Казанга кайтып җитә алдык. Шулай итеп Шәмәрдәннән Казанга ике көнлек юл икәнен белдек.

«Беркем сизмәде...»

Драма артистына сәхнәдә нинди генә рольләрдә уйнарга, кем генә булырга туры килми?! Таҗи Гыйззәтнең «Чаткылар» спектаклендә каз өмәсенә җыелган кызлар җырлап эшләгәндә Рокыя Ибраһимова аларга гармунда уйный иде. Менә берзаман Рокыя ниндидер сәбәп белән килә алмады. Хәзер нишләргә? Алып баручы Мәрьям апа Чанышева: "Ә ник аптырап калырга, безнең Әзәл безнең гармунда уйный ич, ул керсен гармун уйнарга кыз булып», – дип әйтте дә салды. Мине тиз генә кызларча киендереп, гәүдәне бераз үзгәртеп, толымлы чәч-парик кидереп, грим салып чыгардылар сәхнәгә. Уйнадым шул, беркем дә сизмәде бу хәйләне!

талант иясе

● Сулдан: Гали Җәмлиханов, Әзәл Яһүдин, Фәйзи Садыйков.

– Менә күрдеңме, кыз булу берни түгел, гармунда уйнарга өйрәнүдән күпкә җиңел ул, – дип, шаяртты соңыннан Мәрьям апа.

Борын...

Атаклы артист Ситдыйк Айдаров бик тапкыр, җор артист иде. Сәхнәдә берәр көтелмәгән хәл килеп чыкса, бер дә югалып калмый, җаен таба иде.

Әле дә хәтеремдә: бер спектакльдә аның шактый зур һәм озын борын ясап уйнаганы. Менә бервакыт уен барышында, «су эчәм» дип стаканны авызына китергән иде, ясалма борын стакан кырыена ябышты да калды. Ситдыйк ага «ә» дигәнче, борынны куптарып алып, күз йомганчы уз урынына ябыштырып та куйды. Тамашачылар сизми дә калды.

«Тенор да, бас та булып җырла»

Татар филармониясенә яңа килгән бер директорга җырчы килеп, эшкә керергә дип гариза бирә.

Директор:

– Нинди тавыш белән җырлыйсыз? – ди.

– Минем тавышым тенор, – ди җырчы.

Директор:

– Һе, әгәр дә сез менә концертның беренче бүлегендә тенор, икенче өлешендә бас тавыш белән җырласагыз, эшкә алыр идем, тенор белән генә филармониягә эшкә ала алмыйм, – ди, җырчыны шаккатырып.

Әллүкидән Зиләйлүккә...

Бер концертта җырчы Зифа Басыйрова «Әллүки» көен башкара. Җырның уртасында Зифабыз үзе дә сизмәстән Әллүки көеннән Зиләйлүк дип сузып җибәрде һәм үзе дә, аптырап, җырдан туктап калды. Аннары көлеп җибәрде дә «Әллүки!» дип янадан җырлап китте һәм җырны бу көй белән тәгәлләде.

Әтине арытмагыз

1947 елда Әгерҗе районына гастрольгә улыбыз Ринатны да алып чыктык. Ул һәрвакыт залда алдагы рәттә утыра.

Мин юмористик әсәрләр укыганда тамашачы көлә башлый. Ринат артка борыла да: «Көлмәгез! Әтигә комачаулыйсыз! – ди. Әсәрне башкаргач, халык гөрләтеп кул чаба. Ринат улым, тагын артка борыла да: «Кул чапмагыз, әтиемне арытасыз!» – дип ачулана. Менә ничек кайгырта иде минем турында улым Ринат!

Ерып чыктык

Бер гастрольдә яңгынчылар сараенда чыгыш ясыйбыз. Котырып яңгыр ява һәм сарайның идәненә су керә башлады. Тамашачылар аякларын күтәреп суга чыланмаска тырыша. Су электр чылбырына үтеп, ут уйный башлады. Сәгыйт Алиевның гавай гитарасы эшләүдән туктады, хәйран гына җырлагач, мондый шартларда Рәшитнең тавышының да рәте китте. Ә концертны дәвам итү мондый чакларда кем өстенә төшә? Билгеле, алып баручыга – ягъни без бәндәгезгә. Уңышлы гына ерып чыктык тәки.

Исән калдым

1950 нче елларда Урал якларында гастрольдә йөрибез. Зур гына мәдәният сараенда концертны башлау өчен сәхнәгә чыгып баскан идем, өстән авыр пәрдә тимерләре белән ычкынып, нәкь минем алга дөбердәп килеп төшмәсенме! Халык беравыздан «Ах!» дип, котлары чыгып кычкырды.

Мин дә тиз генә аңга килеп, үземне кулга алдым, идәндәге пәрдәләр артыннан «Борчылмагыз иптәшләр, мин исән-сау, концертны дәвам иттерәбез», дип халыкны тынычландырдым. Сәхнә эшчеләре тиз генә сәхнә пәрдәсен, тимер-томырларны алды. Концерт алга таба күтәренкелек белән үтте.

«Татарча концерт күрсәтегез»

1958 елда, Усман Әлмиев бригадасы белән Урта Азиядә гастрольдә йөргәндә, Фирганә шәһәрендә концерт куябыз. Беренче бүлектән соң, сәхнәгә бер язу килде. Анда: «Сез, артистлар, кайчан татар концерты бирерсез?» – дигән сорау куелган.

Мин концертның икенче бүлеген башлап, сәхнәгә чыктым да, «Менә иптәшләр, безгә бер сәер язу килде, аны язган иптәш: «Сез кайчан татарча концерт бирерсез?» – дигән. Без сәгатьтән артык татар телендә чыгыш ясыйбыз, җырчылар татар җырлары җырлый, мин татар шагыйрьләренең әсәрләрен татар телендә укыйм, ә иптәш әлегә кадәр концертның татар телендә баруын аңламаган икән», – дип әйткәч, бөтен зал шаулатып кул чабып, залны яңгыратып көлде.

Җаен таба белсәң

Гастрольләрдә айлар буе йөрү артистларны бик арыта, талчыктыра. Шуның өчен алар үзара төрле шуклыклар, мәзәкләр уйлап, күңелләрен күтәрергә тырыша.

Бер гастрольдә Рәшит Ваһапов белән Динә Сиражетдинова ядәч аерышалар. Ләкин һич кенә дә берсен-берсе ота алмый болар. Көннәр үтә. Рәшит концертның ахырында җырлый, соңгы җырны Динә белән бергәләп «Башмагым»нан дуэт башкаралар. Динә җырларга чыккач, Рәшиткә: «Тиреңне сөрт», – дип кулъяулык тоттыра. Һәм аның колагына «ядәч» дип пышылдый. Рәшит җырлаганда, билгеле, «Исемдә» дип әйтә алмый кала. Шулай итеп, оту өчен Динә тәки җаен таба.

Истәлекләрне Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе музее мөдире Алсу ХӘКИМОВА туплады.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

30 декабрь (шимбә). ***Җомәдел ахир аеның 17 нче көне. 19 нчы Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 19.35 сәгатьтә калка, 11.32 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 7.03 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Күп аралашмаска, күз тиюдән, чит тәэсирләрдән сакланырга кирәк. Бурычка алырга да, бирергә дә ярамый. Нерв системасы, эчәклек, арканың өске өлеше зәгыйфь.

Стенокардияне тары дәвалый

Тары ярмасында йөрәкнең нормаль эшчәнлеге өчен кирәкле калий күп. Стенокардия булганда, көн саен тары боткасы ашау файдалы. Башта тары ярмасын бик көчле утта кыздырып алалар, тик төсе үзгәрмәсен. Аннары өчтән бер стакан кыздырылган тары ярмасын юып, өчтән ике стакан суда сүрән утта пешерәләр. Бу – йөрәгә авырткан кеше өчен тәүлеклек норма.

31 декабрь (якшәмбе). ***Җомәдел ахир аеның 18 нче көне. 20 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 20.54 сәгатьтә калка, 11.41 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 7.04 сәгать.***

Үз-үзеңне танып-белү, уйлану көне. Өйдә булырга тырышырга, гаиләгә игътибарны арттырырга кирәк. Тәкәбберлек күрсәтергә ярамый. Яңа белем җиңел үзләштерелә. Нерв системасы, сизү әгъзалары, кан тамырлары, ашказаны зәгыйфь. Ит ашауны чикләү хәерле.

Баллы май

Ашказаны җәрәхәтен болай дәвалап була. Ярты кило бал һәм ярты литр зәйтүн маен кушып, пыяла банкада суыткычта саклыйлар. Кулланыр алдыннан һәрвакыт агач кашык белән болгаталар. Көненә 3 тапкыр 1әр аш кашыгы кушылманы ашарга ярты сәгать кала кабалар. Әзерләнгәне беткәч, 1 ай ял итәләр, аннары кабат дәваланалар. Диетаны һәм туклану режимын саклаганда, җәрәхәт төзәлә.

1 гыйнвар (дүшәмбе). ***Җомәдел ахир аеның 19 нчы көне. 21 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 21.25 сәгатьтә калка, 11.01 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 7.06 сәгать.***

Сәяхәткә чыгу, теләсә нинди эш башлау өчен айның иң кулай көне. Кеше хәлиткеч карарлар кабул итәргә сәләтле. Физик эш белән шөгыльләнү, җәяү йөрү, чыныгу файдалы. Саф һавада күбрәк булу, табигать белән хозурлану кәефне күтәрә. Умыртка лыкның аскы өлеше, әвернә сөяк, аяк зәгыйфь.

Эт шомырты

Дәвалау үзлекләрен тупласын өчен, эт шомырты (крушина) кайрысы, салдырып алганнан соң, 1 ел ятарга яки 1 сәгать буе 100 градуста җылытылырга тиеш, алайса ашказанын авырттырырга, күңелне болгатырга мөмкин. Эчне йомшарта торган төнәтмә әзерләгәндә, 1 аш кашыгы вакланган кайрыны ярты литр суга салып, кайнатып чыгаралар һәм 15 минут буе сүрән утта пешерәләр. Сөзеп, иртән яки төнгелеккә ярты стакан эчәләр. Төнәтмә 8-10 сәгатьтән соң тәэсир итә, организм аңа күнекми.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

2 гыйнвар (сишәмбе). Җөмәдел ахир аеның 20 нче көне. 22 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 22.37 сәгатьтә калка, 11.05 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 7.07 сәгать.

Акыл җыю, белем алу, фәннәр өйрәнү көне. Юмарт булырга, ашау-эчүдә үзеңне чикләмәскә кирәк. Күбрәк аралашкан саен, яхшы тәэсирләр дә арта бара. Кан әйләнеше системасы, буыннар, умырткалык зәгыйфь.

Лимон сихәте

Лимон согы бөер ташы авырулары вакытында, матдәләр алмашы бозылганда бик файдалы. Ярты лимон согын ярты стакан кайнар суга сыгып, көненә 2-3 тапкыр эчәргә кирәк. Төркиядә һәм Тибетта исә яшьлек эликсиры бик популяр: 2 өлеш лимон согы, 4 өлеш бал, 1 өлеш көнбагыш (яки зәйтүн) маен кушалар да, һәр көнне иртән ач карынга 1 чәй кашыгы кабалар.

3 гыйнвар (чәршәмбе). Җөмәдел ахир аеның 21 нче көне. 22 нче Ай тәүлегенең дәвамы. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 23.53 сәгатьтә калка, 11.09 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 7.09 сәгать.

Акыл җыю, белем алу, фәннәр өйрәнү көне. Юмарт булырга, ашау-эчүдә үзеңне чикләмәскә кирәк. Күбрәк аралашкан саен, яхшы тәэсирләр дә арта бара. Кан әйләнеше системасы, буыннар, умырткалык зәгыйфь.

4 гыйнвар (пәнҗешәмбе). Җөмәдел ахир аеның 22 нче көне. 23 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 0.30 сәгатьтә калка, 11.13 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 7.10 сәгать.

Авыр энергетикалы көн. Тәвәккәл адымнар ясау хупланмый. Арып-талганчы эшләргә киңәш ителми. Дару үләннәре белән дәвалану уңай нәтиҗә бирә. Иҗат белән шөгыльләнү өчен яхшы вакыт.

Бөерне чистарту

Бөердәге фосфат ташларын чыгару һәм алар ясалуны кисәтү өчен, 1 аш кашыгы киптереп вакланган каен җиләге яфрагын 2 стакан салкын суга салып, сүрән утта кайнатып чыгаралар, 15 минут пешерәләр, уттан алып, җылы итеп төрәләр һәм 3 сәгать төнәтәләр. Сөзеп, көненә яртышар стакан эчәләр. Дәва курсы – 2 атна. Яисә бәрәңге кабыгы белән дәваланырга була, тик аны химия кулланмыйча үстерергә һәм казып алгач 2-3 ай эчендә кулланырга кирәк. 1 литр суга 2 уч бәрәңге кабыгын салып, йомшарганчы пешерәләр, тукыма аша сөзеп, ашар алдыннан, көненә 2-3 тапкыр яртышар стакан эчәләр. Дәва курсы – 2 атна.

5 гыйнвар (җомга). Җөмәдел ахир аеның 23 нче көне. 24 нче Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында, 1.11 сәгатьтә калка, 11.19 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 7.12 сәгать.

Артык активлык күрсәтү хупланмый. Ялгыз калып уйлану өчен уңай вакыт. Эчке тавышка колак салу файдалы. Бизләр системасы, кан тамырлары, тире, эчәклек зәгыйфь. Күзне арытмаска кирәк.

Чикләвекле кәнфит

1 әр стакан шикәр, вакланган чикләвек һәм салкын сөтне яхшылап болгатып, кайнатып чыгаралар, сүрән утта, әледән-әле болгаткалап, куерганчы пешерәләр. Сөт парга әйләнә башлагач, чикләвек янмасын өчен, гел болгатырга кирәк. Тәлинкәне майлап, куе массаны шунда җәяләр, суынгач, кисәләр.

Кешене ышаныч һәм өмет яшәтә

(Ахыры. Башы 3 нче биттә).

Сайлауларга әзерлек ҮСК составын билгеләү принциплары белән дә гарантияләнә. Ә ул инде күптәннән формалаштырылган һәм ошбу системада тәҗрибә дә тупларга өлгергән. Алай гына түгел, аның әгъзалары инде югары дәрәҗәдә бәяләнүгә дә лаек булды. Узган айда президент В.Путин ҮСК рәисенә һәм ДНР сайлау комиссиясе вәкилләренә, түземлелек һәм яхшы эшләгәннәре өчен, ҮСКның 30 еллыгына туры китереп, дәүләт бүләкләре тапшырды. ҮСК рәисе Э. Памфилова, әйтик, II дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләнде. В.Путин анда сайлауларны дәүләтнең иң мөһим институтларыннан берсе буларак бәяләде һәм: «Доверие к выборам в России существенно выросло», – дип белдерде.

Шуңа да игътибар итик, В.Путин бу юлы президентлыкка кандидат булып, партия исеменнән түгел, ә үзлегеннән теркәлергә карар кылды һәм сайлау алды тактикасы ягыннан бу аңлашыла да. Инде инициатив төркем дә оешты һәм кандидатны рәсми төстә теркәтү хәстәренә кереште. Ул арада, кинәт «ятим калган» «Бердәм Россия» партиясенең чираттагы съезды үтте һәм анда төп кандидатны яклап чыгу турында карар кабул ителде. Күрүебезчә, бер яктан, сайлау алды гамәлләренең урыннары алышынды да кебек. Әмма, кем әйтмешли, кушылучыларның урынын алыштырудан сумма үзгәрми. Икенче яктан, В.Путинның бу сайлауда үзлегеннән чыгуы илдәге сайлау системасының мөмкинлекләрен күрсәтү гамәле дә булып тора кебек (менә, янәсе, югары вазыйфага үзлегеннән чыгып та сайланып була. Әмма, бөтен хикмәт шунда ки – моның өчен Путин булу кирәк). Иң кызыклысы – 17 мартта югары вазыйфага кем сайланасын бүген инде бар халык чамалый. Ә гамәлдәге сайлау системасының асылы шуның белән билгеләнә дә. Шуңа күрә, сайлауга чыгарылачак башка кандидатларга да (ә дәгъва итүчеләр инде 16 икән), мөгаен, әмәлләнә китерү һәм анда мөмкин кадәр күбрәк сайлаучыны җәлеп итү өчен күрсәтелгән ышанычлы затлар итеп кенә карарга кирәктер.

Айның башка мөһим вакыйгаларына килгәндә, алар рәтенә шулай ук РФ президенты В.Путинның 14 декабрьдә катлаулы форматта (ел йомгакларына халык белән туры линиядә аралашуны кушып) үткәргән матбугат конференциясен кертергә буладыр. Ә анда инде аңа, геосәяси проблемалардан (Украинадагы хәлләр, Якын Көнчыгыштагы вазгыять һ.б.) алып, тавык йомыркасына бәягә кадәр (ул авыл хуҗалыгы министрыннан: «Как у вас с яйцами?» дип соравы турында да сөйләде) сорауларга җавап бирергә туры килде. Украина хакында ул, үзе үк таныганча, инде күп мәртәбәләр сөйләгәннәрен тагын бер кат кабатлап җавап бирде. Ә алга куйган максатларга ирешү-ирешмәү турындагы сорауга җавапны инде һәркем, махсус хәрби операциянең максатларын (демилитаризация, денацификация, НАТОның көнчыгышка киңәюенә юл куймау) аның бүгенге нәтиҗәләре белән чагыштырып та таба ала. Президент үзе Украинадагы хәлләрне: «И то, что сейчас происходит, – это огромная трагедия, похожая на гражданскую войну, когда братья оказались по разную сторону», – дип, яңачарак бәяләде. АКШ ны исә ул империячел сәясәттә, үз мәнфәгатьләрен санкцияләр һәм хәрби юл белән хәл итәргә омтылуда гаепләде, андый юл аның үзенә дә комачаулавы турында белдерде.

Игътибарны тагын В.Путинның ясалма интеллект турындагы фикерләре дә җәлеп итә. Әйе, алар шактый ук каршылыклы күренә. Бер яктан, ул ясалма интеллектның үсешен (аның үз-үзен үстерә торган югары формасын да кертеп) туктату мөмкинлеге булмавы турындагы бәхәсле фикерләрне таный да кебек. Шул ук вакытта: «Значит, нужно сделать все для того, чтобы мы могли быть одними из лидеров в этом направлении», – дип тә белдерә. Әлбәттә, әлеге катлаулы проблема – үзе бер зур тема һәм ул җентекләп өйрәнүне таләп итә. Әлегә исә, шуны истә тотып, акылның кешегә Аллаһ тарафыннан бирелүен, ә интеллектны ясалма итү, асылда, Аның шөгыленә тыкшыну булуын искәртү белән генә чикләник.

Әлеге матбугат очрашуында сүз Татарстан турында да булды. В.Путин аның беренче президенты һәм бүгенге җитәкчесе эшен югары бәяләде, ә республикадагы казанышларны, исемен атап әйтмәсә дә, төп халыкның әчке культура дәрәҗәсе белән аңлатты. Татарстанның төрле конфессияләр арасында һәм ислам илләре белән мөнәсәбәтләрне дөрес урнаштыруын В.Путин бөтен ил өчен үрнәк итеп тә куйды. Ә Казанның 2024 елда БРИКС саммиты үткәрү урыны итеп сайлануын ул: «Это связано с тем, что Татарстан развивается хорошо, а Казань – один из наилучших примеров такого развития. Условия созданы хорошие», – дип аңлатты. Матбугат очрашуы үзе исә, гадәттәгечә, илдә гаять мөһим вакыйга итеп бирелде. Шуның белән бергә, сәяси планда ул гавам өчен чираттагы «пар чыгарып алу» чарасы да булып тора.

Инде декабрьнең кайбер башка вакыйгаларын да санап үтик: Дубайда COP28 дигән Халыкара климат саммиты; президент В.Путин РФ коралы көчләренең гомуми штаттагы санын 2,2 миллион кешегә җиткерү турында указга кул куюы; Пекинда ЕС – КХР саммиты; Брюссельдә ЕС очрашуы; Мәскәүдә БДБ илләренең хөкүмәт башлыклары советы һәм РФ Саклану министрлыгының киңәйтелгән коллегиясе; РФ хөкүмәте башлыгы М.Мишустинның Кытайга сәфәре һ.б. Ишарәле вакыйгалардан исә: Брюссельнең Украинаны ЕС составына алу буенча сөйләшүләргә чакыруын; ЕС ның алдагы 4 елга Украинага бүленәчәк 50 млрд евро күләмендәге финанс ярдәме буенча сөйләшүнең, Венгрия риза булмау сәбәпле, 2024 елның февраль башына күчерелүен; АКШ Конгрессында Украинага алдагы 4 елга тәгаенләнгән 61 млрд доллар күләмендәге финанс ярдәме күрсәтү турындагы закон проектын карауның, «демократлар» белән «республикачылар» арасында бу илдә 2024 елның ноябрендә булачак президент сайлавы белән бәйле бәхәсләр башлануы нәтиҗәсендә, гыйнварга күчерелүен; РФ Үзәк банкының төп еллык ставканы 16 процентка кадәр күтәрергә мәҗбүр булуын һәм кайбер башка шундый хәлләрне билгеләп үтәргә була.

Көнбатыш бүген Россиянең анда «туңдырылган» активларын (Европада – 300 млрд, Америкада исә 50 млрд доллар күләмендә) Украинага финанс ярдәме итеп куллану темасын да бик актив куерта. Бу юнәлештәге эшләр ЕС һәм G7 структуралары аша башкарыла икән. Әмма МВФ мондый адымның глобаль дәрәҗәдә финанс тотрыклылыгын какшатуга китерү мөмкинлеге турында да искәртә. Гәрчә Мәскәү Көнбатышның Украинадан инде тәмам гарык булуы турында бик тәмләп сөйләсә дә, аңа финанс ярдәме күрсәтү проблемасы Вашингтонда да, Брюссельдә дә хәл ителер кебек. Чөнки, әйтик, АКШ Конгрессындагы ике партиянең дә идарә җепләре дөнья тотучылар кулында. Димәк, ахыргы карар да алар файдасына булачак. ЕС исә консенсуска, янә Венгрияне җайлап (начар тәртибе өчен бирелми калган 30 миллиард долларның тагын 10 миллиардын аңа биреп) ирешер кебек.

Елның гомуми йомгакларына килгәндә, ни кызганыч, узып баручы елда кешелек дөньясы упкын читенә тагын да якынлашты кебек. Украинадагы фаҗигале хәлләргә, Якын Көнчыгыштагы канлы низагның яңартылуы да өстәлде. Ә соңгы көннәрдә Кызыл диңгездә инде Йәмән хөситләре провокациясе белән бәйле янә бер конфликт туып килә. Әйтик, Венесуэланың Гаянага территориаль дәгъва белдерүе дә җәлеп итә. Димәк, яңа киеренкелек ноктасы инде Көньяк Америкада да булдырыла дигән сүз. Аларны нәрсә берләштерә соң? Уртаклык, миңа калса, кулланылган провокацияләрнең охшашлыгында һәм геосәяси планда бәйләнеше буларак күренә. Төп максат – моңа кадәр кулланылган рухи кыйммәтләр һәм халыкара нормаларны җимерел, яңа дөньяви тәртип урнаштыру өчен җирлек булдыру. Дикъкать итик, АКШ президенты Джо Байденның Россияне, «Украинада җиңгән очракта, НАТО илләренә дә һөҗүм итәчәк», дип гаепләвенә, узган атнада РФ президенты В.Путин: «Нет желания испортить с ними отношения. Мы заинтересованы в развитии отношений», – дип җавап бирде. Димәк, зурдан алганда, Көнбатыш һәм Россия, капма-каршы яктан, әмма уртак максатларда эш итә булып чыга. Ә әлегә иске дөньяви тәртипне җимерү дәвам итә.

Язма ахырында инде җаһил заманның янә бер четерекле мәсьәләсенә тукталып үтик. Ул милләтара мөнәсәбәтләргә кагыла. Бүген сәяси даирәләрдә «русофобия», «исламофобия» кебек төшенчәләрне шактый еш иштетергә туры килә. Миңа калса, алар – сәяси максатлы, җаһил кулланышлы төшенчә. Чөнки чын мәгънәдә цивилизацияле җәмгыятьтә берниди дә «фобиялэр» була алмый. Ә тискәре мөнәсәбәтләргә килгәндә, аларны дөнья тотучыларның әлеге тәнкыйть субъектларын сәясәт коралы итеп куллануына халыкара җәмәгатьчелекнең реакциясе дип карарга кирәктер. Чөнки бу четерекле тема гаммәви мәгълүмат чаралары аша төрле шоу-программалар ярдәмендә бик күп еллар дәвамында куертылып килде. Мәгәр, мәсьәләнең икенче ягы да бар. Бүген бәгъзеләр, бик төчеләнеп китеп, сәяси максатларда «русский татарин», «русский еврей» кебек төшенчәләрне дә куллана. Ә моны инде купшы сүзләр артына яшерелгән бөекдержавачыл шовинизм галәмәте, дип карарга кирәктер. Милли рухын, туган телен, горефен югалткан кемдер шәхси планда, бәлки, үзен шулай дип саный да аладыр. Ләкин бөтен бер милләт кемнедер була алмый. Чөнки ул – фәкать Хак Тәгаләнеке.

Кызганычка, 2023 ел татар өчен дә, милләт буларак, нииндидер казанышлар китермәде. Бу – дәүләт тарафыннан максатчан үткәрелгән милли ассимиляция сәясәте нәтиҗәсе. БДИне милли мәктәпләрдә дә урыс телендә генә тапшыруны таләп иткән ул мәкерле сәясәт үзенең кара эшен төгәл эшләде – бүген инде татар мәктәбенең дә тамырына балта чабылды. Шуңа хәлләр татар теленең кулланышы белән дә мөшкел. Инде язма башындагы сорауны янә искә төшерик: мондый шартларда кемгә ышанырга һәм нәрсәгә өметләнергә? Ә җавап гади: Хак Тәгаләгә һәм үз-үзеңә ышанырга. Шөкер, Күкләр бүген татарга һәр тарафтан хәерхаһлы. Ә үз-үзенә ышану әлегә аңа җитми. Бу уңайдан хәтта урыс халкында да: «На Бога надейся, а сам не плошай» дигән мәкаль бар. Ә үз-үзенә ышанычы җитмәү милләткә тулаем да кагыла. Шуңа, халкыбызга яңа елда иминлек, үз-үзенә ныклы ышаныч булдыруын, югары дәрәҗәдә үзоешуын һәм Урталык җирләрендә, чыннан да, тотрыклылык һәм рухи яңарыш факторына әверелүен телим.

Фоат УРАЗАЙ.

Нәфис ӘХМӘТ

Аһ, хикмәтле бәрәңге!..

(Юмореска)

Җырда гына мактап җырлана ул «ак тәнле, бик тәмле бәрәңге». Җыр сүзләре искермәсә дә, элекке бәрәңге белән хәзерге бәрәңгенең аермасын утыртып үстергән кеше яхшы чамалый. Узган гасырның җитмешенче еллар ахырыннан үз бәясен нык күтәрде «икенче икмәк» дип атап, иркәләп үстергән ризыгыбыз. Элек утырта идек тә, беркат төбен күмеп, көзен ала идек, базга сала идек. Артыгын әле сата да идек. Хәзер, сөйләсәң сүз, төртсәң күз. Гел аның өстендә үтә җәйнең матур вакыты. Чүбен утыйсың, кортына әллә ничә тапкыр агу сибәсең, төбен дә бер генә күммисең әле. Ике меңнән артык төре исәпләнә икән бәрәңгенең. Без бәләкәй чакта алай күп сортлары бар сыман түгел иде кебек. Булгандыр инде ул чакта да, без авыл кешесе генә каян белеп бетерсен аны. Кытыршы тышлы караңгы кызыл төсле бәрәңгене без бәләкәй чакта «әрмән бәрәңгесе» дип атый идек, эре, яхшы уңганга шулай аталгандыр инде. Бәлки, элек колхоз фермаларын таштан әрмәннәр килеп төзи иде бит. Алар эшләрен төзелештә бетереп, китәр алдыннан туган якларына күпләп алып китәргә шушы бәрәңгене авыл буйлап җыеп йөри иде.

Кайберәүләр бер баз бәрәңгесен җиңел «Жигули» машинасына алыштырып калды. Шуңа, бәлки, ул исем ябышып калгандыр. Тагын берничә төрле сары, кызыл бәрәңге барын хәтерлим, башка сортлар хәтердә калмаган. Күршеләр белән алыштыра-алыштыра үзебезчә төрен яравайлаштырып, утырта иде инде авыл халкы. Шулай әйләнештә йөреп сортлары үзгәреп беткәндер бахырларның. Хәзер заманасы да башка, бәрәңгеләрнең тәме дә икенчерәк кебек. Исемнәре бигрәк хәтәр, заманына яраклаштырып аталган: Адретта, Винета, Ривьера, Бриз, Шаман, Симфония... саный-саный хәлләр бетә. Нинди төсләре генә юк: ак, сары, крем, яшел, зәңгәр каймалы... әллә нинди төсле эчләре. Тышларының төсен, формасын, кыяфәтен әйткән дә юк. Һәр кеше, билгеле, иң тәмле дигәнен эзләп алып утыртырга тырыша. Кыш буе ашарга дигәне дә пешергәч, авызда таралып, тел йотарлык булсын!

Без дә хатын белән бәрәңгенең иң тәмлесен, эре булып уңа, кортларга бирешми торганын утыртырга булдык. Яздан көн дә иртә-кич заманча телефоннарыбызның битен сыпыра-сыпыра интернеттан ошаткан бәрәңге эзлибез. Күңелгә ятканын күрсәтешәбез, «менә кара әле, нинди бәрәңге! Менә ничек мактап язганнар, карале эрелеген!» Ахырда озаграк эзләгәнбезме, утыртырга вакыт җиткәнен сизми дә калганбыз, «бәрәңге, бәрәңге инде» дидек тә, үзебезнең моңынчы базда яткан орлыкларны алып утыртып куйдык. Алай күп утыртмыйбыз без, өч-дүрт чиләк, үзебезгә кышкылыкка җитәрлек тә, орлыклык кына. Яшь барган саен, кеше үстергән әйбергә шикләнебрәк карый башладыкмы, үзебез тәрбияләп үстергәннәргә ышаныбрак карыйбыз, бакча җимешләребезне кулланабыз. Шунысы да бар, кеше ничек үстерә бит әле, сатарга дип үстергәндә, ни генә кыланмый халык: ни белән генә тукландырмый да, ни генә сипми ул бәрәңгесенә дә, башкасына да.

Хөкүмәт эшеннән туктагач, вакытыбыз бар. Агу-мазар сипмичә генә экологик чиста бәрәңге үстереп ашыйк дип сөйләштек хатын белән. Моңынчы да агу белән бик булышмый идек анысы, үлән төнәтмәләре, сабын эремәләре сибеп мәш килә идек. Аларын да кем белгән, ничек кабул итә бит бәрәңге «организмы» ул төнәтмәләрне! Шуңа быел кортларын гел җыеп кына торырга, бернәрсә дә сипмәскә, экологик чиста бәрәңге үстерергә булдык. Йөрергә җайлы булсын, төбе бик тапталмасын дип, рәт араларын да, төп араларын да метрга якын калдырып утырттык... Үргән орлык озак көттермәде, тиз тишелеп чыкты. Аннан шәп кенә яңгыр да явып үтте. Шул беренче һәм соңгы яңгыр булды да инде ул безнең якта. Җәй озынына башка явым-төшем күренмәде...

Шуннан шул, бәрәңге тишелеп чыкты, аның яфракларына утырып теге зәхмәт буй-буй сыртлы колорадо коңгызлары да җылыга, кояшка таба күтәрелде. Җүнле әйбер булса, әллә кайчан йә беткән булырлар иде, йә кешегә зыян салмаслык булып яшәрләр иде. Океан артыннан җүнле нәрсә кайта димени инде безгә... Теге әрсезләрне бакчаның икебез ике башыннан җыя башладык хатын белән савыттагы «җимешләрне» бер-беребезгә күрсәтә-күрсәтә, маңгай тирен сөртә-сөртә, күплегенә шаккатып. Һәр төпнең, һәр яфрагын берәм-берәм сыпырып, иркәләп диярлек, җыеп чыктык игътибар белән. Хатын битендәге тирен сөртә-сөртә: «Җиңдек бит тәки, башка болай күп булмаслар инде», – диде, эшне төгәлләгәч, канәгать калып. Бу алда торган көрәшнең беренче генә көне иде...

Хәләл җефетем иртәгәсен йокыдан торып бәрәңгеләргә күз салса, ачуыннан шартлардай дәрәҗәгә җитеп, өйгә атылып кергән: «Берни булмагандай утыралар теге «дошманнар! Булмый болай, – диде хатын, өйгә кергәч, биленә таянып. – Немецларга безнең этиләр Мәскәүне бирмәгән, бу хәшәрәтләргә дә бәрәңгене биреп булмас, чигенмибез! Көн дә иртән торгач, иртәсен син, кичен мин чыгып җыябыз!» Хатын әйтсә, кырт кисеп әйтә, сүзендә таш булып ката торганнардан. Мишәр хатыннары шулайрак була бит, сүзен сүз итмичә туктамый. Каршы килеп торуның файдасы юк. Үзеңә кыйммәткә төшә. Шулай көйләдек көнебезне. Көн кыздырганчы дип, иртәрәк чыгып китәм бакчага – хатын йоклап кала. Көн кичкә авышып һава сүрелгәч – хатын эшкә тотына. Күршеләр көтү куа – мин корт чүплим. Күршеләр көтү каршылый – хатын кортлар белән көрәшә. Көн дә җыйгач, күнегеп беттек, азартка кердек, икенче сулыш барлыкка килде. Кайда күрсәм дә хәзер, «колорадо» дигәннәрен потенциаль дошманым итеп күрә башладым. Сытып юк итми торып тынычланмыйм, күземә җен булып күренәләр. Шулай көн дә иртәнге физзарядканы читкә куеп, корт чүпләүгә күчтем. Шулай җәй үтте. Җыйган буй-буйлы хәшәрәтләр белән буяудан бушаган калай савытлар тула торды. Савытларның өстен яхшылап ябып куям, шулай итмәгәндә яныннан үтеп булмый, тәмсез ис чиста авыл һавасын боза. Тулган савытны чүп җыючы машинасына гына ташлар идең, ярамый, чүп җыючы егет кызганыч... Җыю гына түгел, котылу да мәшәкатькә әйләнде алар белән...

Ниһаять, бәрәңге алыр вакыт җитте. Бәрәңгедән сабаклары көеп бара, кортларны шул темп белән җыя торабыз, ә теге җир битләр барыбер бирешмибез дигән кебек әрсезләнеп, өелгән сабакларда җай гына кояшта кызынып утыра бирә. Кайбер акыллы башлары сабактан төшеп, чүп үләне яфракларына күкәйләрен салып куя башлады. Сәгать дигәндә теге үчтекиләп үстергән бәрәңгене алып бетердек. Ни хикмәт, әллә көн дә яфрагын сыйпап торганга, бәрәңге былтыргыга караганда бермә-бер уңган булып чыкты. Җитәрлеген алып, берничә чиләген хатын белән сатырга дип аерып куйдык. Былтыргыдан барыбер артык ашап булмый бит инде. Хәзер җайлы, сатасы әйберең булса, базарга барып йөрисе түгел, интернетка белдерү эләсе дә, алучының шалтыратканын көтәсе. Мин: «Экологик чиста, агу сипмичә, яфрагын көн дә сыйпап кына үстергән бәрәңге сатам, чиләге фәлән сум», – дип язып куйдым. Җавап озак көттермәде, «Алдашып маташмагыз инде, хәзерге вакытта агу сипмичә бәрәңге үстереп буламыни? Ничә тапкыр агу сиптегез? Эче нинди? Крахмалы ничә процент? Чиләгенең бәясе күпме? Нигә шулай кыйммәт?» – сорауларына җавап биреп кенә өлгер. Телефоннан кыскача экологик чиста икәнен, кортын җыеп кына үстергәнен аңлата-аңлата тавыш бетте. Ахырда үзебез дә аңладык, халыкка экологик чиста бәрәңге кирәк түгел икән бит, халыкка очсыз бәрәңге кирәк! Безгә шул яхшы аңлашылды. Халык әйтсә хак әйтә, биргән булса, белербез киләсе елга!..

Их, бәрәңге, «ак тәнле, йомры гәүдәле» генә түгел, алтын бәһәле, мәшәкатьле, иркә, җәй буе каршыңда хуҗасын туңгайтып тотучы хикмәтле нәрсәгә әйләндең бит син хәзер. Шулай икәненә бәхәсләшә алам!



Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

29 декабрь – 14.00 – Шәрык клубында – Балалар өчен «Кышкы тылсым» исемле яңа ел квесты. 19.00 – «Ситса туй» (И.Зәйниев).
30 декабрь – 14.00 – Шәрык клубында – Балалар өчен «Кышкы тылсым» исемле яңа ел квесты. 18.00 – «Бию пәрие» (И.Зәйниев).
2 гыйнвар – «Көзге кайтаваз» (Р.Галиуллин).
3 гыйнвар – 12.00 – «Көзге кайтаваз» (Р.Галиуллин). 14.00 – Шәрык клубында – Балалар өчен «Кышкы тылсым» исемле яңа ел квесты. 18.00 – зур залда «Гөргөри кияүләре» (Т.Миңнуллин). 18.00 кече залда – «Көл» (К.Митани).
4 гыйнвар – 12.00 – «Гөргөри кияүләре» (Т.Миңнуллин). 14.00 – Шәрык клубында – Балалар өчен «Кышкы тылсым» исемле яңа ел квесты. 17.00 – Шәрык клубында – «Бичара кыз» (Г.Ильяси). 18.00 – «Сөясеңме, сөймисеңме...» (Ф.Бүләков).
5 гыйнвар – 12.00 – «Кәҗә, сарык һ.б.» (И.Зәйниев). 14.00 – Шәрык клубында – Балалар өчен «Кышкы тылсым» исемле яңа ел квесты. 18.00 – «Болганчык еллар. Мөһаҗирләр» (М.Галәү).
6 гыйнвар – 12.00 – «Кәҗә, сарык һ.б.» (И.Зәйниев).14.00 – Шәрык клубында – Балалар өчен «Кышкы тылсым» исемле яңа ел квесты. 17.00 – Шәрык клубында – «Артист» (Г.Кариев). 18.00 – «Игезәк» (Р.Зәйдулла).
7 гыйнвар – 12.00 – «Хуш, авылым» (А.Җаббаров). 14.00 – Шәрык клубында – Балалар өчен «Кышкы тылсым» исемле яңа ел квесты. 17.00 – «Безнең шәһәрнең серләре» (Г.Камал). 18.00 – «Рәшә» (Ә.Еники).
8 гыйнвар – «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

30 декабрь – «Яратам! Бетте-китте!» (Л.Әминова).
2 гыйнвар – 12.00 – «Тылсымлы арена» (Ш.Фәрхетдинов). 17.00 – «Кияү урлау» (С.Юзеев әсәре, Х.Ибраһим тәрҗемәсе).
3 гыйнвар – 13.00, 17.00 – «Яратам! Бетте-китте!» (Л.Әминова).
4 гыйнвар – 13.00, 17.00 – «Ай, былбылым» (Ш.Фәрхетдинов).
5 гыйнвар – 13.00, 17.00 – «Кияү урлау» (С.Юзеев әсәре, Х.Ибраһим тәрҗемәсе).
6 гыйнвар – 13.00, 17.00 – «Яратам! Бетте-китте!» (Л.Әминова).
7 гыйнвар – 13.00, 17.00 – «Ай, былбылым» (Ш.Фәрхетдинов).
8 гыйнвар – «Кияүләр» (Х.Вахит).
11 гыйнвар – «Акча бездә бер букча» (З.Хәким).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

29 декабрь, 3 гыйнвар – 10.00, 13.00 – «Көлсылу һәм Яңа ел бәйрәме» (В.Илюхов).
4 гыйнвар – «Камыр батыр» (А.Житковский инсценировкасы).
5 гыйнвар – 13.00 – «Бәхетле көнем» (Е.Гороховская). 18.00 – «Матур City» (А.Әхмәтгалиева).
6 гыйнвар – «Җырлап яшик!» (Р.Латыйпов).
7 гыйнвар – «Мио, минем Мио!» (А.Линдгрен).
8 гыйнвар – 13.00 – «Әлифба: хәрефләр дөньясында» (Л.Әхмәтҗанова, Э.Яруллина, Ф.Насыйбуллин). 18.00 – «Мәхәббәт күгәрченнәре» (В.Гуркин).
10 гыйнвар – «Ак чәчәкләр кебек...» (Р.Мухина).
11 гыйнвар – 11.00 – «Сәлам, Актәпи!» (А.Сальникова). 18.30 – «Ләйлә вә Мәҗнүн» (Н.Ганҗәви, Ю.Тупикина инсценировкасы).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

29-31 декабрь, 2-8 гыйнвар – «Морозко – зимнее шоу» Яңа ел тамашасы.

Кыш бабай, Аяз ата, Дядо Мраз...

Балаларны бүләк белән сөендерүче Кыш бабайга инде ике мең яшь икән. Башта ул бик усал һәм куркыныч итеп сурәтләнгән, тыңлаусыз сабыйларны капчыгына салып китә торган булган... Әкренләп ул мәрхәмәтлегә әйләнгән, бүләк бирә башлаган. Безнең Кыш бабай ак сакаллы мәһабәт карт кыяфәтендә сурәтләнсә, бөтен халыкларда да ул шундый түгел. Мәсәлән, финнарның Яңа ел символы – кәҗә тәкәсе, шуңа күрә аларның Кыш бабае – Йоулупуккиның исеме “Раштуа кәҗәсе” дигәнне аңлата. Аның оныгы да юк, ул хатыны белән Поляр түгәрәк артында мәгарәдә яши. Санта Клаусның Италиядәге кардәше – Баббо Натале, Болгариядәге туганы – Дядо Мраз, Удмуртиядә – Тол бабай, Карелиядә – Паккайне, Казахстанда – Аяз ата, Кытайда – Шэн Дань Лаожэнь, Швециядә – Юлтомтен исемен йөртә...

(“AdMe.ru”).

Яшел чыршы, басып торчы...

Яңа ел чыршысы беренче тапкыр 1600 елда Франциянең Эльзац провинциясендә куелган, ул кәгазь розалар белән бизәлгән булган. 1737 елдан Германия кенәзлекләрендә төрле ялтыравыклы тасмалар куллана башлаганнар. Тагын 38 елдан соң Европада ул чакта сирәк очрый торган бәрәңге бүлбеләрен алтын һәм көмеш йөгертеп бизәү модага кергән. 1815 елдан чыршыны шәмнәр белән бизәүгә күчкәннәр. 1850 елда исә Саксониядә беренче пыяла уенчыклар пәйда булган. 1877 елда Германиядә Йоханнес Эккард агач астына куя торган музыкаль җайланма ясаган – аны ачкыч белән борып кабызгач, чыршы вальс музыкасына әйләнә торган булган. Россиядә Яңа елны чыршы белән каршылау модасын Петр патша керткән, шулай да империянең бөтен җирендә ылыслы гүзәлкәйләрне унтугызынчы гасыр азагында гына куя башлаганнар. Бу традиция революциягә кадәр сакланган. СССР да Яңа елның бу символлары баштарак буржуазия атрибуты саналган һәм тыелган. Әмма 1935 елдан кабат рөхсәт ителгән. 1949 елдан 1 гыйнвар бәйрәм көн дип игълан ителгән.

(“Fishki.net”).

Кем сикерә, кем су сибә

Яңа елны төрле җирдә төрлечә каршылыйлар. Таиландта Яңа ел 13-19 апрельдә каршылана, тик 31 декабрьдә туристлар белән бергә җирле халык та европача ел башын билгеләп үтә – урамдагы бөтен кеше бер-берсенә су сибә һәм битләренә он сылый, шулай кешегә бәхет килә, дип ышана. Япон балалары Яңа ел төнендә мендәр asларына үз хыялларын сурәтләгән рәсемне куеп ята, ул тормышка ашачак, дип өметләнә. Иртән японнар, Кояш белән бергә торып, бер-берсен котлый һәм бүләк бирә. Өйне явыз рухлардан саклау өчен, сәламә көлтәләре элеп куялар. Яңа ел уңышлы булсын өчен, аның беренче секундларында кычкырып көләргә кирәк. Япониядә бәйрәмнең төп бизәге – кечкенә тырма, аның белән үзеңә күпме кирәк, шулкадәр бәхетне тырмалап китереп була дип ышаналар. Индуслар Яңа елны 12 айда 8 тапкыр каршылый. Англиядә сәгать 12 не суга башлагач, йорттагы арткы ишекне ачып, иске елны озаталар, соңгы тапкыр сукканда, алгы ишекне ачып, яңасын кертәләр. Австриядә дуңгыз башы ашыйлар. Германиядә бөтен кеше сәгать 12 не суга башлагач өстәл, урындык, караватка менеп баса да, яңа елга “сикереп төшә”. Италиядә өйдәге бөтен иске җиһаз, кием-салым, савыт-сабаны чыгарып ташлыйлар. Испаниядә сәгать суккан саен бер йөзем ашап, теләк телиләр. Шотландиядә дегетле мичкәгә ут төртеп, урам буйлап тәгәрәтәләр – шул рәвешле иске елны “яндыралар” һәм яңасына юлны яктырталар. Кубада өйдәге бөтен савыт-сабага су тутырып куялар да, сәгать 12 не суккач аларны түгәләр – яңалыкка юл ачалар. Бразилиядә Яңа елны диңгез ярында каршылыйлар.

(“Die Presse”).



Кайсы фараз чынга ашар?

Бөекбританиянең The Economist атналык журналы ел саен Яңа ел алдыннан үзенең тышлыгында шифрланган фараз урнаштыра. 2024 елга фараз сурәтләнгән атналык инде моннан ай ярым элек үк дөнья күрде. Аннан түбәндәгеләрне “укып” була: Зеленский АКШ Президентын сайлауда демократ хатын-кыз (Камала Харрис) җиңүенә һәм сугышның, үзләрен кораллландыруның дәвам итәчәгенә өметләнә, Путин исә республикалы Трамп җиңәр һәм сугыш тәмамланыр, дип исәп тота. Аларның турыдан-туры каршылыгы тәмамланырга вакыт аз калган (моны ком сәгате күрсәтә) һәм Россия, АКШ, Украинадагы президент сайлауларыннан соң хәл ителәчәк, кара белән ак урыннарын алмашачак. Космосны үзләштерү дәвам иттерeләчәк. Нейрочелтәрләр кеше акылына һәм цифрлы контрольгә хуҗа булачак, хәзерге финанс системасы (доллар) юкка чыгачак, криптовалюта киң таралачак. Байден һәм Си Цзиньпин һәркайсы Глобаль Көньякны (Латин Америкасын һәм Тайвань белән бергә Көньяк-Көнчыгыш Азияне) үзенеке итәргә тырышачак. АКШ/Байден яшел энергетика, климат (җилләр), энергия кытлыгы, сирәк очрый металлар һәм Арктика турында уйлап баш вата. Кытай/Си исә электр транспорты, арзанлы энергия, температура җылыну, сирәк очрый металлар, алтын запасларын арттыру хакында уйлана. Түгәрәкләрдәге зәңгәр төсне (АКШ) нәтиҗәдә кызыл төс (Кытай) алыштыра – бу ел азагына таба Кытайның Глобаль Көньякны гына үз ягына авыштырачагына түгел, киләчәктә бөтен дөнья хуҗасына әйләнәчәгенә дә ишарәле кебек. 2024 – Җир шарының язмышы хәл ителәчәк сайлаулар елы (сурәтнең иң үзәгендәге урна моңа ишарә), әмма аларның ничек тәгәлләнәсен әлегә беркем дә фаразларга кыймый.

(“The Economist”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

1 гыйнвар
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
6.35 «КАЗАНГА КАЗАНДА». 16+
7.40 Мультфильмы. 6+
8.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 16+
11.00 «Пар алма». 16+
12.00 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». 16+
15.15 «Өмет йолдызы». Эльмира Кәлимуллина концерты. 16+
16.30 «Сөйләшергә вакыт». 16+
17.30 «ЯҢА ЕЛДА БЕРГӘ БУЛЫЙК!» 16+
19.30 «Болгар радиосы» милли музыкаль премиясен тапшыру тантанасы. 12+
22.30 «НАЗАД - К СЧАСТЬЮ, ИЛИ КТО НАЙДЁТ СИНЮЮ ПТИЦУ?» 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
6.00 «Татарлар». 12+
6.40 «Йөрәктән - йөрәккә». Фердинанд Саләхов турында телеочерк. 16+
7.35 «Яңа елны ТНВ белән бергә каршылыйк!» 6+
8.40 «Гаилә учагы». 16+
9.10 «Яңа елда минем гаиләм». 16+
10.00 «АЛМАШ». 16+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
13.00 «ХӘСИТӘ». 16+
14.35 «Чакыра юлларым». Мурат Гайсинның иҗат кичәсе. 16+
16.15 «Кәмит Җәвит». 16+
17.00 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА». 16+
19.00 «Күңелләрдә тальян моңнары». 12+
19.30 «Болгар радиосы» милли музыкаль премиясен тапшыру тантанасы. 12+
22.50 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
23.40 «СИҢА КАЙТАМ». 16+

«ЭФИР»
5.00 «Человек на своем месте». 16+
5.30 «Волшебное королевство Щелкунчика». 6+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
7.45 «Маша и медведь». 6+
8.30, 9.30 «НОВОГОДНЕЕ СЧАСТЬЕ». 16+
12.25 «Отцы и дети». 16+
13.00 «ЖЕНА РОБИНЗОНА». 16+
14.45 «Точки роста». 16+
14.55 «КТО-ТО ТЕРЯЕТ, КТО-ТО НАХОДИТ». 16+
18.00 «Марк Захаров. Технология чуда». 16+
20.00 «ПОМЕНЯТЬСЯ МЕСТАМИ». 16+
23.00 «ЖЕНСКОЕ ДЕЛО». 18+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Новогодний календарь».
6.50 «МАРЬЯ-ИСКУСНИЦА».
8.05 «Карнавальная ночь».
9.20, 10.15 «МОСКВА СЛЕЗАМ НЕ ВЕРИТ». 12+
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
12.15 «МОРОЗКО».
13.35 «Наш Новый год». Большой праздничный концерт. 12+
14.00 Новогодний «Мечталлион». 12+
15.00 «Наш Новый год». 12+
16.30 «ИВАН ВАСИЛЬЕВИЧ МЕНЯЕТ ПРОФЕССИЮ».
18.30 «Большая разница 2024». 16+
20.00 «ВЫЗОВ». 12+
22.35 «НОВОГОДНЕЕ ПРИКЛЮЧЕНИЕ». 16+

«РОССИЯ»
4.20 «ИРОНИЯ СУДЬБЫ, ИЛИ С ЛЁГКИМ ПАРОМ!» 12+
7.40 «ДЕВЧАТА».
9.20 «ДЖЕНТЛЬМЕНЫ УДАЧИ». 6+
10.50 «БРИЛЛИАНТОВАЯ РУКА».
12.35 «ОДЕССКИЙ ПАРОХОД». 12+
14.00, 20.00 Вести.
14.25 «Песня года».
16.25 «ПОСЛЕДНИЙ БОГАТЫРЬ. ПОСЛАННИК ТЬМЫ». 6+
18.10 «КОНЁК-ГОРБУНОК». 6+
20.24 «ЧЕБУРАШКА». 6+
22.10 «ХОЛОП». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Ну, погоди!»
8.15 «Снежная королева». Оживи, милый!»
8.55 «СНЕЖНАЯ КОРОЛЕВА».
10.20 «Сюжеты зимней Тарусы».
11.00 «ЧУК И ГЕК».
11.50 Исторические курорты России. «Сочи. Русская Ривьера».
12.20 «Брачные игры».
13.15 Гала-концерт телевизионного конкурса «Щелкунчик».
15.20 «Рецепты счастья».
16.25 «Здравствуйте, я ваша тетя!» Как сюда попала эта леди?»
17.05 «ЗДРАВСТВУЙТЕ, Я ВАША ТЕТЯ!»
18.45 «Песня не прощается... 1976-1977».
20.05 «ГРАФ МОНТЕ-КРИСТО».
23.10 Клуб «Шаболовка, 37».

«НТВ»
5.00 «Следствие вели...» 16+
6.20 «ПАПЫ». 6+
8.00, 9.00 «ЛИХАЧ». 16+
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
15.30 «Новогодний миллиард».
17.00 «КИНО ПРО БАНДИТОВ». 16+
20.20 «Шоу Аватар». 12+
23.15 «ГАРАЖНЫЙ ПАПА». 12+

Сишәмбе

2 гыйнвар
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
6.00, 0.30 «ТРИ МУШКЕТЁРА». 12+
8.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 16+
11.00 «Күңелләрдә тальян моңнары». 12+
11.30 «Татарлар». 12+
12.00 «Ялт-йолт». «Мунча ташы»ның сатирик күңел ачу тапшыруы. 16+
15.40 Концерт Мурада Гайсина . 16+
17.05 «Әйдә, шаяРТ!» 16+
19.00 Концерт «Тылсымлы бәйрәм мизгелләре». 12+
19.30 «ХӘСИТӘ». 16+
21.00 «Яңа Гасыр»да Яңа ел төне». 12+
23.00 «С НОВЫМ ГОДОМ, МАМЫ!» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
6.00, 19.30 «Татарлар». 12+
6.30 «Йөрәктән - йөрәккә». Әсхәт Хисмәт турында телеочерк. 16+
7.25 «Яңа елны ТНВ белән бергә каршылыйк!» 6+
8.40 «Гаилә учагы». 16+
9.10 «Яңа елда минем гаиләм». 16+
10.00 «АЛМАШ». 16+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
13.00 Спектакль «Ханума». 16+
16.00 «Кәмит Җәвит». 16+
17.00 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА». 16+
19.00 «Күңелләрдә тальян моңнары». 12+
20.00 «Безнең заман - Наше время» Республика телевизион фестиваленең гала-концерты. 16+
22.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
22.50 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК». 16+

«ЭФИР»
5.00 «Человек на своем месте». 16+
5.30 «Смешарики. Легенда о золотом драконе». 6+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
7.45 «Маша и медведь». 6+
8.30 «Точки роста». 16+
8.40, 9.30 «СИЛА ЛЮБВИ». 16+
12.25 «Отцы и дети». 16+
13.00 «МОЯ МАМА СНЕГУРОЧКА». 16+
14.25 «НОВОГОДНЕЕ СЧАСТЬЕ». 16+
18.00 «Золотой теленок. С таким счастьем - и на экране». 16+
20.00 «УЧИТЕЛЯ». 16+
23.00 «ЖЕНСКОЕ ДЕЛО». 18+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
6.10, 0.25 Подкаст.лаб. 16+
6.30 «МОРОЗКО».
8.00 «Доброе утро».
10.15 «Модный приговор».
11.10 «Играем свадьбу!» 12+
12.15 «Поехали!» 12+
13.10 «Видели видео?»
14.20 «Давай поженимся в Новый год!» 16+
15.15 «Угадай мелодию». 12+
16.05 «КАЗАНОВА». 16+
18.20 «Я люблю мою страну».
19.25 «Сегодня вечером». 16+
21.00 «Время».
21.35 «ДОКТОР ПРЕОБРАЖЕНСКИЙ». 16+
23.25 «ДИАНА ДЕ ПУАТЬЕ». 16+

«РОССИЯ»
5.10 «ДНЕВНИК СВЕКРОВИ». 12+
6.45 «МЕЖДУ НАМИ ГЛУБОКОЕ МОРЕ». 12+
8.40 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
9.20 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.55 «КОНЁК-ГОРБУНОК». 6+
14.40, 21.05 Вести. Местное время.
14.55 «Песня года».
17.50 «ЧЕБУРАШКА». 6+
21.20 «ТАЙНА ЛИЛИТ». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Ну, погоди!»
7.25 «ВЕСЕЛЫЕ РЕБЯТА».
9.00 «Тайная жизнь сказочных человечков».
9.30 «СТАРОМОДНАЯ КОМЕДИЯ».
11.00 «Паломница».
11.50 Исторические курорты России. «Сергиевские воды».
12.20 «Брачные игры».
13.15 Большие и маленькие.
14.00 «ГРАФ МОНТЕ-КРИСТО».
15.30 Легендарные спектакли Большого. Екатерина Максимова, Владимир Васильев, Светлана Адырхаева в балете С. Прокофьева «Каменный цветок».
17.25 «ДЕТИ ДОН КИХОТА».
18.45 «М.И.Ф.».
19.25 «ЧЕРНЫЙ ТЮЛЬПАН».
21.15 Гала-концерт «Музыкальная вселенная Исаака Шварца».
23.15 «ЛЮДИ И МАНЕКЕНЫ».

«НТВ»
5.15 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.20 «АЛМАЗ В ШОКОЛАДЕ». 12+
10.20 «Детская Новая волна».
12.15, 16.20 «БАЛАБОЛ». 16+
19.30 «БИМ». 16+
22.40 «Главный новогодний концерт». 12+

Чәршәмбе

3 гыйнвар
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
6.00, 0.35 «ТРИ МУШКЕТЁРА». 12+
8.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
11.00 «Күңелләрдә тальян моңнары». 12+
11.30 «Татарлар». 12+
12.00 «Синең өчен сөюләрем». Алсу һәм Азат Фазлыевлар концерты. 16+
14.00 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА». 16+
16.05 «Шаян»да Үзгәреш җиле».
17.50 «Соотечественники». 12+
18.20 «КАЗАНГА КАЗАНДА». 16+
19.30 «Яңа Гасыр»да Яңа ел!» Бәйрәм концерты. 16+
22.50 «МАМЫ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.10 «Бөркет канатында хөрлек бар». Адлер Тимергалин турында телеочерк. 16+
6.00, 19.30 «Татарлар». 12+
6.30 «Йөрәктән-йөрәккә». Зөлфәт турында телеочерк. 16+
7.25 «Яңа елны ТНВ белән бергә каршылыйк!» 6+
8.30 «Гаилә учагы». 16+
9.05 «Яңа елда минем гаиләм». 16+
10.00 «АЛМАШ». 16+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
13.00 Спектакль «Йөрәк маем». 16+
16.00 «Кәмит Җәвит». 16+
17.00 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА». 16+
19.00 «Күңелләрдә тальян моңнары». 12+
20.00 «Бүләк булып калсын җырларым». Ринат Мөслимов. 16+
22.30 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
23.15 «КУНАК АШЫ - КАРА КАРШЫ, ЯКИ КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК 2». 16+

«ЭФИР»
5.00, 8.30 «Человек на своем месте». 16+
5.30 «Смешарики. Дежавю». 6+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
7.45 «Маша и медведь». 6+
8.55, 9.45 «КТО-ТО ТЕРЯЕТ, КТО-ТО НАХОДИТ». 16+
12.25 «Отцы и дети». 16+
13.00 «ВЬЮГА». 16+
14.35 «Точки роста». 16+
14.45 «СИЛА ЛЮБВИ». 16+
18.00 «Дело Деточкина». 16+
20.00 «УЧИТЕЛЯ». 16+
23.00 «ЖЕНСКОЕ ДЕЛО». 18+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
6.10, 0.25 Подкаст.лаб. 16+
6.30 «ОГОНЬ, ВОДА И... МЕДНЫЕ ТРУБЫ».
8.00 «Доброе утро».
10.15 «Модный приговор».
11.10 «Играем свадьбу!» 12+
12.15 «Поехали!» 12+
13.10 «Видели видео?»
14.20 «Давай поженимся в Новый год!» 16+
15.15 «Угадай мелодию». 12+
16.05 «КАЗАНОВА». 16+
18.20 «Я люблю мою страну».
19.25 «Сегодня вечером». 16+
21.00 «Время».
21.35 «ДОКТОР ПРЕОБРАЖЕНСКИЙ». 16+
23.25 «ДИАНА ДЕ ПУАТЬЕ». 16+

«РОССИЯ»
5.10 «ДНЕВНИК СВЕКРОВИ». 12+
6.45 «МЕЖДУ НАМИ ГЛУБОКОЕ МОРЕ». 12+
8.40 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
9.20 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.55 «ПАЛЬМА». 6+
14.40, 21.05 Вести. Местное время.
14.55 «Олег Газманов. 55 лет на сцене».
17.50 «Песни от всей души». 12+
21.20 «ТАЙНА ЛИЛИТ». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 Мультфильмы.
7.30 «ЗДРАВСТВУЙТЕ, Я ВАША ТЕТЯ!»
9.10 «Тайная жизнь сказочных человечков».
9.40, 23.15 «ЛЮДИ И МАНЕКЕНЫ».
11.00 «Паломница».
11.55 «Приют путешественника».
12.20 «Брачные игры».
13.15 Большие и маленькие.
14.10 «ГРАФ МОНТЕ-КРИСТО».
15.40 Аида Гарифуллина, Ирина Шишкова, Сон Чи Хун в гала-концерте фестиваля искусств «Хворостовский».
17.15 «ФОРМУЛА ЛЮБВИ».
18.45 «М.И.Ф.».
19.30 Новости культуры.
19.45 «ПАРИЖСКИЕ ТАЙНЫ».
21.30 Юбилейный творческий вечер «Александр Домогаров - 60».

«НТВ»
5.15 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.20 «ГАРАЖНЫЙ ПАПА». 12+
10.20 «Домисолька. Время чудес».
12.15, 16.20 «БАЛАБОЛ». 16+
19.30 «БИМ». 16+
22.40 «Вне времени. Вне пространства. 50 лет на сцене». Юбилейный концерт Ларисы Долиной. 12+

Пәнҗешәмбе

4 гыйнвар
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
6.00, 0.40 «ТРИ МУШКЕТЁРА». 12+
8.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 16+
11.00 «Күңелләрдә тальян моңнары». 12+
11.30 «Татарлар». 12+
12.00 «Нечкәбил-2023». Финал Республиканского конкурса красоты, материнства и семьи. 12+
14.00 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА». 16+
16.05 «Соотечественники». 16+
16.30 «Яшик әле!» Разил Вәлиевнең иҗат кичәсе. 12+
19.30 «МЕНӘ УЛ, БӘХЕТ!» 12+
21.00 «Яңа елны ТНВ белән бергә каршылыйк!» 12+
23.00 «10 ДНЕЙ С САНТОЙ». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
6.00, 19.30, 0.05 «Татарлар». 12+
6.30 «Йөрәктән - йөрәккә». Җәүдәт Фәйзи турында телеочерк. 16+
7.20, 19.50 «Яңа Гасырда Яңа ел». 6+
8.40 «Гаилә учагы». 16+
9.10 «Яңа елда минем гаиләм». 16+
10.00 «АЛМАШ». 16+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
13.00 «Яшик әле!» Разил Вәлиевнең юбилей кичәсе. 16+
16.05 «Кәмит Җәвит». 16+
17.00 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА». 16+
19.00 «Күңелләрдә тальян моңнары». 12+
23.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 9.30, 11.30 «СОН КАК ЖИЗНЬ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
12.30, 18.30 «Подружки». 16+
13.00 «ПРИЛЕТИТ ВДРУГ ВОЛШЕБНИК». 16+
14.35 «Человек на своем месте». 16+
15.00 «Отцы и дети». 16+
15.30 «Золотой теленок. С таким счастьем - и на экране». 16+
16.30 «МОЙ ЛЮБИМЫЙ ПАПА». 16+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
20.00 «УЧИТЕЛЯ». 16+
23.00 «ЖЕНСКОЕ ДЕЛО». 18+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
6.10, 0.25 Подкаст.лаб. 16+
6.40 «ЗОЛОТЫЕ РОГА».
8.00 «Доброе утро».
10.15 «Модный приговор».
11.10 «Играем свадьбу!» 12+

12.15 «Поехали!» 12+
13.10 «Видели видео?»
14.20 «Давай поженимся в Новый год!» 16+
15.15 «Угадай мелодию». 12+
16.05 «КАЗАНОВА». 16+
18.20 «Я люблю мою страну».
19.25 «Сегодня вечером». 16+
21.00 «Время».
21.35 «ДОКТОР ПРЕОБРАЖЕНСКИЙ». 16+
23.25 «ДИАНА ДЕ ПУАТЬЕ». 16+

«РОССИЯ»
5.10 «ДНЕВНИК СВЕКРОВИ». 12+
6.45 «МЕЖДУ НАМИ ГЛУБОКОЕ МОРЕ». 12+
8.40 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
9.20 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 14.00, 17.15, 20.00 Вести.
11.35 «ХИТРОВКА. ЗНАК ЧЕТЫРЁХ». 12+
14.40, 21.05 Вести. Местное время.
14.55 Большой юбилейный концерт Николая Баскова.
17.50 «Песни от всей души». 12+
21.20 «ТАЙНА ЛИЛИТ». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 Мультфильмы.
7.55 «ДЕТИ ДОН КИХОТА».
9.10 «Тайная жизнь сказочных человечков».
9.40, 23.40 «ЛЮДИ И МАНЕКЕНЫ».
11.00 «Паломница».
11.55 «Приют путешественника».
12.20 «Брачные игры».
13.15 Большие и маленькие. Лучшее.
14.10 «ЧЕРНЫЙ ТЮЛЬПАН».
16.05 «Романтика романса».
17.20 «СЕМЬ СТАРИКОВ И ОДНА ДЕВУШКА».
18.45 «М.И.Ф.».
19.30 Новости культуры.
19.45 «БЛЕФ».
21.30 Гала-концерт в честь юбилея Тамары Синявской.

«НТВ»
5.15 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.20 «ЗИМНИЙ КРУИЗ». 16+
10.20 «Добрая волна».
12.15, 16.20 «БАЛАБОЛ». 16+
19.30 «БИМ». 16+
22.40 «Я не боюсь». Шоу Сергея Лазарева. 16+

Җомга

5 гыйнвар
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.25, 16.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
6.00, 0.40 «ТРИ МУШКЕТЁРА». 12+
8.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 16+
11.00 «Күңелләрдә тальян моңнары». 16+
11.30 «Татарлар». 12+
12.00 «Восточный базар-2023». Гала-концерт. 12+
14.00 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА». 16+
16.45 Хоккей. «Ак Барс» - «Адмирал». 6+
19.30 «СӨЮЛӘРЕМ СИНЕ ХАК МИНЕМ». 16+
21.30 «Яңа татар җыры-3» конкурсының гала-концерты. 16+
23.20 «КОРОТКИЕ ВОЛНЫ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.50 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
6.00, 19.30, 2.00 «Татарлар». 12+
6.30 «Йөрәктән - йөрәккә». Булат Гыйльванов турында телеочерк. 16+
7.20 «КАЗАНГА КАЗАНДА». 16+
8.40 «Гаилә учагы». 16+
9.10 «Яңа елда минем гаиләм». 16+
10.00 «АЛМАШ». 16+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
13.00 «КАЙТ ӘЙДӘ, КЫШ БАБАЙ!» 6+
14.30 «Кайда сез, яшьлек елларым». Зөһрә Шәрифуллина концерты. 16+
16.00 «Кәмит Җәвит». 16+
17.00 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА». 16+
20.00 «Шәрык базары 2023». 12+
22.20 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
23.30 «ЫШАНАСЫ КИЛӘ». 16+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 9.30, 11.30 «СЛЕПОЙ РАСЧЕТ». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ЛЮБОВЬ И ДРУГИЕ ИЛЛЮЗИИ». 16+
14.45 «Точки роста». 16+
15.00 «Отцы и дети». 16+
15.30 «Дело Деточкина». 16+
16.30 «МОЙ ЛЮБИМЫЙ ПАПА». 16+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.20 «Fam TV». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
20.00 «УЧИТЕЛЯ». 16+
23.00 «ЖЕНСКОЕ ДЕЛО». 18+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
6.10 «ФРАНЦУЗ». 12+
8.00 «Доброе утро».
10.15 «Модный приговор».
11.10 «Играем свадьбу!» 12+
12.15 «Поехали!» 12+
13.10 «Видели видео?»
14.20 «Давай поженимся в Новый год!» 16+
15.15 «Угадай мелодию». 12+
16.05 «КАЗАНОВА». 16+
18.25 «Я люблю мою страну».
19.40 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.35 «ДОКТОР ПРЕОБРАЖЕНСКИЙ». 16+
23.25 «ДИАНА ДЕ ПУАТЬЕ». 16+

«РОССИЯ»
5.10 «ДНЕВНИК СВЕКРОВИ». 12+
6.45 «МЕЖДУ НАМИ ГЛУБОКОЕ МОРЕ». 12+
8.40 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
9.20 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.45 «Измайловский парк». 16+
14.45, 21.05 Вести. Местное время.
15.00 «Классная тема!»
17.50 «Песни от всей души». 12+
21.20 «ТАЙНА ЛИЛИТ». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 Мультфильмы.
7.50 «СЕМЬ СТАРИКОВ И ОДНА ДЕВУШКА».
9.10 «Тайная жизнь сказочных человечков».
9.40, 23.20 «ЛЮДИ И МАНЕКЕНЫ».
11.00 «Паломница».
11.55 «Приют путешественника».
12.20 «Брачные игры».
13.15 Большие и маленькие.
14.10 «ПАРИЖСКИЕ ТАЙНЫ».
16.10 «Песня не прощается... 1978».
17.15 «СТАРИКИ-РАЗБОЙНИКИ».
18.45 «М.И.Ф.».
19.30 Новости культуры.
19.45 «Пиковая дама».
22.35 «Твербуль, или Пушкинская верста».

«НТВ»
5.10 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.20 «НОЛЬ». 16+
10.20 «Белая трость». Международный благотворительный фестиваль. 12+
12.15, 16.20 «БАЛАБОЛ». 16+
19.30 «БИМ». 16+
22.40 «Ани Лорак. Концерт в день рождения».

Шимбә

6 гыйнвар
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
6.00 «ТРИ МУШКЕТЁРА». 12+
7.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 16+
9.00 «Гаилә учагы». 16+
9.30 «Видеоспорт». 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00 «Музыкальный майдан». 16+
11.30 «Бүләк булып калсын җырлары. Ринат Мөслимов». 16+
15.00 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА». 16+
17.00 «Сөйләшергә вакыт». 16+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 16+
20.00 «Тылсымлы бәйрәм мизгелләре». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
22.00 «МОДЕЛЬ СЧАСТЛИВОЙ ЖИЗНИ». 16+
23.50 Рождество Христово.

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
6.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Мирсәй Әмир турында телеочерк. 16+
7.00, 15.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 16+
9.00 «Сөйләшергә вакыт». 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00 «Мәңгелек... Ирек... Хисләр...» Ирек Баһманов турында телеочерк. 16+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
13.00 «МЕНӘ УЛ, БӘХЕТ!» 16+
17.00 Спектакль «Ялт-йолт». 16+
20.15 «Фәрештә түгел». Илсөя Бәдретдинова концерты. 16+
22.30 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
23.20 «МӘХӘББӘТ ХАКЫНА». 16+

«ЭФИР»
5.00 «Человек на своем месте». 16+
5.30 «Снежная королева. Огонь и лед». 6+
7.00 «Маша и медведь». 6+
7.30 «Фиксики. Новенькие». 6+
8.00 «Спасите, я не умею готовить!» 16+
8.50 «ФРОДЯ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «Детский шеф». 12+
14.00 «ПРИКЛЮЧЕНИЯ ЭКСПОНАТА». 16+
15.40 «Точки роста». 16+
15.50 «ДАША». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «НЕОБЫКНОВЕННАЯ ИСТОРИЯ НА РОЖДЕСТВО». 16+
22.45 «Концерт «Русское Рождество».
23.55 «РОВЕСНИКИ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
6.10 Подкаст.лаб. 16+
6.35 «БЕДНАЯ САША». 12+
8.30 «Моя любовь». 12+
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.15 «Модный приговор».
11.10 «Играем свадьбу!» 12+
12.15 «ФИНИСТ-ЯСНЫЙ СОКОЛ».
13.45 «ТАЙНА».
15.20 «Иисус. Земной путь».
16.15 «Рождество в России. Традиции праздника».
17.10 «Угадай мелодию». 12+
18.20 «Эксклюзив». 16+
19.15 Юбилейное шоу Ильи Авербуха.
21.00 «Время».
21.35 «Сегодня вечером». 16+
23.00 Рождество Христово.

«РОССИЯ»
6.05 «ПАЛЬМА». 6+
8.15, 11.30 «ГАРДЕМАРИНЫ, ВПЕРЁД!»
11.00, 20.00 Вести.
14.05 «ГАРДЕМАРИНЫ 1787. МИР». 12+
16.05 «ГАРДЕМАРИНЫ 1787. ВОЙНА». 12+
17.50 «Гардемарины-2024». 12+
20.45 Вести. Местное время.
21.00 «НЕПОСЛУШНИК 2. ВСПОМНИТЬ ВСЁ!» 12+
23.00 Рождество Христово.

«КУЛЬТУРА»
6.30 Мультфильмы.
7.40 «СТАРИКИ-РАЗБОЙНИКИ».
9.10 Тайны старого чердака. «Древний Египет. Перезагрузка».
9.40 «ЛЮДИ И МАНЕКЕНЫ».
11.00 «Паломница».
11.55 «Приют путешественника».
12.20 «Правила птичьего леса».
13.05 «Вся Россия». Фестиваль фольклорного искусства.
13.45 «СЕРДЦЕ НЕ КАМЕНЬ».
16.00 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
17.20 «Сладкая жизнь».
18.05 Юбилейный концерт Школы-студии при Ансамбле имени Игоря Моисеева.
19.30 Новости культуры.
19.45 «Театр на линии фронта. «Донбасс Опера».
20.40 «ЕЩЕ РАЗ ПРО ЛЮБОВЬ».
22.15 «Поездка для души. Кто упрям - тому на Валаам».
22.55 «СВЕРСТНИЦЫ».

«НТВ»
5.15 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.20 «ВЕТЕР СЕВЕРНЫЙ». 16+
10.20 «Снегурочка». Шоу Евгения Плющенко.
12.15, 16.20 «БАЛАБОЛ». 16+
19.30 «БИМ». 16+
22.40 «Хиты 80-90х. Дискотека». 12+

Якшәмбе

7 гыйнвар
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
6.00, 0.40 «ТРИ МУШКЕТЁРА». 12+
7.00 «ГОСПОЖА МЕТЕЛИЦА».
8.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 16+
10.30 «Движение к мечте - Хыялга омтылыш». Республиканская новогодняя елка.
11.30 «Кызган казан». 16+
12.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
13.00 «Ком сәгате». 16+
14.00 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА». 16+
16.45 Хоккей. «Ак Барс» - «Автомобилист». 6+
19.30 «Видеоспорт». 16+
20.00 «Эльмир Низамов һәм дуслар». 16+
22.00 «ЛЕКАРЬ. УЧЕНИК АВИЦЕННЫ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». Гомәр Бәширов турында телеочерк. 16+
7.00 «Яңа елны ТНВ белән бергә каршылыйк!» 6+
10.00 «УКСЕЗЛӘР». 16+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
13.05 «Хыялга омтылыш». Республика Яңа ел чыршысы. 6+
14.05 «Шаян»да үзгәреш җиле». 6+
16.00 «Кәмит Җәвит». 16+
17.00 Р.Ваһапов исемендәге халыкара татар җыры фестиваленең гала-концерты. 16+
19.00 «Ком сәгате». 16+
19.50 Спектакль «Дон Жуан». 16+
22.20 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
23.10 Спектакль «Шулай булды шул». 16+

«ЭФИР»
5.00 «Человек на своем месте». 16+
5.30, 14.45 «Точки роста». 16+
5.40 «Фиксики. Большой секрет». 6+
7.00 «Маша и медведь». 6+
7.30 «Фиксики. Новенькие». 6+
8.00 «ДАША». 16+
11.10, 18.10 «Детский шеф». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ТАЛИСМАН». 16+
15.00 «ФРОДЯ». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «РОЖДЕСТВЕНСКИЕ КАНИКУЛЫ». 16+
22.40 «ПРИКЛЮЧЕНИЯ ЭКСПОНАТА». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
6.10 Подкаст.лаб. 16+
6.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Мечталлион». 12+
9.40 «Непутевые заметки». 12+
10.15 «Играем свадьбу!» 12+
11.10, 12.15 «ЗОЛУШКА».
13.05 «СТАРИК ХОТТАБЫЧ».
14.40 «ЁЛКИ-ИГОЛКИ». 12+
16.40, 18.20 «Рождество с Григорием Лепсом». 12+
19.10 «Лучше всех!»
21.00 «Время».
21.35 «БАБА МОРОЗ И ТАЙНА НОВОГО ГОДА». 12+
23.30 Концерт «Навсегда». 12+

«РОССИЯ»
4.45 «РАЗВОДА НЕ БУДЕТ». 12+
6.20 «МЕЖДУ НАМИ НЕБО». 12+
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 20.00 Вести.
11.55 Рождественское интервью Святейшего Патриарха Кирилла.
12.20 «РУССКИЙ КРЕСТ». 12+
13.30 «Отец Иоанн». 12+
14.25 «НЕПОСЛУШНИК». 12+
16.35 «НЕПОСЛУШНИК 2. ВСПОМНИТЬ ВСЁ!» 12+
18.40 «Нежность твоя».
20.45 Вести. Местное время.
21.00 «ВАША ТЁТЯ ЛЮСИ». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 Мультфильмы.
7.15 «СЕЛЬСКИЙ ВРАЧ».
9.05 Тайны старого чердака. «Искусство Древней Греции».
9.35, 12.20, 15.35 «Рождественская звезда».
9.40, 23.30 «СВАДЬБА С ПРИДАНЫМ».
11.40 «Поездка для души. Кто упрям - тому на Валаам».
12.30 «Степная песня жаворонка».
13.10 Юбилейный концерт Государственного академического Воронежского русского народного хора им. К.И. Массалитинова.
14.15 «СВЕРСТНИЦЫ».
15.45 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
16.45 «Отцы и дети».
17.10 «Пешком...»
17.40 «Красота по-русски».
18.35 «Романтика романса».
19.30 Новости культуры.
19.45 «Как я стал ребёнком».
20.40 Концерт «Андрей Дементьев. Всё начинается с любви».

«НТВ»
5.15 «Таинственная Россия». 16+
6.00 «НАСТОЯТЕЛЬ». 16+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Рождественская песенка года».
12.15, 16.20 «БАЛАБОЛ». 16+
19.30 «БИМ». 16+
22.40 Юбилейный концерт Валерии. 12+

Декабрь аенда Аксубай районының Түбән Майна урта мәктәбе оештырган, шактый гына фән-мәгариф әһелләрен җәлеп иткән «Татар халкының мәдәни мирасын өйрәнү, саклау һәм яшь буынга җиткерү мәсьәләләре» дип аталучы республикакүләм фәнни-гамәли конференция максатына иреште. Мәктәп бусагасын атлап керүгә үк күренде бу. Конференция программасында илледән артык чыгыш каралган. Иң отышлысы: нотык текстлары, алдан ук җыелып, 210 битле китап рәвешендә, катнашучылар кулына тапшырылды. Түбән Майна мәктәбе дип әйткәндә, әлбәттә, беренче чиратта мәктәп директоры, тарих фәннәре кандидаты Рәфыйк Насыйровны күздә тотабыз.

Мәдәни мирас мәктәптән башлана

Шушы мәртәбәле җыелышта катнашкан күренекле археолог, «Болгар» музей-саклаулыгының өлкән фәнни хезмәткәре Җәмил Мөхәммәтшин белән, туган төбәгенең җанатары һәм һөнәри тарихчысы да булган шушындый шәхесләр тагын кайда бар икән, дип баш ваттык. Балык Бистәсе районының Яңа Сала авылы фидакаре, үзе язган һәм аның мөхәррирлегендә бастырылган, тарихыбызны өйрәнүгә кагылышлы алтмышлап китапка бәйле Нурулла Гарифтан башка белгечне таба алмадык. Туган төбәгенең тарихын язу һәм язучыларга булышудан тыш, Нурулланың тагын бер олы хезмәте – шәһәр җирлегеннән күченеп кайтып, туган авылында нигезен яңартуы, Шәрәфетдин бабасы нигезендә «Борынгы Чаллы төбәге тарихына караган шәхси музей-комплексы» төзүе. Гыйльми җыелышта ясаган чыгышында ул менә шушы музей-комплексның тарихи һәм милли үзаңыбызны саклаудагы әһәмияте турында сөйләде. Аны барып күргән кешеләр, их, шушындый музейларны бөтен авылларда, һичьюгы Татарстанның һәр районында берне булдырасы иде, дип кайта.

Биләр варислары

Конференция башланганчы да, фәнни-гамәли җыелыш барышында өлкән һәм кечкенә түбәнмайналылардан «Без – Биләр варислары» дигән гыйбарәне еш ишетергә туры килде. Гаҗәп тә түгел: бу якта гомер сөрүче милләттәшләребез бүген дә үзләрен озак еллар буе Идел буе Болгар дәүләтенең башкаласы булган Биләрне коручы һәм аның шанлы исемен югары тотучы бабаларыбызның дәвамчылары дип саный. Әйе, Болгар дәүләте халкы – болгары, суары, бортасы, чуашы, марие, удмурты беркая да китмәгән; ушкуйниклар, монголлар, калмыклар зыян салып торуга карамастан, үз йөзен – гореф-гадәтләрен, телен, динен саклап, шушы туфракта яшәп калган. Билгеле, борынгыдан килгән мәдәни мирасыбызны саклауның һәм яшь буынга тапшыруның төрле юллары булырга мөмкин. Шуның бер юлын Р. Насыйров пленар утырышта тәкъдим итте.

– Биләр ягы заманында тарихи үзәк булган, бүген дә шул традицияләр – дәүләтчелек хисе, әби-бабаларыбызның яшәү рәвешенә тугрылык тойгысы дәвам иттерелергә тиеш. Без Казандагы «Ярдәм» мәчет-комплексы белән берлектә авылыбызда кыз балалар өчен пансионат тибындагы милли мәгариф үзәге булдырырга ниятлибез. Авылда тел мохите бар, милли һәм тарихи аң тәрбияләрлек белгечләребез җитәрлек. Дәүләт органнары, хәйрия оешмалары да булышса, бу кулдан килмәслек эш түгел, – дип сөйләде ул. Буш хыял түгел бу. Әнә баш казыебыз Җәлил хәзрәт Фазлыев һәм ярдәмлеләр тырышлыгы белән Балтач районының Бөрбаш авылында ир балалар пансионаты эшләп китте. Нигә әле түбәнмайналыларның нияте тормышка ашмасын, ди?!

«Чума үрдәк, чума каз»

Секция утырышлары барышында бик күп кызыклы фикерләр, тәкъдимнәр яңгырады. Галимнәр, мәктәп укытучылары, балалар бакчалары тәрбиячеләре – һәммәсенең әйтер сүзе бар. Алдынгы тәҗрибә итеп сөйләрлек мисаллар күп булса да, бүген биредә нәкъ менә Аксубай җирлегендә булган кызыклы гамәлләр генә телгә алынды.

Бакча яшендәге балаларда ничек итеп милли үзаң тәрбияләргә? Район үзәгендәге төрле милләт балалары тәрбияләнә торган «Буратино» балалар бакчасында халкыбызның рухи байлыгын сабыйларга җиткерү, әби-бабаларыбызның үткәненә кызыксыну уяту максатында, кечкенә генә музей оештырганнар. Анда халкыбызның көнкүреш әйберләреннән бишек, самавыр, кулдан сугылган, чигелгән сөлгеләр, көнкүрештә кулланылган савыт-сабалар, эш кораллары тупланган.

– Бәләкәчләрдә милли үзаң булдыру максатыннан, бишек җырлары, әкиятләр, табышмак-сынамышлар, мәкаль-әйтемнәр өйрәнәбез. «Чума үрдәк, чума каз», «Түбәтәй», «Йөзек салыш», «Самавыр», «Без, без, без идек» кебек җырлы-сүзле уеннарны сабыйлар яратып уйный. Балалар белән әкиятләр сәхнәләштерәбез. Алар спектакльләрдә бик теләп катнаша, – дип сөйләде тәрбияче Галия Минсафина.

Түбән Майна урта мәктәбендә «Мәктәп хәбәрчесе» газетасы чыгару тәҗрибәсе дә күпләрдә кызыксыну уятты. Аның электрон варианты да бар. Телләгән кеше шушы минутта ук http://edu.tatar.ru/aksubaevo/n-tat-maina/sch сылтамасына кереп газетаның эчтәлеге белән таныша ала.

– Мәктәп тормышын чагылдырудан тыш, аның һәр санында «Чал тарихта эзле без» дигән рубрика астында туган ягыбызның тарихын өйрәнүгә багышланган язма урнаштырыла. Быелның октябрендә «Мәктәп хәбәрчесе»нә 5 яшь тулды. Шушы дәвер эчендә газетаның 49 саны дөнья күрде. 2019 елдан алып баш мөхәррир вазыйфасын татар теле һәм әдәбияты укытучысы Фәнүзә Гафятуллина башкара, – дип сөйләде әлеге вакытлы матбугатның эшчәнлеге турында тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Гөлия Мифтахова. Газетаның кәгазь версиясе, мәктәпнең мини-типографиясендә бастырылып, әти-әниләргә, укучыларга, мәктәп хезмәткәрләренә, гомумән, кызыксынган барлык кешегә таратылуы да мөһим. Мәгълүм ки: бик күп каләм әһелләребез мәктәп эчендә дөнья күргән менә шушындый газеталарда чирканчык алган.

Һөнәрле кулда бәрәкәт бар

Әлеге мәктәпнең башлангыч сыйныфлар укытучысы Рузилә Хәйруллинаның чыгышы бер әти-әнине дә битараф калдырмады. Чөнки балаларны һөнәрле итү – заманыбызның иң җитди мәсьәләләреннән берсе. Укучы мәктәптән белем-тәрбия генә түгел, кәсеп-һөнәрчелек нигезләрен дә алып чыгарга тиеш, дип тәкрарлаучылар күп тә бит, тиешне гамәлгә ашыручылар гына аз.

– Сәдәф тагарга, сүтелгәнне тегәргә өйрәтә башласаң да, моның безгә кирәге бармы, дип сораучылар табыла... Тегү-чигү барышында балаларга бик нык тырышырга – энә тоту һәм саплаудан алып, тигез итеп кисәргә, җепне төйнәргә, туры итеп тегәргә, чигү төрләрен өйрәнергә туры килде, – дип бер караганда күптәннән билгеле һәм бик тә гади тоелган гореф-гадәтләребезне искәртте Рузилә ханым. – Без балаларның игътибарлы, яхшы хәтерле, сөйләм телләре чиста, аралашучан булуын телибез. Бу сыйфатларның үсешенә кул хезмәтләре нык ярдәм итә. Бәйләү барышында кан әйләнеше яхшыра, кул һәм күз хәрәкәтләре бергәлеге (сенсорика) үсеш ала. Кул эшләре бармакларның моторикасын үстерә, сабырлыкка һәм үзсүзлелеккә өйрәтә. Эшкә осталыгын күрү балада уңай кәеф һәм үз-үзенә ышаныч тудыра.

Әлеге уку йортындагы малайлар, кызлар милли бизәкләр төшерелгән савыт-сабалар, куна-такталар, шамаилләр ясый икән. Төсле фольгалар кулланып һәм милли бизәкләр төшереп, шамаилне пыялага ясау ысулын мастер-класслар барышында без дә күреп сокландык.

Иң мөһиме: баланы эш яратырга өйрәтергә кирәк. Эштән курыкмаган, эш сөйгән кеше беркайчан да югалып калмый, теләсә кайсы илгә барып урнашса да, үзен һәм гаиләсен тәэмин итәрлек акча таба ала. Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз, дип тиктомалдан гына әйтмәгән халкыбыз. Бу мәкалебез кыз-кыркынга да карый.

Рәшит МИНҺАҖ.



ЙӨРӘККӘ ЯКЫН ҖЫРЛАР

Гаҗәп хәл – Казанда татар концертлары юк дәрәҗәсендә. Концерт заллары афишалары рус, Европа композиторлары һәм җырчыларының әсәрләре белән шыплап тулган. Шулай булгач, татар җыры ничек сакланып калсын? Җитмәсә, республикабызның күрке булган опера театрында ел саен «Үзгәреш җил»ләре котырып, татар моңын ботарлый. Шулай да, сирәк булса да, йөрәккә тансык татар җырлары башкарыла. Әмма затлы бу кичәләргә реклама җитми, ахры, халык аларны белми кала. Аннары тамашачы исеме танылган артистларны ярата. Ләкин бүген атказанган җырчылар моннан күп еллар элек сәхнәдә беренче адымнарын атлаганда, аларны да белүче булмаган бит. Әмма кемдер аларны сәхнәгә чыгарган, иҗатка юл ярган.

Сүз Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе оештырган милли җыр проектлары турында. Аларның авторы – филармония директоры, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Кадим Нуруллин, проектны тормышка ашыручы исә – шушы концерт оешмасының әдәби-музыкаль лекторий җитәкчесе, Татарстанның халык артисты Вил Усманов. Проектларның берсе «Их, гармуннар уйный белсәм!» дип атала иде. Җырчы гармунчылар һәм гармунчы җырчылар концертын тамашачылар бик тансыклап, яратып кабул итте. Сүз уңаеннан, гармун моңын яратучылар, йоклап калмагыз, яз айларында концертны яңа башкаручыларны да кертеп кабат күрсәтү каралган. «Республика горурлыгы» дип исемләнгән программа да тамашачыларда җылы хатирәләр калдыргандыр. Анда «Татар моңы» халыкара конкурсы лауреатлары һәм филармония артистлары Рәсим Ильясов җитәкчелегендәге «Казан нуры» халык уен кораллары оркестрына кушылып танылган композиторларыбызның җырларын башкарган иде. Концерт Казанда гына түгел, Әлмәт һәм Түбән Камада оештырылды. «Илһамлы яшьлек» проекты белән дә республикабызның төрле районнарында яшәүче сәнгать сөючеләрне куандырдылар.

Инде филармония оештырган тагын бер затлы кичәнең шаһиты булу бәхете елмайды. «Һаман истә» дип исемләнгән концерт ретро җырлардан төзелгән иде. Аларны филармониянең яшь җырчылары Алмас Хөсәенов, Гөлназ Гарифуллина, Сәет Хөсәенов (концертмейстер), Алинә Хөснетдинова, Салават Шәфыйков, Илүзә Вәлиуллина, Булат Закиров, Миләүшә Миңнушина башкарды. Күбесенең исемнәре таныш түгел. Дөрестән дә, аларның берише консерваторияне яңа тәмамлаган, кайберләре әле укый гына. Шулай да филармония аларны эшкә алган һәм бу концерт алар өчен дә, филармония өчен дә үзенә күрә сынау иде. Ишетсәгез иде бу егет-кызларның Яхин, Сәйдәшев, Сара Садыйкова әсәрләрен, Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова, Фәридә Кудашева репертуарындагы җырларны ничек башкарганын! Үзләре чибәр, тавышлары чиста. Карап туймаслык бер манзара булды бу концерт. Ул җырларны «ретро» дияргә тел әйләнми. «Ретро» сүзе белән ерак үткәндәге күренешләрне билгелиләр түгелме? Татар җыры исә искерә алмый. Бриллиант ташның вакытлар үтү белән бәясе кыйммәтләнә барган кебек. Мәхмүт Хөсәенов сүзләренә Гали Ильясов иҗат иткән «Идел вальсы» искеме? Р.Әхмәтҗанов сүзләренә Алмаз Монасыйпов язган «Кояшларың белән кил син» җыры таушалганмы? Яхин һәм Гөлшат Зәйнашеваның уртак иҗат җимеше «Китмә, сандугач» җыры заман арбасыннан төшеп калганмы? Җырчы Фәридә Кудашева Казахстанда отып кайткан, дистә еллар сәхнәләребездән төшмәгән «Әниемә» җыры һәрвакыт яңа түгелмени? Гомәр Бәширов сүзләренә Сара Садыйкованың «Җидегән чишмә»се мәңге яшь җыр лабаса! Менә шундый затлы әсәрләрдән торган ике сәгатьлек программа белән сәхнә тотты яшьләребез һәм сынатмады. Ретро җырлар дигәндә элек популяр булган артистлар күз алдына килә. Дөрес, яңа чорда филармониянең мондый концертларны да оештырганы булды. Алар йөрәк түрендә кадерле бер хатирә булып саклана. Әмма матур җырларыбызны нәкъ менә яшьләрнең башкаруы аерым бер мәгънәгә ия. Яши җырларыбыз! Онытылмаган әле! Сәхнәдә мәтәлчек кенә атмаган кыланчык мәзәк сөйләүчеләрдән башка, дөбер-шатыр фонограммасыз концерт хәзерге заманда бераз гаҗәп тә тоела хәтта. Җырчыларның үзләрен тыйнак, әдәпле тотуы, туарылып китеп тоссыз сүзләр кыстырмавы да хәзерге сәхнәләрдә сирәк күренеш. Җырлар арасында рояльдә башкарылган Яхин әсәрләрен ишетү дә гадәттән тыш хәл. Ә нинди матур итеп уйный бит музыкант!

Теләсәң-теләмәсәң дә, һәр тишектән сикереп чыккан бүгенге эстрада җырчылары безне затлы музыкадан, матур сәхнә эстетикасыннан гаҗәеп биздергән икән. «Һаман истә» концертында, мәсәлән, зал тулмады, аның каравы тамашачы икеләтә, өчләтә җылырак алкышлады кебек. Мондый программаны, һичшиксез, республикабыз шәһәрләре буенча йөртеп кайтырга кирәк тә бит, тамашачы күп җыелмагач, зал арендасы өчен акча түләп, үзләренә чыгым гына булмасмы? Җырчыларны укуларыннан, бүтән эшләреннән җыеп алу да җиңел түгел...

Татар теле, моң онытылып барган, халык затсыз такмакларга ияләшеп беткән заманда башланган бу изге эш барыбер нәтиҗәсез узмас. Бүген кыер-кыймас кына сәхнәгә чыккан Гөлназ, Алинә, Илүзә, Булатлар берзаман Георгий Ибушев, Зиннур Нурмөхәммәтов, Руслан Дәминов, Зөһрә Сәхәбиева һ.б. мәшһүрләребез кебек олпат сәхнә осталарына әйләнер әле. Аларга бездән игътибар гына кирәк. «Үзгәреш җиле» фестивале янында бу ретро-концерт таш арасыннан яралган нәфис нәзберек бер үсенте кебек кенә. Аның язмышы исә үзебезнең кулларда.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип
Мөнирә СӘГЫЙДУЛЛИНА

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;
222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;
222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;
222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк, г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 29.12.2023

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2550 данә

Заказ 2650

16+